1° 2014

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



КАЗАН

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, идарә рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы (Истанбул)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы (Уфа)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Ж.Ш., техник фәннәр докторы (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы (Мэдисон)
ЯКУБОВ Ф.Я., техник фәннәр докторы (Симферополь)

► **БАШ РЕДАКТОР**

Мөдәррис Харис улы ВӘЛИЕВ

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), БӘДЕРТДИНОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты), ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ Д.Р. (фәлсәфи фикер)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

АБДУЛКАДЫЙРОВА Я.М., АБДУЛЛИНА Н.Т., ХӘКИМОВА Г.Р.

► **РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:**

420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

БУ САНДА:


**Хәерле сәгатьтә!**

*Ә.М. Мазһаров, Р.И. Вәлиев, К.М. Миңнуллин* . . . . . . . . . . . 5

**Тел белеме**

*И.Б. Бәширова.* Татар әдәби теленең алтын чоры (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар язма әдәби теле торышына бер караш) . 11

*Д.Б. Рамазанова.* Татар теленең тарихи лексикологиясе: алтай телләре белән чагыштырма яссылыкта татар туганлык атамалары . 23

*Ф.С. Баязитова.* Бишек туе лексикасы (этнолингвистик аспект) 34

*Г.Ф. Лотфуллина.* Татар телендә фигыльнең хәзерге заман формасындагы кабатлылыкның аспектуаль мәгънәләре . . . . . 39

*Л.Г. Вәлиева.* Шарт мөнәсәбәтенең сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт мәгънәсе белән бәйләнеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43

**Әдәбият белеме**

*З.Г. Мөхәммәтшин.* Г. Ибраһимов һәм З. Вәлиди күрергә теләгән Тукай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

*З.З. Рәмиев.* Тукай энциклопедиясендә әдәби топографияне бирүгә карата (Казан шәһәре мисалында) . . . . . . . . . . . . 62

*Мостафа Өнәр.* Галимҗан Ибраһим һәм татар мәдәнияте . . . . 66

*Д.Ф. Заһидуллина.* Шәриф Хөсәенов: тыелган темалар – яңа формада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74

**Халык иҗаты**

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова.* Татар халык иҗатында «Күр углы» дастаны 84

*Л.Х. Дәүләтшина, Л.И. Вәлиуллина.* Кытайда яшәүче татарларда туй йоласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94

**Тарих сәхифәләре**

*И.К. Заһидуллин, З.И. Гыймадиева.* 1897 елгы беренче халык санын алуга каршы күтәрелгән фетнә истәлеге . . . . . . . 103

*Р.Р. Сафиуллина.* XIX–XX гасыр башы татар китап традициясе: кульязма һәм басма китаплар . . . . . . . . . . . . 115

**Фәлсәфи фикер**

*Д.Р. Гыйльметдинов.* XX гасырда дин һәм җәмгыять чигендә кеше яшәеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126

**Шәхесләребез**

*Х.Ч. Алишина.* Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтев – беренче татар фольклорчы галиме . . . . . . . . . . . . . . . . 134

*Али Хөсәен углы Шамил.* Репрессия корбаны, тел галиме Абдулла Шәрифов (төрекчәдән *Ф.И. Таһирова* тәрҗемәсе) . . . . . . . 141

**Экспедицияләр эзеннән**

*М.Р. Булатова.* Ерактагы якын кардәшләребез: Әстерхан якларына галимнәр сәфәре . . . . . . . . . . . . . 150

*А.М. Гайнетдинов.* Соңгы елларда оештырылган археографик экспедицияләрдә табылган Коръән нөсхәләре . . . . . . . . . 159

**Сәнгать**

*Д.Р. Фәрдиева.* Октябрьгә кадәрге татар театрында комедия жанры 164

*А.Р. Исимбитьева.* Казанда спрей-арт сәнгате үсеше . . . . . . . 168

*Л.М. Шкляева.* «Хәзинә»дә Кырым татарлары сәнгате: күргәзмәгә күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .172

**Яңа китаплар**

Д.М. Абдуллина. Тукай иҗатында Коръән мотивлары. *Ф.И. Габидуллина* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174

А.Х. Садыйкова. XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор. *Н.Ш. Хисамов.* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

М.Р. Булатова. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». *Д.Б. Рамазанова* . . . . . . . 177

*Ә.М. МАЗҺАРОВ*
*Татарстан Республикасы*
*Фәннәр академиясе президенты*



Бүген сезнең игътибарыгызга килеп ирешкән «Фәнни Татарстан» журналы – Татарстан Фәннәр академиясенең күптәннән тормышка ашырырга планлаштырган гаять мөһим проектларыннан берсе ул. Әлеге фәнни журналны гамәлгә кую берничә максатны күздә тотып башкарыла. Без аны төрки-татар дөньясын өйрәнүчеләрне, гуманитар фәннәр өлкәсендә тикшеренүләр алып баручыларны, тарихи-мәдәни мирас белән кызыксынучыларны бергә очраштыручы, туплаучы гыйльми-мәдәни үзәк, фикер алышу урыны булып өлгерер дип уйлыйбыз. Мондый басмалар фән яңалыкларын, татар гуманитар фәнендә ирешелгән казанышларны уртаклашу, җәмгыятьтә фәнни фикерне үстерү мөмкинлеге бирә. Тарих исә аерым бер гыйльми юнәлешләрдә күтәрелешләрнең шул өлкәгә караган журналлар басыла башлау белән бәйле икәнен яхшы белә. Яшьләр өчен осталык мәктәбенә, каләм чарлау һәм беренче эзләнү тәҗрибәләрен яктырту, бәхәсләшү мәйданына әверелүе дә кирәк, әлбәттә. Безнең милләтебез өчен татар телендә фәнни журнал нәшер ителә башлауның татар телен фән теле буларак үстерү, гыйльми терминологияне академик планда баету, татар теленең кулланылыш кырын киңәйтү мөмкинлеге булуы да бәхәссез.

XXI гасыр фәнни журналлар нәшер итү, хәтта йөзләгән шундый басмаларны берләштергән эре нәшриятлар төзү (Голландиянең Elsevier нәшрияты гына да бер елга 2000 фәнни журнал чыгара), аларда дөнья күргән материаллар нигезендә күптөрле рейтинглар ясау вакыты буларак та тарихка кереп калыр. Моның тискәре нәтиҗәләре дә юк түгел: әйтик, РИНЦ базасында иң күп телгә алына торган, иң билгеле 100 Россия журналының 42 се Россия Фәннәр академиясенең «Фән» («Наука») нәшриятыныкы булып, аларның хәзерге нигезләүчесе американың Pleiades Publishing, Inc. компаниясе икәнлеге билгеле. Димәк, фәнни журналларыбызны югалту, аларны башка илләр өчен бизнес чыганагына әйләндерү куркынычы да яшәп килә. Интернет челтәренең үсүе дә, фәнни

белемнәрнең таралыш кырын киңәйтү белән бергә, аларны бәяләү эшен авырайта. Ләкин шулай да академик фәннең киләчәге фәнни журналлар белән турыдан-туры бәйләнгән.

Журналның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты көче белән, әлеге институтка 75 яшь тулган көннәрдә тергезелүе символик мәгънәгә ия. Бу журнал татар гуманитар фәннәреннән озак еллар дәвамында булдырылган төпле нигездә, галимнәре аерым фән юнәлешләрендә әйдәп барган гыйлем йортында нәшер ителеп, татар халкына хезмәт итәр дип ышанам!

Татарлар – элек-электән дәүләте, фәне булган милләт. Татар зыялылары гасырлар буе халыкны мәгърифәткә өндәгән, аң-белем тараткан, гыйлем ярдәмендә үсеш юлына, алгарыш юлына омтылган. Бүген дә Казан гыйльми фикер, фән өчен чын мәгънәсендә нигез хезмәтен үти. Биредә фундаменталь һәм гамәли гыйлемнәрне Татарстанның инновацион үсеше өчен файдалану, татар телен, әдәбиятын, тарихын гыйльми югарылыкта өйрәнү эше алып барыла. Җир йөзендә мондый урын башка юк. Димәк, төрки-татарларны фәнни өйрәнү мәктәбе һәм шуның нәтиҗәләрен таныту эшчәнлеге республика өчен аерым әһәмияткә ия.

Төгәл фәннәр галимнәре «кумулятив эффект» дип аталган күренешне яхшы беләләр. Бу вакытта аерым тармаклар, төркемнәрнең һәм төрле юнәлештә белгеч булган кешеләрнең омтылышлары бер максат тирәсенә туплана. Нәтиҗә исә арифметик суммадан берничә тапкыр артып китә. «Фәнни Татарстан» журналының уртак максаты – гуманитар фәннәр белгечләрен татар телен, әдәбиятын, тарихын, мәдәниятен, милли мирасны өйрәнү ягыннан берләштерү – аны гамәлгә куючыларга да, әзерләүчеләргә дә зур җаваплылык йөкли. Милләтебезгә, фәнебезгә лаеклы басма булып озак яшәсен иде ул.

*Р.И. ВӘЛИЕВ*
*Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе*



Узган гасыр ахырларында башланып киткән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр татар халкы тормышына, аның милли үзаңы, мәдәнияте һәм шул исәптән татар теле үсешенә дә зур йогынты ясады. Соңгы вакытта Татарстан Республикасында тел сәясәте өлкәсенә караган мәсьәләләрне хәл итү юнәлешендә күп кенә чаралар тормышка ашырылды һәм ашырылып килә. Татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү максатыннан аерым кануннар һәм башка хокукый-норматив документларның кабул ителүе халкыбызның рухи-мәдәни мирасын һәм бу мирасның бер чагылышы булган туган телебезне дәүләт теле буларак саклау, үстерү, аны фәнни яктан өйрәнү өчен киң мөмкинлекләр тудырды.

Татарстанда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләсе XX гасырның 20–30 нчы елларында ук җитди рәвештә көн тәртибенә куелды. Республика хөкүмәте бу мәсьәләгә ул вакытта ук зур игътибар биреп, әлеге юнәлештә күп кенә карарлар кабул итә. Дәүләт дәрәҗәсендә тормышка ашырылган мондый кыю чараларның уңай нәтиҗәсе буларак, ул елларда татар теленең кадрлар әзерләүдә дә, төрле дәрәҗәдәге хакимият органнары эшендә дә кулланылыш даирәсе шактый киңәйде. Ләкин аннан соңгы дәвердә мәгълүм сәбәпләр аркасында татар теленә игътибар кимеде. Бары тик соңгы вакытта – XX гасырның 80–90 нчы елларында гына – тел мәсьәләсен заман таләпләре яссылыгында хәл итү мөмкинлеге ачылды. Бу чорда тел сәясәтенә караган мәсьәләләр киң җәмәгатьчелек тарафыннан тикшерелеп, гаять әһәмиятле кануннар һәм карарлар кабул ителде. 1992 елда “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы канунны кабул итү татар теле үсешенә, аның дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелүенә яңа этәргеч һәм хокукый нигез бирде. Алга таба әлеге

канунны гамәлгә ашыру юнәлешендә Дәүләт программалары һәм башка хокукый-норматив документлар эшләнеп кабул ителде һәм өлешчә тормышка да ашырылды. Һәм, ниһаять, 2012 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан татар теленең дәүләт теле буларак кулланылышын тәэмин итү, аны саклау һәм үстерү максатыннан «Татар теленең Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак кулланылышы турында»гы канунның кабул ителүе хөкүмәт тарафыннан әлеге мәсьәләгә зур игътибар бирелгәнен күрсәтеп тора.

Менә сезнең кулыгызда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасының 2014–2020 елларга дәүләт программасы кысаларында татар фәнен үстерү һәм татар теленең фән теле буларак кулланылыш даирәсен киңәйтү максатыннан гамәлгә куелган «Фәнни Татарстан» журналының беренче саны. Мәгълүм булганча, татарларда белем, мәгариф элек-электән югары бәяләнгән, татар халкы борынгы заманнардан китаплы халык саналган. Бүгенге көндә ул рухи, мәдәни һәм фәнни яктан зур үсешкә ирешкән милләтләр белән бер рәттә тора һәм галимнәребезнең фән өлкәсендәге казанышлары киң җәмәгатьчелеккә иң беренче чиратта татар телендә ирештерелергә тиеш.

Ничек кенә авыр булмасын, журнал киләчәктә фән дөньясында үз урынын табар һәм тар даирә белгечләргә генә түгел, ә бәлки киң катлам укучыларга да кызыклы булыр дип ышанам, ә журнал хезмәткәрләренә һәм авторларга аларның татар фәне өчен әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия булган эшчәнлегендә уңышлар телим.

*К.М. МИҢНУЛЛИН*
*Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институты директоры*



Глобальләшү шартларында татар телен саклап калу, аны куллану даирәсен киңәйтү кебек җитди бурычның көн кадагына басуы һәммәбезгә мәгълүм. Аны гамәлгә ашыру төрле яклап якын килүне, татар фәне, мәгарифе, матбугаты, телевидение-радиосы һ.б. өлкәләрнең бердәм рәвештә туган телгә йөз белән борылуны, куелган максаттан чыгып мөмкин булганның барысын да эшләүне таләп итә.

Бүген татар телендә чыгып килә торган журналлар исемлеге шактый бай. Һәркайсының үз юнәлеше бар. Мәгълүмати-популяр, фәнни-популяр, әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журналлар рәтендә фәнни проблемаларны татар телендә яктырта торган, саф фәнни профильле журналның булмавы әлегә кадәр күңелне борчып килде.

Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан гамәлгә куелып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты нигезендә «Фәнни Татарстан» исемле татар телле журналның чыга башлавы – халкыбыз өчен мөһим вакыйга. Ни өчен журналны әзерләп чыгару нәкъ менә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына йөкләнде соң?

1939 елның октябрендә Мәгариф халык комиссариаты карары белән ачылган Институт 75 ел дәвамында татарны өйрәнү, аны милләт буларак саклап калу мәсьәләләрен кайгырта, 1921 елда төзелгән Академик үзәк нигез салган юнәлешне киңәйтә бара. Узган гасыр ахырында аннан Тарих һәм Энциклопедия институтлары мөстәкыйль гыйльми оешмалар булып үсеп чыктылар. Бүгенге көндә безнең Институт татар тел белемен, әдәбият белемен, сәнгатен, халык иҗатын төрле яклап өйрәнү белән шөгыльләнә, шул мәсьәләләрне күтәргән хезмәтләрне һәм классикларыбызның академик басмаларын, һәртөрле сүзлекләрне китап рәвешендә дөньяга чыгара, республика, төбәкара, бөтенроссия күләмендә, халыкара

масштабларда уздырыла торган форумнар оештыра, комплекслы фәнни экспедицияләр аша рухи мирасыбызны барлап, туплап, өйрәнеп, халыкка кире кайтара. Фәнне татарча эшләү – татарлар өчен көнүзәк мәсьәлә, аңа милли ихтыяҗ зур. Милләтне милләт итеп саклый торган категорияләрнең иң олысы, әлбәттә, тел. Фәнни кулланылыштагы телнең генә чын мәгънәсендә тулы канлы булуы, горур яңгыравы шик уятмый. Институт әлеге әһәмиятле мәсьәләләрне җиренә җиткерүдә төп координатор ролен башкара. Татар дөньясындагы фәнни яңалыкларны милләттәшләребезгә җиткерү, читтә яшәүче галимнәребезне берләштерү дә – Институт бурычы.

Шуңа да фәннең төрле юнәлешләрен татар телендә яңгырату вазыйфасы йөкләнгән журнал чыгаруның милләтебезнең йөзек кашы саналган гыйльми үзәккә йөкләнүе табигый хәл. «Фәнни Татарстан» журналы татар мохитенә кагылышлы һәртөрле яңа мәгълүматны киң җәмәгатьчелеккә танытачак. Мондый басманың дөнья күрүе татар теленең, милләтебезнең тагын бер зур казанышы һәм киләчәккә өмете дип саналырга лаеклы. Татар фәне һәм, гомумән, халкыбызның алгарышы өчен бу журнал – чор таләбе, аның оештырылуы безнең милли үзаңыбыз дәрәҗәсен билгели.

Бүген «Фәнни Татарстан»ның беренче санын кулга алдык. Әлеге башлангыч уңышлы, нәтиҗәле булыр, фән белән тыгыз бәйләнгән мәгарифнең алга китүенә дә уңай тәэсир ясар дигән ышанычыбыз зур. Хәерле сәгатьтә булсын!

# ТЕЛ БЕЛЕМЕ

УДК 811.512.145

## ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ АЛТЫН ЧОРЫ (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар язма әдәби теле торышына бер караш)

*И.Б. Бәширова*

Конец XIX – начало XX века является переломным этапом в истории развития татарского языка, который в указанный период начинает употребляться в новых для нее литературных и публицистических жанрах, таких как проза, драматургия и газетные статьи. В статье рассматриваются особенности функционально-стилистического варьирования старотатарского письменно-литературного языка в конце XIX – начале XX века.

**Ключевые слова:** история татарского литературного языка, языковая ситуация, старотатарский письменно-литературный язык, функционально-стилистическое варьирование литературного языка.

Билгеле булганча, XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче чиреге – татар халкының милли аңы, тарихы, иҗтимагый-эстетик фикере, әдәбияты, әдәби теле үсешенең нәтиҗәле-катлаулы бер дәвере ул [Татар..., 1985, б. 212]. Бу дәверне галимнәр, еш кына, халкыбыз тарихындагы алтын чор дип саныйлар. Әлеге мәсьәләне төрле яклап килеп өйрәнергә мөмкин. Бу мәкаләдә темага бәйле рәвештә, язма әдәби телгә мөнәсәбәте ягыннан, кайбер фикерләребез белән уртаклашабыз.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, иске татар телендә, алдагы чорлардагы традиция дәвам итележ, шигъри-тезмә әсәрләр белән бер үк вакытта, төрле жанр-стильгә караган чәчмә әсәрләрнең иҗат ителүе, тәрҗемә кылынуы һәм шәрехләнүе дәвам итеЛә. «...без әле аның хәзинәләрен яртылаш та үзләштермәгән хәлдә яшибез», – дип белдерелсә дә [Әхмәтҗанов, XVIII гасыр..., 2006, б. 5], алдагы дәверләргә караганда, әлеге чыганак хезмәтләрнең сан ягыннан күбрәк булуы күренә.

Язма текстларда чагылыш таба торган эшчәнлекнең кайбер төрләре, мәсәлән, кешеләрне дәүләт-хөкүмәт белән бәйли торган документ-эш кәгазьләренең, аерым фән тармагына караган проблемалар өйрәнелеп языла торган хезмәтләрнең, көндәлек матбугатта яктыртыла торган публицистика, чынбарлыкны образларда күрергә мөмкинлек бирүче матур әдәбият, иманлы булырга өндәүче дини-дидактик текстлар һәм башкаларның, аерым сөйләм типлары буларак бүленеп, жанр-

стиль ягыннан ныграк тәгаенләнүе аңлашыла.

Иҗтимагый шартларга бәйле булып, XVIII гасыр ахыры – XIX гасырның башында, үткен публицистик жанрның ныграк үскәне күренсә дә, XIX гасырның икенче яртысында уку-укыту мәсьәләләренә, иҗтимагый фикер үсешен аңларга тырышу, дини вә дөньяви белем алуга йөз тоту, мәгърифәтчелек хәрәкәте активлаша. Әлеге эшчәнлек әдәби телнең структур төзелешенә үзенчә тәэсир итә.

Ш. Мәрҗани тирән белемле философ, тарихчы, әдәбият, тел, археология, этнография, нумизматика, география һ.б. күп төрле фән тармакларының әһәмияте турында башлап фикер әйткән галим буларак, бөтен дөньяга билгеле булган мәгърифәтче шәхес буларак танылa (Татар..., 1985, б. 225–237). Фәннең шушы ук тармаклары буенча диярлек Каюм Насыйри (1825–1902), Хөсәен Фәизханов (1826–1866), Габделгаллэм Фәизханов (?–1910), Ризаэддин Фәхретдин (1858–1936) һ.б. шәхесләр фәннең төрле тармагында нәтиҗәле эш алып бара.

Бу юнәлештә теология – рухани-дини тәгълимат үсеш ала. Санкт-Петербургта югары белемле дин белгече, публицист һәм нашир Гаталла Баязитов (1846–1911) ислам дине турында рус һәм татар телләрендә китаплар бастыра (Кәрими, 1902). Р. Фәхретдин «Коръән вә табагать» (1900), «Мөхәммәд галәйһиссәлам» (1908), «Җәвамигуль кәлим шәрхе» (1911) һ.б. хезмәтләрен яза. Дин белгече Муса Җарулла Бигиев (1875–1949), «Рәхмәйте илаһия борханлары» (1911), «Халык нәзарына берничә мәсьәлә» (1912), «Шәригать әсаслары» (1917) һ.б. әсәрләрен иҗат итә (Абдулхаков, 2010).

Фәнни хезмәтләр, билгеле булганча, белемле, укымышлы кешеләр укысын дип язылa, бу хәл язма телдә чагылыш таба. «Ш. Мәрҗани Көнчыгышның йөзләгән атаклы галимнәре, язучылары һәм дәүләт эшлеклеләре биографияләренә караган гаять күп фактик материал тупланган... «био-библиографик җиде томлык «Вафиятел-эсляф вә тәхийятел-эхляф» («Элгәрлеләрнең некрологлары һәм аларның киләчәк буыннарга бүләге») хезмәтен – гарәп телендә, ике томлы «Мөстафаделәхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәтен гарәп-фарсы алынмаларын һәм традицион гомумтөрки сүзләрен мул кулланып яза. Башка галимнәрнең хезмәтләре дә шушы ысулда бара. Ш. Мәрҗанинең биобиблиграфик хезмәтен дәвам итеп, Р. Фәхретдинең ике җилд, 14 җөзьәле «Асәр»ен төзи (1900–1908).

К. Насыйри исә, мөмкин дәрәҗәдә, «...Русия мөселманларының үз телендә» язарга тырыша. К. Насыйри, В. Радлов, Г. Фәизханов, Т. Яхин, Г. Рахманколый һ.б. мәгърифәтчеләрнең, балаларга дип махсуслап, рухани-дидактик пландагы фәнни-популяр әсәрләренең теле дә балалар укып аңласын дип, аларның үз телләренә якын итеп язылa [Татар..., 1985, б. 502–512].

Күрсәтелгән чорда кулъязма әдәби мирас һәм халык тарихын өйрәнүгә ныклап игътибар ителә [Татар..., 1985, б. 250 һ.б.]. Бу юнәлеш-

тә шәҗәрә төзү (Әхмәтҗанов, 1991), милли тарих һәм җәгърәфиягә (Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Һ. Атласи, Ф. Кәрими һ.б.), региональтарихи (К. Насыйри, Ш. Тукаев һ.б.), дин гыйлеме (К. Насыйри, Г. Баязитов, М. Имәнколый, Р. Фәхретдин, М. Бигиев, Ф. Кәрими һ.б.), әдәбият гыйлеменә (К. Насыйри, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди һ.б.), тел гыйлеме (С. Күкләшев, К. Насыйри, Н.Ф. Катанов һ.б), аерым төгәл фән тармакларына (тыйб-медицина, хисаплык, һәндәсә, гөлзар вә чәмәнзар (К. Насыйри һ.б.) багышланган һ.б. жанр-стильдәге күп санлы әдәбият дөнья күрә.

Иҗтимагый-публицистиканың үзенчәлекле булып колачы киңәя (Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый Г. Гафуров-Чыгтай һ.б.), татар тормышы, бигрәк тә әдәбияты, мәдәнияте, дини-дидактика мөселман дөньясы һәм Европа-Россия даирәсе яктылыгы фонында каралырга тырышыла, әлеге телләрнең алынмалары кулланылышка кертелә.

Төрле төрдәге календарьлар (К. Насыйри Г. Фәизханов), хатлар (С. Күкләшев, К. Бәширов, Б. Әлпарави һ.б.), сәяхәтнамәләр (З. Бигиев, Ф. Кәрими һ.б.) һ.б. язу эше дәвам итә.

Бу юнәлештә тагын XX гасырның беренче унъеллыгында татар матбугатының барлыкка килеп, Россиянең татар халкы яши торган һәр төбәгендә киң рәвештә колач җәюе мәгълүм. Газетага дигән мәкаләне ничек итеп язарга кирәклекне хәл итү юнәлешендә «Тәрҗеман», «Нур», «Йолдыз», «Казан мөхбире», «Борһане тәрәкъкый» һ.б газеталарда, «Шура», «Аң» һ.б. журналларда әдәби тел хакында кызу бәхәсфикер алышу башлана һәм бу хакта күп сандагы мәкаләләр язып бастыру еллар буена дәвам итә (Хөснетдинев, 2011; Миңнуллин, 2012).

Шуның белән бергә, XIX гасыр уртасы – XX гасырның беренче чирегендә, С. Хәлфин (1778), И. Гиганов (1801), И. Хәлфин (1809) эшчәнлеге дәвам ителеп, тел гыйлеменә караган күп сандагы кулланма һәм дәреслекләрнең басылуы мәгълүм. Болар арасында, әлбәттә, татар телен фән буларак өйрәнеп язган: М.-Г. Мәхмудов (1857), С. Кукләшев (1859), Г. Фәизханов (1887), К. Насыйри (1895), Н. Катанов (1898), Г. Мөхәммәтҗан (1900), М. Өметбаев (1901), Ш. Таһири (1904), А. Мөхәммәдрәхим (1905), Ф. Садыйков (1908), Ш. Иманаев (1910), Х. Кәбутари (1910), Г. Нугайбәк (1911), И. Кондратов (1911), Г. Алпаров (1912), М. Корбангалиев (1912), Х. Гали (1913), Г. Ибраһимов (1914 һ.б.), Г. Сәгъди (1915), Җ. Вәлиди (1915, 1919) һ.б. авторларның хезмәтләре аеруча игътибарга лаек санала. Бу хезмәтләрдә телнең фонетика, грамматика тармаклары буенча: ıул исәптән графика һәм имляга мөнәсәбәтле заман таләбе белән барлыкка килә торган сорауларга җавап эзләнә, алга таба теория булып үстереләчәк фикерләр күтәрелә.

Галимнәр белдергәнчә, XIX гасырның беренче яртысыннан аермалы буларак, XIX гасырның икенче яртысында проза беренче планга чыга, ныклы адым белән реализм

юлына килеп керә. Бу юнәлештә татар язма әдәбиятының сәнгатьле прозасын яңа юлдан алып китә алган Муса Акъегетзадә (1864–1923), Заһир Бигиев (1870–1902), Фатих Кәрими (1870–1937), Закир Һади (1863–1933), Ш Мөхәммәдов (1865–1923), Г. Гафуров-Чыгтай (1867–1942) һ.б. мәгърифәтче әдипләр иҗат итә. Г. Исхакый (1878–1954), Ф. Әмирхан 1886–1926), Г. Ибраһимов (1887–1938), Ш. Камал (1884–1942) кебек классикларыбыз беренче әсәрләрен яза башлый.

Шулай итеп, XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында, фәннең барлык тармакларына да караган фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият, дин тәгълиматы, дини-дөньяви дидактика, иҗтимагый-публицистик, матур әдәбият, рәсми-эш, эпистоляр-хат, көндәлек-һөнәри дигән функциональ стильләр һәм әлеге стильләрнең үз эчләрендәге жанр-төрләре хәрәкәттә булып, һәрберсе үз вазыйфасын үти, ягъни иҗтимагый эшчәнлекнең төрле ягын чагылдыра торган әдәбият дөнья күрә.

Әлеге хезмәтләр, авторлар үзләре белдергәнчә, Болгар – Казан төрки теле белән языла, нык-лы традиция дәвам иткән хәлдә, көчле яңарыш белән бергә үрелә, нәтиҗәдә, татар әдәбияты һәм теленең алтын чоры дип атала торган күренеш барлыкка килә.

Күрсәтелгән вакытта язма телдә традицияләр яңартылып дәвам ителә дигәндә, **беренчедән,** Болгар – Казан төрки тел төшенчәсенең татар теле дип чиратлаштырылуы игътибарны җәлеп итә. С. Хәлфиннең «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов...» дигән беренче кулланмасыннан (1778) һәм «Татарский словарь и краткая татарская грамматика...» (1785) дигән хезмәтеннән башлап, «татарский язык» дигән атама активлаша (И. Гигановның «Грамматика татарского языка...» дигән китабы (1801) һ.б.). Әсәрләрнең исемендә татар теленең гарәп язуы нигезендә өйрәтелүенә басым ясалуы чагылыш таба: «Букварь татарского и арабского письма, с приложением слов со знаками, показывающими их выговор...» (Атнометов, 1802); Казан гимназиясендә һәм университетында татар телен укытучы И. Хәлфинның беренче хезмәте дә «Азбука и грамматика татарского языка, с правилами арабского чтения» (1809) дип исемләнеп басыла; М.Г. Мәхмүдовның хезмәте «Практическое руководство к изучению татарского языка» (1857) дип атала.

Әлеге дәреслекләрнең исемнәреннән татарча әйтелеш һәм укылышның гарәп теле кагыйдәләре буенча бирелгән язылышка нигезләнүе аңлашыла. Шуның белән бергә, татар телендә сөйләшергә өйрәтү мәсьәләсендә, табигый ки, рус теленең үзенчәлеген дә истә тотарга кирәк була. Бу хәл кулланманың төзелешенә тәэсир итә: гарәп графикасындагы татар теле авазы, телне өйрәнүчеләрнең ана теле булган рус теленең кириллга нигезләнгән аваз-хәрефләре һәм терминнары белән татар теленең авазларын **әйтергә өйрәтү** төп максат булып алына.

Бу вакытта К. Насыйриның да татар-рус мөнәсәбәтендә язылган

хезмәтләре басыла башлый: «...татарча һәм урысча үгрәнүчеләргә файдалы гыйлем булсын...» дип язылган беренче дәреслеге «Кыскача татар нәхүе» («Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах») (1860), «Татарча-урысча лөгать китабы»(«Татарско-русский словарь») (1878) дип бирелә.

Алга таба, рус теле белән бәйләнеше булмаган, татар теле фән буларак тикшерелеп языла торган хезмәтләр дә татар сүзен кертеп исемләнә, мәсәлән, Г. Фәизхановның «Татар телигә кыскача гыйльме сарыф» китабы. Бу хезмәттә беренче мәртәбә, гарәп-татар терминнары ярдәмендә сүз, аваз, хәреф мәсьәләсе һәм гарәп теле үзенчәлеге белән татар сүзләрен ничек итеп язарга кирәклек аңлатыла, К. Насыйриның, ике җилд булып төзелгән «Ләһҗәи татари» (1895–1896) – татар телендәге беренче «Аңлатмалы сүзлек»нең сүзлекчәсендә, аерым сүзләр аңлатылганда, төрки сүзе файдаланыла: «Бетмәк (түрки кадим) йазмак. Бер (түрки бир)-әхәдвәхәд...». Түрк атамасы шулай ук аерым халыкның һәм аның теленең атамасы мәгънәсендә дә аңлатыла. «Әнмүзәҗ» китабында «лисанымыз», «үз телемез», «телемездә» дигән сүзләр кулланыла, әмма махсус терминнар гарәп алынмалары белән аңлатыла, «...гарәп-фарсы аз белгән адәмләрдән кыйсса вә хикәят укырга ихласы бар кешеләр өчен, ошбу Әбүгалисина кыйссасын халык аңларлык итеб рус мәмләкәтендәге мөселманлар теленә тәрҗемә» ителүен ассызыклый. Профессор Н.Ф. Катанов, Казан татарлары телендә язылган әдәбиятны урта, югары һәм халык стиле дип атала торган төрләргә бүлеп карарга мөмкин (1898), дип саный, 40 елдан соң С. Күкләшев «тел» дигән төшенчәне стиль термины белән атый, әмма бу төшенчә-атама XX гасырның 30–40 нчы елларына кадәр кулланылмый диярлек.

Р. Фәхретдиннең «Гыйльме әхляк»тан аерым җөзьәләр «...ана телемездә язылмышдыр», яисә «төрки таныган балалар аталарына укып күрсәтмәк өчен» дип басыла (1898) һ.б., ягъни төрки тел дигәндә, татар халкының ана теле истә тотыла.

Шул ук вакытларда, ягъни XIX гасырның соңгы елында, Уфада язма телне төзәтүгә багышланган беренче Гыйльми мәҗлес җыела. Анда Россия төркиләре һәм Казан шивәсе дигән төшенчә-атама рәсмиләштерелә: «...Русия төркиләре өчен Казан шивәсе лисанын гомуми ителеб кабул итәргә. Төрки тел өчен сарыф вә нәхү хаҗәт, үз телемез төрки вә Казан шивәсе илә йазылыр», – дигән карар кабул ителә. Җыелышның сәркәтибе Ф. Кәрими була. Дәреслекләрнең исемендә татар атамасын куллану дәвам итсә дә, төрки атамасы да эзлекле файдаланыла, әйтик, «Сарфы төрки» (Г. Тәүфикъ, 1900), «Сарфы төрки» (Т. Габдрахман, 1900), «Казан төркисе» (Яхин, 1902), «Төрки лисаны» (Халиди, 1903), «Төрки сарфы», «Төрки нәхүе» (Һ. Максуди, 1910) һ.б. Г. Ибраһимов «Татар сарфы» (1911) дип яза һәм алга таба татар атамасы гына кулланыла, Җ. Вәлиди үзенең хезмәтен «Татар теленең грамматикасы» (1919) дип исемли.

Татар телендә газета басыла башлагач, газетага дигән мәкаләне нинди телдә, ничек итеп языйк? дигән сорауга җавап бирү рәвешендә «әдәби тел», «иске татар теле», «борынгы татар теле» дигән төшенчәләр файдаланыла, аларның мәгънәсен аңлатуга омтылыш көчәя. Шулай итеп, XIX гасыр урталарында «халык аңларлык итеп язу» дигән максатның, XX гасырның беренче унъеллыгына кадәр күп төрле итеп – «рус мәмләкәтендәге мөселманлар теле», «Казан халкының үзара сөйләшенә торган телләре», «безнең Казан татарларымызның теле», «төрки лисанының Казан мөселманлар лөгате», «үз татар телемез», «ачык ана телемез», «урам теле», «Казан төркисе», «үз төрки телемез», «борынгы иске татар теле», «иске татар теле», «гавам теле», «лисаны әдәби», «татар-төрек шивәсе», «Тәрҗеман» шивәсе», «Казан халкы сөйләшә торган тел», «саф татар теле», «урта лисан», «китаби әдәбият лисаны», «татарский язык» һ.б. дип исемләнүе аңлашыла. Игътибар итик, гасырлар буена кулланылышта булган Болгар-Казан төркие дигән атамадагы Болгар компонентының файдаланылуы күренми. Алдагы елларда, сәясәткә бәйләнеп, төрки атамасының да тагын да кискенрәк фикерләрдә-бәхәсләрдә төрлечә гаепләнүен күрәчәкбез, әмма ничек кенә булса да, шул вакытларда башлап әйтелгән, хәзерге вакытта актив кулланыла торган татар әдәби теле, борынгы төрки, иске төрки тел дигән төшенчәләрнең хосусый термин буларак ныгуы мәгълүм.

Күрсәтелгән вакытта язма телдә традицияләр яңартылып дәвам итеlә дигәндә, **икенчедән,** XIX гасырның икенче яртысыннан башлап языла торган төрле жанр-стильләрдә, шул жанр-стильләрнең һәрберсенең үз таләбенә туры килгән сүз һәм сүзформаларны кулланырга мөмкин булу нәтиҗәсендә, бу вакыттагы классик иске татар теленең вазыйфасы: а) гарәп-фарсы алынмалары мул кулланыла торган классик иске татар телендә, ә) угыз һәм кыпчак телләренә хас булган үзенчәлекләр файдаланыла торган гомумтөрки нигездә, б) татар халкының авыз иҗаты һәм сөйләмә теленә хас булган мөмкинлекләре киң файдаланыла торган вариантларында тормышка ашырыла – реальләшә. Хәзерге вакытта барлык жанр-стильләрнең дә, асылда, сөйләмә телгә тәңгәл булган язмада баруы мәгълүм. Әлеге мәсьәләне җентекләбрәк тикшереп, ныклы системага салып аңлатырга кирәклек киләчәк эше булып кала.

Күрсәтелгән вакытта язма телдә традицияләр яңартылып дәвам итеlә дигәндә, **өченчедән**, XIX гасырның икенче яртысыннан соң языла торган матур әдәбият стиленең татар мәгърифәтчеләре прозасында, **бер үк әдипнең**, үзенең темасының нинди булуына карап, кайсы укучыга язуы максатына туры китереп, **төрле әсәрен әдәби телнең төрле варианты** белән иҗат итә алуы нәтиҗәсендә, әдәби тел вазыйфасының төрлечә аерымланып файдалана алу мөмкинлеге хасил була. Гасырлар буена дәвам итеп килә торган татар әдәбиятында бу үзенчәлекнең нәкъ

шушы чорда ачык булып күренүе мәгълүм.

Мәсәлән, халкыбызның танылган тарихчы галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, әдип вә публицист Р. Фәхретдиннең татар халкының «ак өстендә кара таныган» күпчелек укучылары өчен, «ачык ана телемездә» дигән искәрмә белән «Тәрбияле ана» (1898), «Тәрбияле бала»(1898), «Тәрбияле хатын» (1899) һ.б. гыйльме әхлак һәм көндәлек тормышны алып баруда кирәкле тәртип-низам турындагы дөньяви-дидактик хезмәтләре иске татар теленең татар халык җанлы сөйләменә хас булган сүз һәм сүз формалары белән баетылган вариантында языла. Бу юнәлештә Ф. Кәриминең сәнгатьле проза әсәрләре, С. Максудиның «Мәгыйшәт» хикәяте, башка мәгърифәтчеләребезнең хикәя-повестьлары языла, аннан соң классик әдипләребезнең иҗаты дәвам итә.

Шул ук Р. Фәхретдиннең Ш. Мәрҗани тарафыннан гарәп телендә языла башлаган био-библиографик пландагы хезмәтенең дәвамы юнәлешендәге күп томлы «Асәр»е [Татар..., 1985, б. 250–251], Ф. Кәриминең әтисе хакындагы «Гыйльман ахунд» дигән рисаләсе, тарихи һәм дини әсәрләре һ.б., югары рухта (стильдә) язылырга тиеш дип саналганга, иске татар теленең гарәп-фарсы алынмалары һәм гомумтөрки традицион язма формалары мул кулланыла торган варианты белән иҗат ителә.

Шушы ук авторлар, төрки гаиләгә караган халыкның күбрәге укып аңласын дигән максатны күздә тотып язганда, иске татар теленең гомумтөрки нигезендә угыз-төрек теленә хас булган сүз һәм сүз формалары күбрәк файдаланылганга, җәдиди-госманлы дигән вариантында иҗат итәләр: М. Акъегетнең автор үзе милли роман дип атаган «Хисаметдин менла» әсәре (1886), З. Бигиевнең «Мавараэннаһергә сәяхәт» («Транс-Осканияйә сәфәр») юлъязмасы ( 1902), Ф. Кәриминең «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), шул ук авторның «Кырымга сәяхәт» (1904), Р. Фәхретдиннең «Шура» журналында басыла килгән төрле өлкәгә мөнәсәбәтле күп санлы фәнни мәкаләләре, Г. Тукай, Ш. Камал һ.б. әдип һәм шагыйрьләрнең башлангыч чор иҗаты, төрле әдиптә төрле дәрәҗәдә чагылыш табып, менә шушы юнәлештә бара. Әлеге күренеш хәзерге әдәбиятта бөтенләй дә чагылыш тапмаганга, аңлату да зур кыенлык тудыра.

Бу вакытта әсәрләрдә тасвир ителә торган вакыйга-хәлләрне хикәяләү төрлечә бара: а) К. Насыйри прозасы белән тәмамлана торган «хикәя сөйләүчеләр» сүзен сөйләп хикәяләү, ә) мәгърифәтчеләрнең күбесендә авторның «үз сүзен сөйләп» хикәяләве, б) классик авторларның образлап хикәяләү таләбе белән тел байлыгын төрлечә файдалану. Әлеге нигездә әдәби телнең вазыйфасы аның структур төзелешенә үзенчә тәэсир итә. Бу хәл бигрәк тә классик әдипләрнең беренче әсәрләрендә үк, аерым сүз мәгънәсенең шул әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган дәрәҗәдә катлаулана алуында ачык чагыла: «Бай угълы» (Г. Исхакый, 1903), «Уяну» (Ш. Камал, 1907), «Буран» (Ә. Камал, 1943), «Яз башы» (Г. Ибраһимов, 1910), «Хәят» (Ф. Әмирхан,

1911) һ.б. Әлеге мәсьәлә дә җентеклəбрәк тишерүне көтә.

Шулай итеп, XX гасыр һәм XX гасыр башында язылa/басыла торган әсәрләрдә, әдәби телнең табигате (тел берәмлекләре) һәм вазыйфасы (төрле стильләрдә реальләшүе) берсе икенчесенә бик нык бәйләнгән хәлдә, традиция булып килә торган үзенчәлекләрнең, чор таләбе белән барлыкка килә торган яңарыш белән бергә, катлаулы үсештәге хәрәкәтендә – кулланылышында була дип әйтә алабыз.

Кызганычка каршы, иҗтимагый тормыштагы гайре табигый сәяси вакыйгалар тәэсире белән, XX гасырның урталарыннан әлеге бәйләнеш-яшәешнең үсешенә киртә куела.

XX гасырның 20–30 нчы елларында танылган галимнәребез татар әдәби теле турында фикер әйтә башлаганда, аның тарихы булуын искә төшерәләр. Әмма җәмгыятьтә башланып киткән вакыйга-хәлләр нәтиҗәсендә, бу юнәлеш үстерелә алмый, галимнәр юк ителә. Татар әдәби теле аерым бер сыйныф – пролетариат теле булырга тиеш дигән караштан чыгып өйрәнелә башлый. «Яңа әдәби тел» төшенчәсе киң таралыш ала, әдәби тел пролетариат сыйныфының теле дип өйрәтелә башлый. Нәзари яктан язма телнең традициясе –дәвамчанлыгы булуы инкяр ителүгә йөз тотыла, гамәли яктан, әлеге максатка ирешүнең төп шарты буларак, гомумтөрки традицион сүз һәм сүз формаларына, гарәп-фарсы алынмаларына каршы катгый көрәш ачыла: алар корама, халыкка аңлашылмый, алардан котылырга кирәк дигән актив эш башлана. Менә шушы эшчәнлек һәм һәр төрки халык үз сөйләменә туры китереп укый ала торган уртак әлифбаның, традицион уртак хәзинә, уртак маяның юкка чыгарылуы, бер гаиләдәге халыкның әдәби язма телләрен сугарып килә торган нык бер тамырның (структур вариантның) корыуына ныклы җирлек тудыра. 1939 елдан башлап, милли мәктәпләрдә рус теле предмет буларак укытыла башлый.

50 нче еллардан башлап, әдәби тел әдәбиятта беркетелгән, уртак норма итеп эшкәртелгән, әдәби телнең төп хуҗасы халык, теге яки бу сыйныф түгел, дип, әдәби тел төшенчәсе яңача аңлатыла (Җәләй, 1953, б. 3–12). Әдәби телнең нигезендә гомумхалык теле ята, дип искәртелсә дә, шушы вакыттан башлап, әдәбиятта беркетелмәгән, ягъни әдәби тел өчен нигез итеп алынмаган, шуңа күрә «бердәм тел эчендә эреп юкка чыгарга тиеш» дип санала торган диалекталь һәм жаргон формаларга каршы каты көрәш башлана: мәкаләләр язылa, китаплар басыла. Әдәби тел диалектлардан өстен була дигән фикер диалектлары эреп бетәргә тиеш дигән фикер белән тәңгәлләшә. Шушы тазарту, чистартулардан соң, әдәби тел а) үзенең язма традициясеннән, ә) гомумхалык теленә нигезләнеп бара торган табигый структурфункциональ вариантларыннан аерыла, әдәби норма дип санала торган бер билгесенә тиңләштерелә, әдәби телнең барлык тармакларында да аңа фәкать берлек (единичность) хас булырга тиеш дигән караш ныгытыла.

Боларның барысы да, язма әдәби тел халыкның гомумсөйләмә теленә якын булырга, әдәби телне тулаем рәвештә барлык халык та бертигез дәрәҗәдә аңларга тиеш, дигән изге ният белән эшләнә. Әмма, киресенчә булып чыга, язма телнең табигатен һәм вазыйфасын аңлауда каршылыклар барлыкка килә.

Нәтиҗәдә, XX гасырның ахырларында, язма телебезгә нисбәтән, берсе икенчесен инкяр итәрдәй фикерләрнең әйтелүе – язылуы күренә. Әдип Р. Батулла болай ди: «...Татар әдәби телебез елдан-ел фәкыйрьләнә. Әдәби телебез базар теленә якыная».

Укучы башкача уйлый: «Мин үзем татар хатыны, тик газетагызны бик авырлык белән укыйм. Аңлашылмый торган сүзләр күп. Мин җиде сыйныфны татар мәктәбендә тәмамладым. Ә сез тел осталары, галимнәргә генә аңлашылырлык итеп язасыз» (Шәһри Казан, 1991, 2 март).

Татар милләте гасырлар буенча төрле формацияләр кичереп барлыкка килгән, бүгенге көндә өч диалекты, яхшы камилләшкән әдәби теле бар, бигрәк тә Октябрь социалистик революциясеннән соң бик нык үсеш алган милли телгә ия, дип өйрәтелде. Шуның белән бергә, аерым галимнәр үзләренең фәнни хезмәтләрендә, көнчыгыш диалект татар теленең диалекты түгел, бәлки мөстәкыйль тел, чөнки татар әдәби теле Себер татарларының гомумсөйләм теле булмады, шуңа күрә ул аның язма әдәби теле дә була алмый, дип язалар (Алишина, 1994).

Татар теле, төрки телләр гаиләсенең бер вәкиле буларак, XI гасырдан ук тикшерелә башлый, XVIII гасырдан укытыла, дәреслекләр языла, фәнни яктан эшкәртелә, дип өйрәтәбез, ә менә Бөтентатар «Мәгариф» берлегенең 2 нче корылтаенда (1995, 7 гыйнвар) «...күп кенә дәреслекләр белән Татарстанда яши торган кешеләрне генә укытып була, читтә яшәүче татар балаларын укыту өчен алар бик үк кулай түгелләр» дигән фикерләр дә күтәрелде.

Сүз дә юк, әдәби норма конкреттөгәл һәм ныклы-тотрыклы булырга тиеш, чөнки аңардан шулай булуны иҗтимагый шартлар, ягъни җәмгыять таләп итә. Әдәби норманы дөрес итеп яза (орфография) һәм дөрес итеп әйтә (орфоэпия) белү адәм баласының грамоталы булуының күрсәткече дип санала, аны һәртөрле гыйлемнәргә өйрәтү процессы берөзлексез әдәби нормага күнектерү белән бергә үрелеп бара. Чит телне үзләштергәндә дә, нигездә, шул телнең әдәби норма булып күтәрелгән формалары, берәмлекләре игътибар үзәгендә тотыла. Бу хакыйкать дәреслекләрдә чагылыш таба, укыту барышында күп тапкырлар кабатлана. Иң мөһиме, әдәби норма әдәби телнең бөтенлеген хасил итә, шул телдә сөйләшүчеләрнең күбесе өчен аңлаешлы булуын тәэмин итә. Һәрхәлдә тәэмин итәргә тиеш. Әмма югарыда искә алынган капма-каршы фикерләрдән аңлашылганча, татар әдәби теленең бу юнәлештә хәл итәсе проблемалары булуы күренә. Әдәби телне, аның табигатен барлыкка китерә торган традициядәвамчанлык, эшкәртелгән-шомартылган, диалектларыннан өстен,

нормага һәм шул норманың вариантлылыгы белән функциональ-стилистик вариантлылыгына ия дигән шартларының фәкать нормага ия, дигән бер билгесенә тәңгәлләштереп тикшерү һәм шуны гына өйрәтү әлеге проблеманың хәл ителергә тиешлеген аңлата.

Әдәби тел дигән вакытта, аның, әлбәттә, барлык тармакларында да нормага ия булуын истә тотылганы хәлдә, норма дигән билгесеннән башка компонетлары да булуын искә алмау нәтиҗәсендә, әдип күзлегеннән караганда, фәкыйрьләнгән, җиде класс белеме булган укучы өчен катлауланган, үзен зур галим дип исәпләүче күзлегеннән караганда, сөйләмә тел белән язма тел бер үк күренеш булырга тиеш, дип санала.

Сөйләмә телләрендәге күп кенә берәмлекләре әдәби норма булып күтәрелмәгән төбәкләрдә билгеле бер норманың гына дөрес булуын исбатлау укучыда аптырау тудыра. Һәр кешенең ана теле дигәндә, асылда, аның туган төбәгендәге сөйләшү теле, шул үз төбәгенең нормасы истә тотыла. Дәреслек буенча барганда, аның норма булмавы күренә, ул инкарь ителә. Шуңа күрә дә тел укытучылары, татар телен һәм әдәбиятын укытканда, озак еллар буена җирле сүзләрне әдәби сүзләр белән алмаштырып бетерүне төп максат санадылар.

Безнең көннәрдә татарларга латин графикасына күчәргә мөмкинлек бирелмәве Россиядәге төрки телле халыкларның үзара мөнәсәбәтенең дәүләт җитәкчеләре тарафыннан ныклы контроль астында тотуларын күрсәтте. Шуның белән бергә, авыллардагы татар мәктәбендә укучыларны районга илтеп, рус мәктәбенә кушу, Бердәм дәүләт имтиханын гамәлгә куеп, күп милләтле Россиядә, дәүләт күләмендә, милли компонентны, димәк, милли телне укытуны кирәксезгә чыгару, ягъни ана телен оныттыруга юл ачу булып яңгырады.

Әлеге шартларда төрле төбәкләрдә таралып яшәгән татарларга, милли аңны, милли телне саклап калу зарурияте тагын да кискенләште, иң мөһим булган көн тәртибе буларак күтәрелде. Әлеге вазгыятьтә Татарстан җөмһүрияте, татар телчеләренә татар халкын саклап калу юнәлешендә иң кирәк булган вазыйфа йөкләргә тиеш була. Ул – татарлар яши торган барлык төбәкләрдә дә яратып укыла торган, ягъни гомумхалык теленең тулаем байлыгы күрсәтелә алган дәреслек-кулланма төзү.

Хәзерге татар теле белемендә, бу эшнең теоретик нигезе фәнни югарылыкта эшләнгән [Татар..., 1998, б. 152–161; Татар..., 2002, б. 120–121]. Гамәли нигезе, лексиктематик яктан караганда, «Татар теленең аңлатмалы» һәм «Татар теленең диалектологик» сүзлекләрендә урын алган.

Әмма милли телнең ике канаты булган әдәби норма һәм диалекталь форма берсе икенчесе белән кушылып бирелгән, ягъни гомумхалык теленең байлыгы күренә торган хезмәтләребез язылганы юк. Бүгенге көндә татар телчеләре алдына изге бурычны үтәү вазыйфасы куела, ул да булса, татар милли теленең тулаем барлык көч-куәтен, колачын, зурлыгын күрсәтердәй дә-

реслек-кулланмалар язу, татар теленең һәр берәмлегенә милли хәзинә, дәүләти мирас итеп карап, аларны тулаем бөтен килеш күрердәй уку әсбаплары төзү. Мәсәлән, әлеге яссылыкта фигыль заманнарына игътибар итик. Билгеле булганча, чынбарлыктагы реаль – объектив өч заман хәзерге татар әдәби телендә тугыз, сөйләшләрдә егерме тугыз заман формасы белән белдерелә; хәзерге заман әдәби телдә – бер, сөйләшләрдә – сигез формада, үткән заман әдәби телдә – биш, сөйләшләрдә – уналты, киләчәк заман әдәби телдә – өч, сөйләшләрдә – биш формада чагылыш таба [Татар..., 2002, б. 121–145]. Фигыльдәге модальлек категорияләрендә дә шундый ук нисбәт саклана дияргә мөмкин: теләк фигыле әдәби телдә *-ый*, *-и* кушымчалары белән ясала [шунда ук, б. 154], сөйләшләрдә аның унбер күрсәткече бар. Ният модальлеге әдәби телдә – *макчы* формасы белән белдерелә, сөйләшләрдә аның ундүрт күрсәткече теркәлгән һ.б. Татар әдәби теленең табигатен барлыкка китерә торган билге-шартларның берсе булган норма һәм халкының сөйләшләрендәге вариантларның үзара мөнәсәбәте ни дәрәҗәдә икәнлеге китерелгән мисаллардан ачык күренә.

Билгеле булганча, сөйләм – телнең табигый халәте, сөйләм барышында тел берәмлекләре аралашу коралы буларак, үзләренең төп вазыйфаларын үти. Димәк, вариантлылык – ул телдәге табигый эчке мөмкинлекләрнең чагылышы, нормативлык исә – телнең тышкы шартларга ярашып, җәмгыять тарафыннан куелган таләпкә җавап бирүе шартларында, бер форманың кулланылышта ныгуы.

Гомуммилли татар теленең тулаем байлыгын күрсәтү максатыннан төзелгән дәреслектә, әлбәттә инде, әдәби норма булып күтәрелгән форма ассызыкланып, нигез итеп алына һәм әлеге норманың кайсы сөйләштә тагын нинди вариантлары булуын күрсәтергә кирәк була. Шулай итеп, әдәби норманың нинди байлыкка нигезләнүе, һәр этник төркемнең әлеге хәзинәне барлыкка китерүдәге өлеше күзалланачак. Мондый дәреслек-кулланма татарлар яши торган барлык регионнарда да укыту әсбабы була алыр иде. Татар язма әдәби теленең, себер татарларында гына түгел, башка төбәктәге кешеләр өчен дә саф сөйләмә тел була алмавы, бәлки барысына да аңлашылырлык хәлгә китерелгән язма телнең, үзенә хас вазыйфаларын үтәве өчен файдаланылуыннан аңлашылыр иде.

Язма телнең киң кырлы вазыйфасын – функциясен аңлау өчен, тел берәмлегенең структур төзелеше һәм табигый мәгънәсенең, сөйләмгә килеп кергәч, ничек итеп сөйләм мөмкинлекләре ачылуын күзәтергә кирәк була. Хәзерге гомуми тел гыйлемендә нәкъ менә Ф.М. Березин күтәргән проблема, ягъни телнең барлык тармакларын да, тел һәм сөйләм күренеше буларак, объектив-фәнни итеп өйрәнергә мөмкинлек бирә торган, фундаменталь әһәмияткә ия булган методологик нигез дип санала: «XX век выдвинул на первое место функционирование языковой структуры и ее внутреннюю

организации», – диелә [Березин, 1979]. Әмма бер генә телдә дә болай итеп тикшерүнең ныклы гамәлгә куелмавы, терминнарның да системалы рәвештә аерымланмавы искәртелә [Березин, 1979: 23–28, 140–141]. Әлбәттә, хәзерге вакытта, татар телен алтын тәхеткә мендереп куеп булмый, шулай да бергәләп уйлашасы иде...

## ӘДӘБИЯТ

Әхмәтҗанов М . XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати. 2006. 363 б.

Березин Ф.М., Головин Б.Н. Общее языкознание: учебное пособие для студентов пед. ин-тов. М.: Просвещение, 1979. 415 с.

Җәләй Л. Татар теленең орфоэпик нигезләре. Казан: Таттосиздат, 1953. 72 б.

Рамазанов Ш.А. Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 200 б.

Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. II т.

Татар грамматикасы. М.: Инсан, Казань: Фикер, 1998. I т. 512 б.

Татар грамматикасы. М.: Инсан, Казань: Фикер, 2002. II т. 448 б.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,*** филология фәннәре докторы,
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
гомум лингвистика бүлегенең баш фәнни хезмәткәре

УДК 811.512.145′373

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТАРИХИ ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ: Алтай телләре белән чагыштырма яссылыкта татар туганлык атамалары

*Д.Б. Рамазанова*

В статье рассматриваются термины кровного, свойственного и общего родства, общие для тунгусо-маньчжурских, древнетюркских и монгольских языков. Некоторые термины родства восходят к китайскому, корейскому, ностратическим языкам. Выдвигается предположение, что часть общей для названных групп языков лексики может быть связана с праалтайским периодом глоттогенеза.

**Ключевые слова:** историческая лексикология, татарский язык, термины родства, ностратические языки.

Татар теленең төп лексик фонды формалашуда бабаалтай (праалтай) берлеге чорын, ностратик чордан соң икенче чор итеп алырга мөмкин. Билгеле булганча, татар теле, бөтен төрки телләр, тунгус-маньчжур һәм монгол телләре төркемнәре белән бергә, алтай телләре гаиләсенә керә. Бабаалтай телләре берлеген безнең эрага кадәр X гасырларда булган дип исәплиләр. Бу берлек безнең эрага кадәр VI меңьеллыкта таркала башлый. Башта тунгус-маньчжур телләре аерылып чыга дип санала. IV (б.э. кадәр) меңьеллыкта монгол телләре һәм төрки телләр төркемнәре аерылганнар дип исәпләнелә. Әлеге телләрнең кардәшлеге хәзерге телләрнең лексика һәм грамматика өлкәләрендә уртак сүзләр яки күренешләр булуы белән раслана. Бу турыда Г.И. Рамстедт, Н.А. Баскаков, Б.Я. Владимирцов, Дж.Г. Киекбаев һ.б. күп кенә галимнәрнең хезмәтләрендә тикшерелә. Дөрес, күрсәтелгән телләр төркемнәре арасындагы уртаклыклар аларның кардәшлегеннән түгел, бәлки озак дәверләр буена сузылган үзара бәйләнешләрдән барлыкка килгән, дигән карашта торучы галимнәр дә бар (мәсәлән, А. Лигети, В. Котвич, Г.Д. Санжеев, Д. Дечи һ.б.).

Татар теле лексик-семантик системасының формалашуын һәм үсеш-үзгәрешен диахроник аспектта тасвирлау барышында биредә телләр үсешенең алтай чорына аерым тукталу бурычы куелды. Бу мәсьәлә буенча әдәбият шактый чикле. Алар арасында аеруча әһәмиятле, бай һәм ышандырырлык тикшеренүләр В.М. Иллич-Свитыч (1971; 1976; 1984) һәм аның укучыларының хезмәтләрендә, тунгус-маньчжур телләренең чагыштырма сүзлегендә (I һәм II кисәкләр; 1975), А.В. Дыбо (1996) хезмәтләрендә чагылган.

Биредә алтай телләре берлеге чоры белән бәйләнешле татар

туганлык атамаларын барлау өчен борынгы төрки тел, тунгус-маньчжур һәм монгол телләре өчен уртак булган, шушы өч төркемнең барысында да табыла торган сүзләр ачыклап карала, чөнки бу чордагы төрки лексиканы шартлы рәвештә барлык төрки телләр, шул исәптән татар теле өчен дә уртак дип карарга мөмкин. Бу тикшеренү тунгус-маньчжур телләренең чагыштырма сүзлегендәге [сравнительный словарь..., 1975] материалларга нигезләнә. Әлеге өч төркем телләр өчен уртак булган сүзләр бабаалтай телләре таркала башлаганчы ук кулланышта булмадылар микән, дип фараз итәргә нигез бар.

Әлбәттә, бабаалтай чорына караган лексиканы барлау бик тирән эзләнү-тикшеренүләр уздыруны таләп итә. Төрки, тунгус-маньчжур һәм монгол телләре төркемнәренең өчесендә дә табыла торган лексиканы да нечкәләп тикшерү кирәк, алар арасында соңгырак чорларда үтеп кергән алынмалар да булырга мөмкин, чөнки (мәсәлән, эвенкий, солон, эвен һ.б. кайбер телләрдә) соңгы чорларда кабул ителгән монгол алынмаларының шактый зур урын алып торуы ачыкланган.

Татар теле лексикасында алтай гаиләсе телләре белән уртак сүзләр табылуына галимнәр күптән игътибар итеп киләләр. Мәсәлән, Н.А. Баскаков [1969, с. 118], Дж.Г. Киекбаев [1966, с. 94], А.Х. Нуриева [1975, с. 14–15], Э.Ф. Ишбердин [1986, с. 21–40] хезмәтләрендә китерелгән чагыштырма материаллар шуны күрсәтә.

Ностратик[1] сүзлектә [Иллич-Свитыч: 1971, 1976, 1984] кантуганлык атамалары теркәлмәгән. Никах туганлыгы атамаларыннан түбәндәгеләр күзәтелә: *ир* (№ 108), *килен* (№ 162), *кода* һәм *кияү* (№ 174), хатын, хатын-кыз (№ 178) [Иллич-Свитыч, 1971, 306]). Р.Г. Әхмәтьянов бу төркемгә тагын *кәләш, нәнәш, нәни* сүзен дә кертә [Әхмәтьянов, т. 2]. Ике кабиләнең кыз биреп, үзара туганлашуы бик борынгы чорларда ук үтә җитди иҗтимагый-социаль акт булган, ул ике кабилә арасында алыш-биреш рәвешендә барган. Ностратик сүзлектә бары никах туганлыгы атамалары гына чагылган булу да шул турыда сөйли.

Икенчедән, бу атамалар күп мәгънәле, ностратик чорда аларның функцияләре конкретлашудан бик ерак тора әле. Әйтик, ностратик *küda* атамасы нигезендә кода һәм *кияү* атамалары формалашкан, монда никахның төркемле характерда булуы, *küda* атамасының әйтелеше буенча әле сингармонизм кануннарыннан ераграк торуы, кабиләдәге ир әгъзаларны индивидуальләштерүнең бертигез бармавы һәм башка факторларның роле зур булган.

Туганлык атамалары турында фикер йөрткәндә тагын бер әһәмиятле үзенчәлекне искәртеп үтәргә кирәк. *Ирән, углан* атамаларындагы *-ан/-ән* элементларын җанлы әйберләрне белдергән исемнәргә [Иллич-Свитыч, 94–96] ялгана торган ностратик *-NA* суффиксының метатезланган варианты дип саныйлар. Тора бара әлеге сүзләрдәге күплек мәгънәсе онытылган һәм бу ике мисал борынгы төрки телдә үк күплектә хәзерге *-лар/-ләр* кушымчасын ала башлаганнар: угланнар, ирәннәр.

## Никах туганлыгы атамалары

**Ир** атамасы ностратик чорда ук булган һәм ностратик сүзлектә *Herä* формасында теркәлгән, ата, иркәк мәгънәләрен белдергән, дип фараз ителә (№108); [Иллич-Свитыч, т. 1, 247–248]. Дравидий телләрендә: тамил. *ēru* – үгез, ата кыргый хайван (болан, юлбарыс һ.б.); *малаялам ēru* – үгез; *брагун arē* – ата хайван, ир һ.б. Алтай телләрендә киң таралган төрки *är* – ир кеше, ирем; *ērkäk* – ата хайван: якут *är, ergäx,* бор.-уйг. *är, erkäk,* азәрбайҗан *är, erkäk,* төрек *er, irkek,* бор.-угыз *är/er, ärkäg,* чув. *ar* һ.б. – ир кеше, ата хайван. Монгол телләрендә: уртамонг. *ére,* язма монгол. *ere, халха er,* монгор. *rē,* бүр. *ire,* калмык *erə,* могол. *irrá* – ир кеше, ата хайван. Һинд-европа телләрендә дә бу сүз төрле вариантларда булган дип фараз ителә: бор.-һинд *rşa – bħà – s* – үгез, авеста. *aršan* – ир кеше, ата хайван, әрмән *arn* – кеше һ.б.

Сүз башындагы *ħ* авазы протетик аваз дип санала. Кайбер кантуганлык атамаларында бу типтагы протетик аваз борынгы төрки сүзлектә дә теркәлгән (*hata, hana* һ.б.) [Древнетюркский..., 1969, с. 197].

Татар сөйләшләрендә *ир* атамасының мәгънә функцияләре киң, дериватлары да күп, аның бай концептуаль һәм коннотатив эчтәлеге барлыкка килгән [Рамазанова, 1988]. *Ир-атау* (лш.) – гомумән ир кеше. *Ир* сүзе нигезендә «ирләрчә манералы хатын-кыз» төшенчәсен белдерә торган бер төркем сүзләр ясалган: *ирдәүкә* (әдәби телдә дә шулай ук) (казан арты сөйләшләрендә); *ирдаука, ирҗәнкә* (тмн.); *ирҗәнкә* (мам., минз., кмшл., чст., нгб.); *ирдаwай* (дөб., тпк. мәл., чпр., злт., байк.), *ирмирәй* (кмшл.); *ирҗдай* (нгб.).

Сөйләшләрдә тагын *алдангы ир* (подб.) – баштагы, элекке ир; *ирсез-кушсыз* (тмн.) – ялгыз хатын, ирсез хатын һ.б. тәгъбирләр дә күзәтелә.

Ул борынгы төрки язма истәлекләрдә үк, төп формадан тыш, төрле кушымчалар алып ясалган дериватлар рәвешендә, төрле-төрле мәгънәләрдә кулланылган инде [Древнетюркский..., 1969].

«Кыйссаи Йосыф»та ир кеше, сугышчы: *Ун ике бең эр берлә атлан дилар, Йусефи алмаға қәсд қыйлдилар* [Кол Гали, 1983, б. 332].

*Äр* сүзенең күпмәгънәлелеге Кодекс Куманикуста да күзәтелә: «ир кеше», «ире, тормыш иптәше». Тагын берничә дериваты да теркәлгән: *äркäк* – ир кеше, ата җенестән; *äplik* – кыюлык, ир-егетлек, хәзерге татар әдәби телендә дә актив кулланылышта [Махмутова, 1978, с. 12]. *Ир* лексемасының семантик мөмкинлекләре «Идегәй» халык дастанында аеруча нык ачылган [Рамазанова, 1988, б. 90].

**Килен** атамасы да актив кулланылышлы, күп мәгънәле классификацион атама. Төрле фонетик вариантлары (*килн, килне, кин*), дериватлары (*килендәш/киндәш, киленлек* һ.б.) бар. Ностратик сүзлектә *килен* (№ 162): *kälu* – никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән хатын-кыз туганнар [Иллич-Свитыч, 1971, с. 295–296]. Бу сүзнең **kl-* тамыры семит-хәмит телләрендә үк булган һәм «килен (улының яки ир туганының хатыны)», «кәләш» мәгънәләрен белдергән. Семит-хәмит гаилә

телләренең кайбер диалектларында «никах», «кәләш» мәгънәләрендә дә күзәтелә. Грузин телендә *kal* – хатын-кыз, диалектларда – хатын; кыз кешегә эндәшү формасы. Һинд-европа телләрендә *г* яки *з* (чагышт.: *гәүһәр – җәүһәр*) тартыгына башланган вариантлар (шулар арасында славян *zъlъve* > золовка – иренең сеңлесе) таралган.

Урал телләрендә нигездә *kälü* һәртөрле никах туганнарны (хатын-кыз туганнарны да, ир туганнарны да) белдерә. Мәсәлән, фин «иренең яки хатынының кыз туганы», «ир туганының хатыны», эстон. «иренең ир туганы, иренең ир туганының хатыны»; саам, мордва (мукшы һәм эрзя) телләрендә «иренең ир туганының хатыны», мукшы-мордва телендә тагын «иренең абыйсы», удмурт *kalî* «килен», коми-язьва. *kel* «ир туганының хатыны» [Лыткин, 1964, с. 136]; самодий, ненец телләрендә (килендәшләр бер-берсенә карата; баҗалар бер-берсенә карата; бертуганнарга кияүгә чыккан бертуган кызлар яисә бертуган кызларга өйләнгән бертуган егетләр; нганасан, селькуп – «баҗа»).

Ностратик сүзлектә төп сема итеп «никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән хатын-кыз туганнар» мәгънәсен күрсәтәләр. Хатын-кыз туганнарны белдерә торган терминнарның никахлы ир туганнарны да белдерүгә күчүен (кара: эстон, мордва, самодий) беренче башлап бертуганнар белән бертуганнарның өйләнешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән ситуациядә туган булуы мөмкин, дип фараз итәләр [Иллич-Свитыч, 1971, 295-296]. Бер үк атаманың ир җенесеннән булган туганнарны да, хатын-кыз җенесеннән булган туганнарны да белдерүе белән минем үземә дә очрашырга туры килде. Минемчә, әлеге мәсьәлә катлаулырак һәм җәмгыятьтә, теге яки бу этносның тарихында булып үткән иҗтимагый һәм тарихи факторлар белән бәйле булса кирәк. Атама эчтәлегенең җенси яктан капма-каршы мәгънәгә күчүенең аеруча никах туганлыгын белдерә торган терминнарда күзәтелүе дә шул турыда сөйли, чөнки кыз алышу-бирешүнең нигезендә социаль күренешләр ята, ул иҗтимагый фактор.

**Кода, кодагый.** Бу атамаларның сүзлекләрдә теркәлгән мәгънә эчтәлеге сөйләшләрдә дә әдәби телдәгечә.

Диалектларның, яисә аерым сөйләшләрнең үзенчәлекләренә ярашлы рәвештә, кода сүзенең мондый фонетик төрдәшләре бар: *кыда/кыᵒда/кода* (көнб. диал.), *кыда* (м.-кар.), *'ода* (кас.), *қодо/қода* (каз.ар.-крш.; шулай ук: [Материалы.., 1978, с. 29), *қота, қотағай* (туб.-ирт. диал., брб. диал., том. диал.), *қатағы* (том. диал.). *Қөдо* – сват.

Ностратик сүзлектә *кода* сүзе – борынгы сүзләрнең берсе, ул ностратик чорда ук булган, дип күрсәтелә. *Küda* – никахлашу нәтиҗәсендә булган ир туган (№ 174), [Иллич-Свитыч, 1971, с. 302–303]. Урал гаилә телләрендә *кӱдӥ* – баҗа, иренең яки хатынының ир туганы; фин телендә *kyty* – хатынга иренең яки иргә хатынының ир туганы, вепс. *Küdu;* эстон *küdi, küdü* – каенага, иренең ир туганы, ханты *küli, kitә* – баҗа, хатынының кыз туганының ире, *kipi, kili* – баҗа, хатынының кыз туганы, хатынының

абыйсының кызы. Картвель телләрендәге материаллар сорау белән генә китерелгәннәр: грузин телендә *kvisl,* мегрел *kvišišil-,* сван. *me – kwš – ēl* һ.б. – бажа, хатынының кыз туганының (апасы яки сеңлесенең) ире. Алтай гаиләсе телләрендә бу сүз бик актив һәм төрле мәгънәләрдә кулланыла: *küdä/kuda* – 1) үги туганлык; 2) кода; 3) кияү. Монгол *kuda* – кода, өйләнешүчеләрнең берсенең атасы икенче якның ата-аналарына карата, кодалар бер-берсенә карата; халха *xudâ,* монгор *gudā,* бүрәт *xuda,* калмык *xudû* – шул ук мәгънәләрдә.

Ностратик сүзлек авторлары Л.А. Покровскаяның, бер төркем төрки телләрдәге *kuda* сүзе монгол алынмасы [Покровская, 1961, с. 72–73], дигән фикере белән килешәләр [Иллич-Свитыч, 1971, с. 303]. Минемчә, бу фикерне, өстәмә материалларны исәпкә алып, яңадан карарга кирәк.

Төрки телләрдә төп ностратик сүз яки аңа якын вариант тува (*küdä*), карагас (*k'üdö, һüdö*), якут (*kütüö*) телләренә хас. Ул сүз кияү, сеңлесенең яисә кызының ире мәгънәләрендә; татар *kijäw,* үзб. *gijäv,* казак *küjeй,* кумык *gijev,* азәрбайҗ. *gijäv,* диал. *gijov,* төрек *güvej* (i), гагауз. *güvä,* чув. *kēru* – шул ук мәгънәләрдә.

Бер төркем төрки телләрдә (бор. уйг., чыгтай, бор. угыз телләрендә) *küдa – yü.* Мондый вариант һәм аның якын төрдәшләре татар теленең пермь, нократ сөйләшләрендә һәм Себер ареалындагы татар диалектларында спорадик рәвештә күзәтелә.

Шулай итеп, борынгы ностратик küdä сүзе әйтелеше белән дә, эчтәлеге ягыннан да ике юнәлештә үзгәреш кичерә барган: *küdä* – 1) кода; 2) кияү. Бу ике юнәлешнең азагы татар телендә күптәннән дифференциацияләшеп ике мәгънә функциясе урнашкан: 1) *кода* дип, өйләнешкәч, ике яктагы ир туганнар бер-берсен атыйлар; 2) *кияү/көйәү* дип сөйләүчедән кечерәк яшьтәге кыз туганның ирен, кызының ирен атыйлар.

*Кода* атамасы хәзерге төрки телләрнең зур күпчелегендә бар, ул күрше фин-угыр халыклары телләренә дә үтеп кергән: удм. *куда, кудо, кыдо* – кода, мар. диал. *башкуда* (хатын-кыз) – башкода, эрз. *куда* – поезжанин, *кудави* – кодагый (русчасы: сваха), мукш. *куда* – кода һ.б.

Барлык төрки телләрдәге кебек [Покровская, 1961, с. 73], татар телендә дә *кода* атамасы ирле-хатынлыларның ата-аналары тарафыннан бер-берсенә карата кулланыла торган уртак атама.

Кыпчак телләренә хас булганча, *кода* – ирләр атамасы, ә хатын-кызларга карата *кодагый* (< кода + -гый) атамасы кулланыла: әд. һәм урта диал. *ҡодағый,* кас. *'ода'ый,* көнб. диал. *кыдагий,* туб.-ирт.диал., том диал. *ҡотағый,* брб. диал. *ҡотағый / ҡудағай.* Киң вариант ногай (*кудагай*), кара-калпак, казакъ (*ҡудағай*) телләрендә дә кулланыла.

**Кода, кияү** < *küda* – никахлашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән ир туган (№ 174). Бу атама ностратик телләрдән урал, алтай, картвель гаилә телләрендә табыла, никахлашу туганлыгы атамалары системасында ир туганнарны белдерә.

Мәсәлән, фин *kyty* – иренең яки хатынының ир туганы; эстон, вепс,

манси – шулай ук. Ханты телендә *kitә* – бажа, хатынының бертуган апасының яки сеңлесенең ире; *kili* – хатынының кыз туганы, хатынының ир туганының кызы, ягъни бередә ир ягы яки хатын-кыз ягы туганнар дифференциацияләнеп җитми, галимнәр моны урал **küdü* (бажа) һәм *külü* (хатынының кыз туганы) атамаларының контаминациясе дип аңлаталар [Toivonen, 1955–1962].

Төрки телләрдә *küda* (русчасы: свойственник) сүзе берничә төрле мәгънә белдерә, фонетик яктан да төрлелек күрсәтә. Бигрәк тә анда аңкау гармониясенең күзәтелмәве игътибарга лаек. Әлеге факт küda сүзенең ике вариантта (кода, күдәгү) үсеш-үзгәреш алуына китергән булырга мөмкин.

*Küdä-γü* (кушымчадагы γ хәрефе аңлашылмый, чөнки гомумтөрки γ – тирән тел арты авазын белдерә, аның саңгырау пары q яки k тирән тел арты γ авазы янында ü килә алмый) – кияү, кызының яки үзеннән кече кыз туганының ире. Әмма борынгы уйгыр, чыгтай, иске кыпчак [Сравнительный.., 1975], иске угыз (ягъни борынгы төрки)телләрендәге кыскарган *kijew* һ.б.ш. вариантлар тува, карагас, кумык, казакъ һ.б. телләрдә бар.

Татар әдәби телендәге *кияү*, диалектлардагы *кейәү, күwәw* сүзенең, пермь сөйләшендә, Себер ареалындагы татар сөйләшләрендә *көйәwү, күдәгү* очраклары да кулланылалар.

Татар телендә кияү һәм кода атамалары дифференциацияләнеп беткән инде: кода – өйләнешүчеләрнең ата-аналары яисә башка ир туганнарының бер-берсенә мөрәҗәгать итү сүзе, ә хатын-кызларда ул *кодагый*, Себер ареалындагы татар сөйләшләрендә *қутағай*, *кийәү* – үзеннән кече яшьтәге хатын-кыз туганының ире. Кызганычка каршы, ностратик сүзлектә төрки телләрдә *кода* сүзенең, гәрчә килеп чыгышы ягыннан аны ностратик *küda* сүзе белән бәйләсәләр дә, кулланылышы турында материаллар китерелмәгән.

Тунгус-маньчжур телләрендә татар теле белән уртак никах туганлыгы атамаларыннан тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин.

Ире мәгънәсендә *әӡи* (нанай телендә), *эди* (эвенкий, ороч, эвен, ульч, орок теллләрендә) сүзе кулланыла, кайбер тунгус-маньчжур телләрендә аның дериватлары күзәтелә, семантик яктан да үзенчәлекләр бар. Мәсәлән, солон телендә *эдӣ* ~ *әӡӣ* – хуҗа, әфәнде; негидаль *эди* – ире, ата кош, дус; ороч телендә *эди* – ата кош, I зат тартым кушымчасы белән килгәндә – *ире* (чагыштыр: татар диалектларында минем ирем мәгънәсендәге *хуҗам, байым, тарым, өй гешем* кебек 1 зат тартым кушымчалы сүзләр). Удэйча *әӡә(н)* – 1) хаким, дәүләт башлыгы; 2) патша; 3) хаким, дәүләт башлыгы; 4) патша; 5) җан (күңел) хуҗасы (дух – хозяин). Ульч. телендә *әӡә(н)* – 1) хуҗа; 2) башлык (дәүләт, өлкә һ.б.); 3) хаким, дәүләт башлыгы; 4) патша; 5) җан. Маньчжур телендә *эзэн* – 1) хуҗа, хаким, хөкемдар; 2) әмер бирүче, боеручы, идарә итүче, феодал һ.б. Борынгы һәм хәзерге монгол, бүрәт телләрендә *әӡеп* – хуҗа, хакимлек итүче, әфәнде һ.б. Борынгы төрки телдә *ädi* ~ *idi* – хуҗа, ия.

Тунгус-маньчжур телләрендә хатын, хатыны мәгънәләрендә *асӣ* сүзе һәм аның дериватлары системалы

һәм актив кулланыла: эвенк. *аса̄ди, аһа̄ди, аша̄ди* – хатын-кызларныкы, *асэ̄* – хатын (хатынына эндәшү сүзе), *асӣ, аһи, аши* – хатын-кыз. Солон телендә: *аш'е* ~ *аш'ӣ* – хатын (эндәшү һәм атау сүзе). Эвен, негидаль, ороч, удэй, ульч, орок, нанай, маньчжур телләрендә дә шулай ук.

Ир туганнарга карата тунгус-маньчжур телләрендә *авус* атамасы да таралган. Эвенкий, эвен *авус, а̄вус* ~ *а̄у́с, а̄бос, а̄вса* һ.б. Негидаль *авус* – 1) җизни (апасының ире); 2) этисенең яки әнисенең сеңлесенең ире. Ороч *ауса* ~ *ауси* – 1) апасының ире; 2) хатынының энесе. Удэй *ауһи,* нанай *аоси* – кияү. Ульч *авси́* ~ *ауси́* – 1) кияү; 2) искергән мәгънәсе – нәселдәге теләсә кайсы хатын-кызга өйләнгән ир кеше.

Тунгус-маньчжур телләренең барысында да таралганга һәм мәгънә төсмерләре дә шактый киң булганга күрә, бу сүзне алынма дип карап булмый. Ул Себердәге кайбер төрки телләрдә күзәтелә торган *абыч* сүзенең тамырдашы булырга мөмкин. Аны татар телендә киң таралган *абыз* [Рамазанова, 1991, б. 43, 47–51, 12–121, 128 һ.б.; Татар теленең..., 2009] сүзе белән дә бәйләп карарга ярый кебек. *Абзый* (< абыз + -ый), *абысын* (< абыс + -ын) атамаларының да шул сүз нигезендә ясалган булулары бар.

Тунгус-маньчжур телләренә хас никах туганлыгы атамалары системасында тагын бер сүзне татар теленә мөнәсәбәттә карарга мөмкин.

*Ати* – карчык. Аның бик күп фонетик-морфологик төрдәшләре бар. Мәсәлән, эвенкий телендә *атки, акки, аски, а̄тки, аткинил, аткинул, аткинун һ.б.* – 1) каенана; 2) хатынының әнисе; 3) иренең апасы; 4) хатынының апасы. Ороч телендә *атаңа* – китерелгән мәгънәләрдән тыш: 5) хатынының абыйсының хатыны; 6) әнисенең апасы; 7) әнисенең абыйсының хатыны; 8) әби һ.б.

Күргәнебезчә, әлеге атама сөйләүчедән олырак яшьтәге хатын-кыз җенесеннән булган күптөрле никах һәм кан туганнарны белдерә, ягъни ул классификацион атама. Бу – хәзерге *әти* атамасының җенси яктан капма-каршы мәгънәгә күчүе нәтиҗәсе булса кирәк.

Кайбер туганлык атамаларының җенес ягыннан капма-каршы мәгънәдә кулланылуы төрки телләрдә, аеруча борынгы чорларда, шактый киң таралган күренеш [Рамазанова, 1991, б. 134–136; Ахметьянов, 1978, б. 141; Дульзон, 1954].

Гаилә берлеген тәшкил итә торган икенче зат – хатын төшенчәсе тунгус-маньчжур телләрендә дә шушы ук сүз белән белдерелә: Эвенкий телендә *катун* – 1) хуҗабикә; 2) фольклорда – батырның, каһарманның хатыны. Солон телендә аның дериваты күзәтелә: *катуђа́н* – кызый, кызыкай. Эвен телендәге *кату́уа* варианты – идарә итүче, хуҗа, бай, хотун – хуҗа, хатын. Тунгус-манчьжур телләренең чагыштырма сүзлегендә икесен дә якут алынмасы дип күрсәткәннәр. Негидаль телендә *катын* – старейшина, ыру башлыгы (шулай ук якут теленнән дип карала). Монгол телләрендә борынгы (*xatun*) һәм хәзерге (*хатан*), борынгы төрки телдә (*qatun*) – хуҗабикә, аксөякләр нәселеннән булган хатын-кыз, кенәз хатыны. Хатун сүзенең мондый мәгънә функциясе иске татар әдәбияты

әсәрләрендә («Кыйссаи Йосыф» һ.б.ларда), XVIII гасырга караган иске татар эш кәгазьләрендә [Фасеев, 1982, с. 63–148; Кол Гали, 1983, б. 136; Рамазанова, 1991, б. 91–92) дә чагылган.

Тунгус-маньчжур телләрендә никах туганлыгы атамалары системасында *кэли/кэлин* сүзе үзенчәлекле урын алып тора. Эвенкий, ульч, орок телләрендә – *кэли/кэлин;* нанай, ороч, эвен *кэли* – баҗа, баҗалар (бертуган хатын-кызларга өйләнгән ирләр бер-берсенә карата). Маньчжур телендә *кэли* – хатынының апасының ире. Негидаль *кэли* – 1) баҗа (бертуган хатыннарның ирләре бер-берсенә карата); 2) бер нәселдән хатын алган ирләр бер-берсенә карата.

Бу сүз төрки телләрдә киң таралган *килен* сүзенә кайтып кала. Әмма ул җенси яктан капма-каршы мәгънәдә. Бу хәл аның килеп чыгышы һәм җәмгыятьнең үсеш-үзгәреше белән бәйле рәвештә кичергән мәгънә күчешләре белән бәйле булса кирәк.

Шушы ук төркемдә *ина* сүзен дә карарга кирәк. Эвен *ина* – төрле нәселдән булган туганнан туганнар; *йнчй* – иргә хатынының, хатынга иренең ир яки кыз туганнары. Эвенкий. *инан* – 1) каената; иренең апа һәм сеңелләренең балалары; 2) бертуганның малае; *инана, инāна, инанај* – баҗа, баҗай (русчасы: свояк); негидаль *йна* – 1) хатын-кызның апаларының балалары; 2) ата ягыннан булган хатын-кыз туганнар; 3) әнисенең абыйсы; 4) иренең абыйсы. Орок *йна* – кияү, нан. *ѝнā* – иренең сеңлесе, маньчж. *ина* – кыз туганының улы.

Күргәнебезчә, *ина* атамасы ике система туганлыкка да карый: кан туганлыгына да, никах туганлыгына да. Икенче яктан, ул хатын-кыз туганнарны да, ир туганнарны да белдерә. Шулай итеп, әлеге атама (ина) туганлык системасы формалашуның бик борынгы баскычына – әле кабилә әгъзаларының яшь ягыннан (сөйләүчедән олырак яки кечерәкләргә) да, җенес ягыннан да (кан туганлыкка һәм никах туганлыгына) аерылмаган чорга хас туганлык системасын чагылдыра.

**Кантуганлык атамалары.** Татар телендәге **әни, ана**, диалектларда – *әнә, инә(й)* һ.б. Тунгус-маньчжур телләрендә *эн'ин* (ана) һәм аның тамырдашлары киң таралган: эвенкий телендә *эн'ин* – ана, *энн'и* – хатынының әнисе, *эн'ӣјэј* (диал. *ин'э энэ*) – *эни* – әнигә эндәшү сүзе; әнинең кыз туганына эндәшү сүзе, *эн'ин* – 'ана; 2) әнисенең кыз туганы. Солонча *энэ, эни* – ана; удэй телендә *эн'и-ни, эн'и-ти;* ульч телендә *эн'э;* орок телендә *эни(н);* нанайча *эн'ин;* маньчжур телендә *эн'э* – ана; ороч телендә *эни.* Негидаль телендә *эн'ин* 1) ана; 2) ана поши. Эвен телендә *эн'ин* – 1) ана; 2) әби (әнисенең яки әтисенең әнисе) һ.б. Борынгы төрки телдә *апа* – ана, якутларда. *ijä* – ана. Бу сүз корея телендә дә бар: *оин* < **он'и* – ана.

Татар *игәч* (диал.), эвенк. *экӣн*, удэй *эхи(н)* – 1) бертуган апа; 2) әтисенең яки әнисенең сеңлесе; солон телендә – 1) бертуган апа; 2) олы; эвен. *экэ̄* – 1) бертуган апа; 2) апа, түтәй, 3) әни; негидаль. *эгэ* – 1) бертуган апа; 2) апа, түтәй; *ороч эгэ* – 1) бертуган апа, 2) җиңгә (абыйсының хатыны); удей. *эхе* –

бертуган яисә туган тиешле апага эндәшү сүзе; ульч., нан. *эгэ* – апа; маньчж. *эјун* – бертуган апа. Кара: *ага/ака.*

Димәк, тунгус-маньчжур телләрендә *әкә* атамасы, беренчедән, күбесенчә аналар буынына карый, икенчедән, женси яктан капма-каршы мәгънәдә – хатын-кыз мәгънәсендә – урнашкан (чагыштыр: себер диалектларында – *әкә* – абый, ягъни, ир туганны белдерә).

Татар диал. **апа** – бабай, бабайның абыйсы яки энесе (мамадыш сөйләшендә). Тунгус-маньчжур телләрендә мондый янәшәлекләрне китерергә мөмкин: эвенкий телендә *эпо* – бабай, негидаль телендә *апо ~ опо ~ эпо* (диал. *апа ~ эпа*) – 1) бабай; 2) әтисенең абыйсы. Ороч телендә *эпэрэ* – 1) хатынының әтисе (чагыштыр: татар телендә *бабай* – шул ук мәгънәдә); 2) хатынының абыйсы; 3) апасының ире; 4) иренең әтисе; 5) әтисенең яки әнисенең абыйсы; әтисенең апасының ире. Орок телендә *э̄пи* – 1) бабай; 2) иренең әтисе, каената; 3) иренең яисә хатынының абыйлары. Маньчжур телендә *эфу* – җизнә (апасының ире).

Монгол телләрендә: язма монг. *евӥgен* – карт (исем), бабай, монг. *өвгөн* – карт (исем), *өвөг* – ата-бабалар; бүр. *үбгэн* – 1) карт (исем), 2) ир.

Эвенкий *авага* – абзый (русчасы: дядя), *аваүај* (< монг.) – әтисенең абыйсы яки энесе; сол. *аба̄* (< монг.) – ата; эвен. абагат – бабаң булу; удэй абууа ~ бууу – ата, эти; ата-ана;

Монг. *ав* – ата, эти, атакай; *авга эгч* – түти (ата ягыннан), абзый.

Тат. **абзый**. Эвенк. авус, эвен *а̄ву́с ~ а̄у́с, а̄бос, а̄вса* һ.б. – җизнә (бертуган апаның ире), абзый (әтисенең яки әнисенең сеңлесенең ире); негидаль *авуч* – шулай ук; ороч *аус'е ~ ауси* – җизнә (бертуган апаның ире); удэй. *Ауһи;* нан. *аоси* – кияү, җизнә; ульч. *авси́ ~ауси́* – 1) кияү яки җизнә, 2) үз нәселеннән өйләнгән теләсе кайсы ир .

Тат. **ага**, диал. *ака, әкә* һ.б. Эвенк. *ака̄,* эвен. *аңа*, нег. *ага, аха, ахау́,* ороч. *ака , аки,* ульч. *-аз, -аҡ, -аң,* маньч. *агу, аку* – абый, абзый (русчасы: брат, дядя). Монгол телләрендә: язма монг., бүр. *аха* – абый, абзый; бүрәт диалектында *ахадай* – үзеннән олы хатын-кыз туган, хатын-кыз. Бор.-төрк. *аqа* – абый. якутларда *аҕа* – 1) олы, өлкән; 2) ата; 3) үзеннән олыракларга хөрмәт белән эндәшү сүзе; 4) нәселдә баш кеше, праата; *аҕас* – 1) нәрсәнеңдер иң яхшысы; 2) өлкән (хатын-кыз турында); 3) үзеннән олырак һәм ата ягыннан булган хатын-кыз туган. Кытай телендә: *а̃гэ* – 1) абый; 2) әдәп белән, хөрмәт белән мөрәҗәгать итү сүзе.

Шунысын ассызыклап күрсәтергә кирәк, тунгус-маньчжур телләрендә төрки телләр белән уртак туганлык атамалары чагыштырмача аз күзәтелә. Аларда кытай теле белән уртак атамалар күбрәк. Шул ук вакытта тунгус-маньчжур телләрендә төрки телләр белән уртак булган *ана, ага* атамалары зур активлык күрсәтәләр, әлеге төркем телләрнең күбесендә төрле вариантларда күзәтеләләр, мәгънә үзенчәлекләре дә шактый киң, татар телен корея (*ана*), кытай (*ага*) телләренә үк тоташтыралар.

Тунгус-маньчжур телләрендә дә *мама* атамасының семантик

спектрының киңлеге игътибарны җәлеп итә. Ульч, нанай *мама*, ороч *мамач(н)* – 1) карчык; 2) хатын. Удэй *мама* – 1) әби, олы әби (прусчасы: рабабушка); 2) өлкән яшьтәге хатын-кыз (русчасы: тетка); 3) карчык. Маньчжур *мама* – 1) анакай; 2) әби; 3) карчык; 4) чәчәк (авыру исеме). Солон *мāма* – атакай (русчасы: батюшка).

Материаллардан күренгәнчә, тунгус-маньчжур телләрендә *мама* атамасы киң таралган һәм, нигездә, әбиләр буыны белән бәйле. Бу төрки атама һәм аның чулым төркиләре телендә [Дульзон, 1954, с. 79], үзбәк, уйгыр телләрендә дә кулланылуы билгеле [Задыхина, 1952, с. 415–416, 422], татар телендә дә кайбер сөйләшләрдә, Себер төбәге татар диалектларында таралган [Рамазанова, 1991, б. 22]. (Кара: [Колесникова, 1972] ам, ма→ мама).

Тунгус-маньчжур телләрендә *энин* (мать) атамасының антонимы *амã*/... (– ата) сүзе кулланыла: *ама* (сол., ороч, ульч, орок, маньч., нан., негид.), *амин* (уд.), *á-тіп* (чж.), *амã* (эвенк.). Эндәшү формалары: *амачан, амãка, амã* (эвенк), *амаj* (негид.) һ.б.

Китерелгән сүзләрнең өстәмә мәгънәләре дә бар: эвен. *амã* ~ әти, бабай (әти яки әнисенең атасы), эвенк. *амãкã* – 1) бабай (әти яки әнисенең әтисе), 2) әти яки әнисенең абыйсы; 3) баба, борынгы баба; 4) күчерелмә мәгънәдә: аю. Орок. *амака* – 1) бабай; 2) аю. Нанай, ульч телләрендә *ам* – кадерле, *ама* – әти. *Ама – эн'иэ* – ата-ана. *Аче* – кече (эндәшү формасы). *Ачи* (эвенк.) – 1) борынгы баба; 2) туганнан туган (ир туган). Сол. *ача* – ата. Язма монгол *ačі*, монг. *ач,* бүр. *аша* – оның, туганының баласы (русчасы: племянник). Борынгы төрки *atï* – сүзе дә шул ук атамалар белән мәгънәдәш.

**Гомумтуганлыкны белдерә торган сүзләр.** Тат. *ыру, ыру-кардәш, кардәш-ыру* һ.б. Эвенк. *урŷ*, эвен. *урỳ* (< якут) – туган, кардәшыру. Язма монг. *игиү* – нәсел, кабилә. Монг., бүр. ураг – хатын ягыннан булган туганнар, туган, туган-тумача. Бор. төрки. *игиү* – 1) орлык, төш; 2) нәсел. Якут *урӯ̃* – 1) туган, туган-тумача, туганлык; 2) туй; 3) үрчем, артым (нәсел турында).

Билгеле булганча, татар һәм, шулай ук күпчелек төрки телләргә хас туганлык атамалары системасында *ту*- тамырыннан булган сүзләр зур урын алып торалар, әлеге тамырның семантик кыры да бик киң [Рамазанова, 1992, б. 67–78].

Бу тамырның актив һәм төрле формаларда кулланылышы тунгусманьчжур телләренә дә хас. Мәсәлән: эвенкий *туүэн*, орок. *тувэмунэ,* ороч. *туа,* удей *туэхэ* – туганнан туган (ир туганнар, яисә кыз туганнар), солон телендә *тугэ̄ни* – туганнан туган (ир туганнар), негидаль *тувэн* ~ *туүэн* – 1) туганнан туган (ир яки кыз туганнар); 2) ана ягы нәселеннән булган хатын-кызларның балалары; 3) бер нәселдән булган хатын-кызларның балалары.

Шулай итеп, татар һәм бабаалтай чоры лексикасының үзара уртак яклары шактый табыла. Биредә тәкъдим ителгән беренчел характердагы күзәтүләр җитди тикшеренүләрне көтә.

ИСКӘРМӘ

[1] Күп кенә галимнәр үзләренең тикшеренүләрендә Җир шарындагы халыклар кайчандыр (мәсәлән, 11 мең еллар элек) бер булып яшәгәннәр, бер телдә аралашканнар, соңга таба аерылышып, мөстәкыйль үсеш-үзгәреш кичерә башлаганнар, дигән фикерне күтәреп чыгалар. Бу берлеккә семит-хәмит (Африка), картвель (Кавказ), һинд-европа (таҗик, фарсы һәм барлык европа телләре), дравидий (санскрит һәм һинд), урал (фин-угор, пермь телләре), алтай (тунгус-маньчжур, монгол, төрки телләр төркемнәре һ.б.) керә дип санийлар. Аларның барысы өчен дә уртак булган тел үзенчәлекләре һәм 1000 гә якын сүзне чагылдырган ностратик сүзлек (Иллич-Свитыч, 1971, 1976, 1984) басылып чыккан. Бу юнәлештә эзләнүләр дәвам итә һәм материаллар табыла тора.

ӘДӘБИЯТ


Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М.: Наука. 1978. 248 с.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Дүрт томда. I т. Бирск. 2005. 232 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука. 1969. 676 с.

Дульзон А.П. Термины родства и свойства в языках Нарымского края и Причулымья // Уч. зап. Томского гос. пединститута. Т.11. 1954.

Дыбо А.В. Семантическая реконструкция в алтайской этимологии: соматические термины (плечевой пояс). М.: Языки русской культуры. 1996. 389 с.

Задыхина К.Л. Ўзбеки дельты Аму-Дарьи // Тр. Хорезмской археолого-этнографической экспедиции. М. 1952.

Иллич-Свитыч В.М. Опыт сравнения ностратических языков (семито-хамитский, картвельский, индоевропейский, уральский, дравидийский, алтайский). М. Т. 1, 1971. 370 с.; Т. 2, 1976. 156 с.; Т. 3, 1984. 135 с.

Колесникова В.Д. Названия частей тела человека в алтайских языках // Очерки сравнительной лексикологии алтайских языков. Л.: Наука, Ленингр. отд-ние. 1972. С. 71–103.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Казан. 1983. 543 б.

Лыткин В.И. Исторический вокализм пермских языков. М.: Наука. 1964. 270 с.

Материалы по татарской диалектологии. Вып. 4. Казань. 1978.

Махмутова Л.Т. Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику СС по данным лексики // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Вып. 2. Казань. 1982. С. 68–153.

Покровская Л.А. Термины родства в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М.: Наука. 1961.

Рамазанова Д.Б. Общие особенности говора пермских татар со старотатарским литературным языком // Истоки татарского литературного языка. Казань. 1988. С. 88–99.

Рамазанова Д.Б. Термины родства и свойства в татарском языке. В двух кн. Казань. 1991. 191 с.

Рамазанова Д.Б. Корень *ту-* (< *тоү*) в татарском языке // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань. 1992. С. 67–78.

Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков: Материалы к этимологическому словарю. Л.: Наука, Ленингр. отд-ние. 1975. Т.1. 672 с.; Т. 2. 992 с.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр. 2009. 839 б.

Фасеев Ф.С. Старотатарская деловая письменность XVIII века / Сост. Ф.С. Фасеев. Казань. 1982.

Toivonen Y., Itkonen E., Joki A. Suomen kielen etymologinen sanakirja. I–III. Helsinki. 1955–1962. S. 257.



***Рамазанова Дария Бәйрәм кызы***, филология фәннәре докторы,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
лексикология һәм диалектология бүлегенең баш фәнни хезмәткәре

УДК 811.512.145'373

# БИШЕК ТУЕ ЛЕКСИКАСЫ (этнолингвистик аспект)

*Ф.С. Баязитова*

Термины родильных обрядов отражают древние верования, воззрения и этногенетические связи с другимим народами, так как большинство из них относится к древнейшему словарному фонду языка и представляют большой интерес для лингвистики и фольклористики.

**Ключевые слова:** этнолингвистика, обрядовая лексика, родильный обряд, родины, колыбельные.

Бала туу белән бәйле булган борынгы йолалар һәм аларга караган сүзләр, буыннардан-буынга күчеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Тел белгечләре аларны бик кадерле җәүһәрләр итеп санап, тел байлыгы белән бергә бөртекләп туплап барырга тырышалар.

Татар телендә бала туу белән бәйле булган йолаларның лексикасы фәнни әдәбиятта чагыштырмача азрак өйрәнелгән тема булып тора. Һәрхәлдә, махсус бу темага карата мәкаләләр һәм монографияләр язылмаган диярлек. Бу бик борынгы катламны күтәрү татар халкы яшәгән барлык төбәкләргә экспедицияләргә чыгып, бик күп авылларда булып, өлкән буын кешеләренең хәтерендә, телендә сакланган рухи байлыкны барлап, өйрәнеп чыгу юлы белән генә хәл ителергә мөмкин. Бу беренче чиратта башкарылырга тиешле әһәмиятле мәсьәләләрдән санала.

Шуңа күрә традицион культураны өйрәнүдә җирле сөйләшләр төп таяныч итеп алына. Минем үземә, Татарстанда гына түгел, көнбатышның Рязань өлкәсеннән алып, көнчыгышның Томск, Кемерово өлкәләрендә, төньяктагы Нократтан алып, көньяктагы Әстерхан, Волгоград өлкәләрендә булырга һәм алардагы татар сөйләшләреннән дә этнолингвистик материаллар туплап кайтырга насыйп булды.

Билгеле булганча, халык йолалары лексикасын йоладан аерып карау мөмкин түгел. Өлкән буын кешеләренең хәтерендә, телендә әле борынгы йолаларыбыз турында бик күп истәлекләр саклана, кайберләре исә бүгенге көндә дә йола булып үтәлеп киләләр.

Бала тугач, гаиләнең бәхетен, туганнарының шатлыгын уртаклашу – бик борынгыдан килгән йола. Авылларда сакланып килгән җирле сөйләшләрдә бала тудыру үзе дә төрлечә аталып йөртелә. Мәсәлән, мишәр диалекты сөйләшләрендә – **бала түрәү,** Әстерхан, Пермь һәм

Башкортстандагы татарлар сөйләшендә **бала асрау** сүзләре дә кулланыла. **Бала биләү** – балалы булып гомер итү. «Балалар биләп, бәхетле гомер иттем», – дип сөйләшәләр.

Элекке вакытларда, беренче бала тугач, сөенечле хәбәрне халыкка ирештерү өчен, берәр кешене авыл буйлап чыгарып җибәрә торган булганнар. Иң беренче сөенчене, гадәттә, каенанадан алганнар. Сөенче хәбәре белән килгән кешегә, борынгы йола буенча: «Бала йомырка кебек тәгәрәп үссен», – дип, йомырка биргәннәр.

Бала тапкан хатын, ягъни бәби анасы, әлеге гаиләнең һәм күршекүләннең иң кадерле кешесенә әйләнгән, аңа сый-хөрмәт күрсәткәннәр, урыны да аның түрдә булган.

«Бала тапкан хатынның өенә кереп хәлен белә алмасаң, морҗасына кара. Төтен чыкканын күрсәң дә бик зур савап», – дигәннәр.

Әстерхан өлкәсе татарлары болай сөйлиләр:

– Бала асраган (*тудырган*) хатынны, баланың кырыгы тулганчы, аш-суга якын җибәрмиләр, авыр эшләр эшләтмиләр. Каберстанның авызы ачык торыр, ди; бала табу җиңел эш түгел шул, кырыгыннан чыкканчы казан-аяк астырырга ярамый.

Бала тапкан хатынга туган-тумача да, күрше-күлән дә «бәби ашы» илткән. Гадәттә, өйдә пешкән әлбә, чәкчәк, бавырсак, бәлеш, коймак кебек милли ризыклар матур савытларда, кызыл ашъяулыклар белән төреп китерелгән. Казан арты төбәкләрендә бәби ашына дип, борынгыча **әлбә** пешергәннәр:

– Әлбә пешереп алып килә хәл белә килгән кеше; май белән, шикәр белән тугылап, әлбә пешерәләр.

Мишәр диалекты сөйләшләрендә бәби ашына **чумар** пешерүне дә истәлек итеп сөйлиләр:

– Бездә, бала тугач, чумар китерәләр. Чумарга катык, каймак каталар. Шул чумарны ашаталар балага сөт булсын, ана хәл алсын, дип.

Шулай ук **сөтләш** (ягъни сөттә пешкән ботка) тә бәби анасын зурлап пешерелә торган булган:

– Сөтләш китерәләр. Аның уртасына күз ясап, май салып алып киләләр. Китерелгән көенә, җылы көенә бәби анасына ашаталар.

Әстерхан өлкәсе татарлары бала тапкан хатынга **майболамык** (майга он болгатып пешерелгән боламык) ашаталар:

– Биш бала таптым, бишәвенә дә май боламык пешертте әни.

Билгеле булганча, элекке вакытларда хатыннар баланы өйдә, кендек әбиләр булышлыгы белән тудырганнар. Бала туу билгеләре, тулгак тоту (мишәр диалектында *кисү алу*, диләр) башлангач та кендек әбине алып килгәннәр. Кендек әбиләрне авылларда зурлап, олылап йөрткәннәр. Атамалары да һәр якта үзенчә: **кендек әби, кендекәй, олан әбисе, бәбәй әбисе, түти әби, әби тәтә, әби әңкә, инәлек корткаяк, мамай, авыл әбисе** һ.б.

Себердә яшәүче татарлар болай дип әйтәләр:

– Балага, авырып китсә, инәлек корткайакны алып киләләр. Инәлек – зур кеше, аны бик кадерлиләр. Инәлек өйгә килеп керсә, өйдәге аркалык (*матча*) иелеп китәр, диләр.

Кендек әби баланы һәм ананы караган, тәрбияләгән, мунча керткән. Ул өенә кайтып китәсе көнне «әби озату» дип атаганнар һәм аны,

күрше-күләнне чакырып, чәй мәҗлесе ясап, озатканнар.

Кендек әбинең вазифалары күп. Мәсәлән, ул баланы салават (изге, мактаулы догалар дигән сүз) әйтеп авызландыра.

Ата-ана йоласы,
Пәйгамбәрләр догасы.
Бәхетле бул,
Тәүфикълы бул, –

дип кабатлый-кабатлый, баланың авызына бал тидерә.

Халыкта шундый ышану да бар; «Кем авызландырса, бала шуңа охшап үсә» янәсе.

Кендек әбисе бәбинең кендеген кисә һәм җыеп куя. Әстерхан өлкәсе татарлары бу турыда болай дип сөйлиләр:

– Кендеген кисә, юындыра. Кендекне ак чүпрәккә бәйләп, бишекнең почмагына югарыга элеп куя: «Бала үскәндә өйдә булсын, каңгырып йөрмәсен, өйдән чыкмасын» янәсе.

Себер татарлары баланың кендеген әйбәтләп төреп, аркалыкка (ягъни *матчага*) кыстырып куялар. Яз көне, иген чәчкәндә, аны җиргә күмәләр:

«Ашымның (*игенемнең*) уңышын бир», – диләр.

Кендек әбиләр бәбине дә, бәби тудырган хатынны да мунча кертәләр, ана белән баланы юындыралар.

Иң алдан баланы юалар. «Әйдәгез, бәбәй мунчасы», – дип, әбиләрне дә дәшәләр. Бәбәй мунчасын котлап, йомырка, сабын, коймак китерәләр.

Беренче мунчада бәбине юындырганда кендек әбиләре төрле ырым сүзләре әйтеп баланы чабындыралар. Менә Пермь крае татарларыннан язып алынган ырым такмаклары:

Аю баласын чабам,
Бүре баласын чабам.
Аю кебек симез бул,
Бүре кебек җитез бул,
Көндез уйна, кич йокла,
Бәхетле бул, тәүфикълы бул.
Әйшә-Батман (*Гайшә-Фатыйма*) куллары –
Име-йомы шул булсын, –

дип, бәхет сорап чапканнар баланы.

«Олан чапкан яфракны өч юл аермага ыргытабыз», – диләр.

Монысы – тау ягы (Апас районы) сөйләшеннән язып алынган ырым сүзләре:

Әби-бабай мунчасы
Җан тынычы бирсен,
Көн тынычы бирсен,
Яфрак кебек ярпайсын.
Колмак кебек кабарсын,
Борчак кебек тәгәрәп йөрсен,
Куян кебек сикереп йөрсен,
Каен кебек үссен.

Бала тугач, берникадәр вакыт үткәннән соң, туганнарын, дусларын, күршеләрен чакырып, бала котлап, зур мәҗлес үткәрәләр. Ул мәҗлесләр татар сөйләшләрендә түбәндәгечә атала. **Бәби мае** – казан арты, мишәр диалекты сөйләшләрендә:

– Бәби маена җыялар. Бәби маена дип бүләк сала, аш, бәлеш, бал-май куялар. Бәби маена бардым әле, – дип сөйлиләр.

**Бәби туе, бәби боткасы** – тау ягы сөйләшендә:

– Аш-боткалар пешереп барганнар бәби боткасына, бәби туена. Түр башында олан әбисе утырган.

**Бәби чәе** – касыйм, сергач сөйләшләрендә:

– Күрше хатыннары бөтен бәлеш белән киләләр бәби чәенә.

«Бәлеш белән киләм, каршы да чыкмыйсыз, – диләр.

– Бәбәй чәенә ястык, мендәр китерә. Мендәр китерсә, почмагына көмеш тәңкә бәйли. Көмеш кебек ялтырап торсыннар янәсе.

Бәби туена килгән кунаклар бала котлап бүләкләр дә алып киләләр.

Себер диалектларында бала котлап бирелгән бүләкләрне **савын** дип әйтәләр:

– Бала котлокка савын алып барасың хәлеңнән килгәнчә: күлмәкләр, юрган. Олы кызыбыз бәбәйләгәндә сыерыбыз бозаулаганые. «Бозау үсеп мал булса – кызыбызга», – дип ниятләдек.

Татар телендә бишек атамалары, бишек йолалары бик кызыклы.

«Тал бишек» дигән шигырендә Р. Миңнуллин болай дип яза:

Бездә бишек әллә ничек –
Талдан, җырдан үрелә.
Җырлы бишек, җылы бишек
Эленә өй түренә.

«Татар өендә бишек, гадәттә, түр башында тирбәлә, өй эчендәгеләрнең бөтен игътибары шул бишектә – якты өмет-хыяллар да, гасырлардан килгән җыр-моң да, елмаюлар да, күз яшьләре дә... Бишекле өйнең эче нурлы, бишекле өйдә җыр-моң өзелми. Бишекле өйнең киләчәге бар! Ә бишек янында – Ана! Шул моңнарның, җырларның чыганагы, бетмәс-төкәнмәс чишмәсе – Ана күңелендә. Ана! Бала! Бишек! Менә шушы өч изге сүзгә җыр-моңның узганы, бүгенгесе һәм киләчәге сыеп беткән түгелме?!» [Миңнуллин, б. 399].

**Бишек бирнәсе** – нократ сөйләшендә: бала котлап китерелгән бүләкләр.

– Беренче бала тугач, кыз анасы, кызның дуслары бишек бирнәсе китерәләр. Бәбәйгә күлмәк, юрган, чыбылдык, көрпә, мендәр китерәләр.

**Бишек җыры** – халыкның рухи байлыгының иң якты чагылышы, шул ук вакытта ул һәр ананың үз баласы өчен генә көйләгән йөрәк җыры.

Сабый баланы йоклатканда бишек җырын әби дә, бабай да, әтиәни дә, апа-абыйлар да җырлыйлар. Ләкин ул җыр эчендә яшеренеп яткан тирән серләрне беләләр микән? Бишек җырына бала изрәп йоклап китә. Чөнки йөрәктән чыккан назлы моңда тылсымлы көч бар. Ул йоклату чарасы гына түгел, дога кебек, баланы шифалы аура белән урап ала, тынычландыра, күз тиюдән, тискәре дулкыннардан саклый, көй белән яңгыраган теләкләрнең баланың киләчәгендә гамәлгә ашуына ышаныч бар. Халыклар, үз тәҗрибәләренә, күзәтүләренә таянып, бишек җырының аерым ритмик шигъри төзелешен барлыкка китергәннәр.

Тирән мәгънә саклаган бишек җырларын хәзерге галимнәр дә өйрәнәләр. Төмән дәүләт университетының Гуманитар эзләнүләр институты филология кафедрасының мөдире, филология фәннәре докторы Ирина Карабулатова бишек җырларын фәнни нигездә өйрәнеп, аларның бала организмы ритмнарын җайга салу сәләтен ачкан. «Бишек җыры, – ди ул, – фольклорның гади көнкүрешебез белән югары сәнгатьне тоташтыра торган уникаль жанры» [Карабулатова, б. 16].

Сөекле шагыйребез Г. Тукайның «Бишек җыры» да бик күптән инде барлык төбәкләрдә татар халкының

үзенеке булып, балага изгелек, яхшылык, гыйлемлек теләү булып сеңеп калган:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Әстерхан татарларында бигрәк тә үзенчәлекле итеп үткәрелә торган бишек туйларын күрү насыйп булды. Кундрау авылында яшәүче Гыйләҗева Фатыйма апа сөйли:

– Бишек туена кыз анасы үзенең бөтен булган туган-токымын җыеп килә. Бәбәйгә кием алып киләләр, пылау пешерәләр, бүләк өләшәләр. Әстерхан сөйләшендә кендек әбисен «мамай» дип әйтәләр, баланы бишеккә салып, мамайдан такмак әйттерәләр. Ул баланың атасын, анасын, әбисен мактый. Ефәктән чыбылдык корып, такмак әйтәләр. «Бәхетле бала туды, батыр булып үс, матур булып үс, атасы йахшы, анасы йахшы», – диләр.

Баланың бишегенә манит (тәңкә) салалар. Түрдә утырган хатын бишекнең тишегеннән кунакларга бавырсак өләшә.

– Бишек туенда тагын баланың өстенә якалы кием ябалар, җиде кешенең якалы җиде киемен ябалар. «Яхшы булсын, ару булсын, яхшы кешеләрдән үрнәк алсын, сау булсын», – дип.

Бишек туенда халык таралыр алдыннан кендек әбисе баланы тирбәтеп көйләп куя:

Йөгерә-йөгерә йөргәндә
Тәбәнәк курай кермәсен.
Кечкентәй генә кызыма
Халыкның күзе тимәсен.

Бишектәге бала – гаилә бәхете, өмете һәм киләчәге. Бәхетле гаиләдә – бала да бәхетле. Г. Тукай язганча:

Бәхетле нарасидә! Тар бишек тә киң
эле аңар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң
эле аңар!

Гомумән, бала тууга бәйле йолалар лексикасы гаҗәп бай һәм кызыклы. Ул халык иҗаты белән, борынгы мәҗүсилек чорларыннан ук калган ырымлау, им-том сүзләре белән дә үрелеп барган. Шулай итеп, халыкның рухи һәм матди тормышындагы үзенчәлекләрне үзенә сеңдерә-сеңдерә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Алар гасырлар тирәнлегеннән килгән рухи байлыкның бер чагылышы буларак, фәнни яктан тирәнтен өйрәнелергә лаек.

ӘДӘБИЯТ


Баязитова Ф.С. Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе, фольклор. Казан: Фикер, 2002. 298 б.

Баязитова Ф.С. Халык традицияләре лексикасы: бишек туе (Йола һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан, 2012. 331 б.

Карабулатова И.С. Региональная этнолингвистика: Колыбельная песня тюркских народов Тюменьской области. Тюмень, 2003. 23 с.

Миңнуллин Р. Сайланма әсәрләр: балалар өчен шигырьләр, әдәби тәнкыйть, иҗат портретлары, рецензияләр: II китап. Казан: Мәгариф, 2004. 399 б.


***Баязитова Флера Сәет кызы***, филология фәннәре докторы,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
лексикология һәм диалектология бүлегенең баш фәнни хезмәткәре

УДК 811.512.145'366

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ФИГЫЛЬНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ФОРМАСЫНДАГЫ КАБАТЛЫЛЫКНЫҢ АСПЕКТУАЛЬ МӘГЪНӘЛӘРЕ

*Г.Ф. Лотфуллина*

Статья посвящена исследованию потенциала формы настоящего времени татарского языка в реализации аспектуальных значений. *Хәзерге заман* оказывается способным реализовывать частные значения кратности в соответствующих контекстуальных условиях, что является доказательством неограниченности его количественного аспектуально-темпорального значения длительности.

**Ключевые слова:** аспектуальность, темпоральный контекст, кратность, семельфактив, презенс.

Аспектологик теория, аспектуаль мәгънә чагылышы күзлегеннән караганда, фигыль формасының төрләрен билгеләү бурычын үти. Бездә аерым мәгънәви төшенчәләр белән бәйле кыенлыкларны читләтеп үтү гадәткә кергән, ягъни икенчел дәрәҗәдәге үзенчәлекләр еш кына исәпкә алынмый. Бу мәкаләдә кабатлаулы фигыльнең күләм-кабатлылык йогынтысы ысулларына нигезләнгән аерым аспектуаль мәгънәләрен куллану очраклары анализлана.

Татар телендә аспектуаль мәгънә җөмләдә үзара тәэсир итешүче төрле дәрәҗәдәге чаралар белән белдерелә, ул чаралар фигыльнең йогынты ясау ысулларының гомуми категорияләре кысаларында берләшәләр. Бу хезмәтнең максаты – кабатлылыкның аспектуаль мәгънә үтәүдә хәзерге замандагы фигыль формалары потенциалын билгеләү.

Бүгенге көндә татар телендә хәзерге заман формаларын куллануның түбәндәге төп очраклары аерып күрсәтелә:

1. Гадәти, типик яки кабатланып килә торган эш-хәрәкәтне билгеләү: *Ел саен бер тана, җиде-сигез баш сарык суялар;*

2. Сыйфат ягыннан хәзерге мәгънәсен, ягъни кайсы да булса затның яки предметның даими билгесе, үзенчәлеге буларак аңлашыла торган эш-гамәлне билгеләү: *Ул сүгенә, тарта, эчә, сугыша, бу хакта үзе сөйләде, хәтта «сугышырга ярамам» дип сөйләде*;

3. Бер үк вакытта сөйләү моментында барган эш-хәрәкәтне белдерүче хәзерге актуаль (хәзерге конкрет) заманны белдерү: – *Сез ни сөйлисез! – диде стенографист кыз;*

4. Узуаль эш-хәрәкәтнең әһәмиятен чагылдыру: *Тормышыма кирәкне хәләл көчем белән табам...;*

5. Контексттан чыгып, хәзерге заман формасы киләчәккә планлаштырылган максатны, төгәлрәк әйткәндә ниятне, аңлатырга мөмкин: *Туйдан соң кибетне сатам да Көнбатышка китәм – анда иске гаепләрнең калкып чыгу ихтималы азрак булыр, дип уйлыйм* [Гильфанова, 2005, с. 13]. М.Н. Закамуллина хәзерге заман формасын морфологик яктан ешрак кулланыла торган һәм экономиялерәк форма буларак карый [Закамуллина, 1999, с. 34]. Хәзерге заманның системалы темпораль мәгънәсе контекстта төрле дәвамлылыктагы эш-хәрәкәтнең семантик төсмерләрен, аның типиклыгын, кабатланучанлыгын һ.б. ны чагылдырырга мөмкин [Харисова, 2010, б. 24; Хисамова, 2004, б. 234]. Татар грамматикасы канунлаштырган фикердән чыгып, татар телендә хәзерге заманның семантик потенциалы, хәзерге заманның махсус өстәмә формалары кулланылган башка төрки телләр белән чагыштырганда, шактый киң булып санала [Татарская..., 1997, с. 103–106]. Татар тел фәнендә кабатланып килгән эш-хәрәкәтне чагылдыруда бу форманың өстенлеге эш-хәрәкәтнең төрле интерпретацияләрендә: өзлексез яки регуляр репрезентациядә [Ганиев, 2000, с. 87], үзлеген һәм торышын гәүдәләндерүдә [Серебренников, 1963, с. 7], кабатланып кулланылуында [Тумашева, 1986, с. 31], характерны яки закончалыклы рәвештә кабатланучы гадәти эшне чагылдыруда [Хисамов, 2004, б. 45], хәзергенең эзлеклелегендә [Салехова, 1975, с. 24], предметның гадәтилеген яки үз гамәлен башкару сәләтен күрсәтүдә [Нуриева, 1961, с. 81], даимилекнең, бер-бер артлы кулланылуның яки кабатлануның семантик төсмерләрендә [Харисов, 1944, с. 83] гәүдәләнә.

Бу заман хәзерге планда эшхәлнең билгеле вакытка беркетелгәнлеген белдерә. Сөйләү моменты белән бер үк вакытта башкарылган (симультантлыкны), яки сөйләм моментыннан соң дәвам итәчәк яки эшләнәчәк мәгънәләрне билгели ала. Әлеге формадагы транспозициянең мөмкинлекләре теләсә кайсы вакыт аралыгында аның заман чикләреннән тыш локальләштерү функциясе белән яраша. Чиксез аспектуаль-темпораль дәвамлылык мәгънәсе хәзерге заман фигыль синтагмасыннан аңлашылган ситуациянең интервалын билгели алмый.

**Кабатлану** – ул эш-хәрәкәтне башкаруның бер ысулы. Фигыльләрдә дәрәҗә-ысул категориясе мәгънәләрен заман формалары ярдәмендә белдерәләр.

**Беренче яки соңгы эше / хәрәкәте белән чикләнгән күп мәртәбәләр кабатлаулы эш-хәрәкәт мәгънәсенең** (кабатланган эш-хәрәкәтләрне бер яктан чикләү) (2, 3) маркерлары баштагы яки соңгы эшхәрәкәттә булган интервалны күздә тота. Алар, тәмамланган (чикле) фигыльләр мәгънәсенә ярашып, интервал вакытының чикле булуын [*билгеләнә* (2), *катнашырга* (3)] һәм эшнең тәмамланганын белдереп, хәзерге заман формасының дуративлыгын юкка чыгара. **Семельфактив** (бер мәртәбә булган эшхәрәкәт) очрагында да шуңа охшаш ситуация күзәтелә. Вакыт формасының дуративлыгы (1) мисалда кинәт килеп туган хәлдән [*кинәт*

(1)], шулай ук семельфактив мәгънәне еш ачыклап килгәнлектән һәм, җае килгәндә, терминатив мәгънәне аңлаткан, дуратив булмаган аналитик структураның [*кабынып киту* (1)] чик семантикасын белдергәнлектән үз асылын югалта.

**Билгеләнгән интервал эчендә билгесез мәртәбәләр кабатлаулы эш-хәрәкәт мәгънәсе** билгеле бер күләмдәге мәгънәви комбинацияне [*бер* (4)] һәм интерваллыкны [*елга* (4)] тәшкил иткән күпкомпонентлы маркер ярдәмендә белдерелә, ягъни акциональ семантикадагы *көнгә ике тапкыр, елга бер тапкыр* дигәнне аңлата торган, кабатлының иске мәгънәсен тагын да ачыклый төшкән характеристикалы төшенчәләр күздә тотыла.

**Билгеле мәртәбәләр кабатлаулы эш-хәрәкәт мәгънәсен белдерү өчен** чикле дәвамлылык маркерын куллану урынлы түгел: *Ул ишекне биш тапкыр ача*, яки семантика күчеше (үзгәреше) барлыкка килә.

(1) Кинәт мотор *кабынып китә* [Рәкыйпов, 2000, б. 31]. (2) Соңгысына командир итеп Евдокия Давыдовна Бершонская *билгеләнә* [Рәкыйпов, б. 11]. (3) ...менә без үз гомеребездә беренче мәртәбә күмү процессында *катнашабыз* [Мәһдиев, 1996, б. 152]. (4) Яңа ел бәйрәме елга бер генә *килә* [Вәли-Барҗылы, 2000, б. 42].

Билгесез кабатлының асылы – эш-гамәлләренең чикләнмәгән күләмдә булуына һәм чиксез дәвамлылыкның күләм-сыйфат темпораль-аспектуаль мәгънәсенә, ягъни эш-хәрәкәтнең өзлексез чагылышына туры килүеннән гыйбарәт. **Билгесез күп мәртәбәләр кабатлаулы эш-хәрәкәт һәм гадәти эш-хәрәкәт мәгънәсе** (билгесез-итератив һәм фреквентатив) хәзерге заман фигыленең иң киң таралган һәм гадәти кулланылган мәгънәләренең берсе. Хәзерге заман формасы шушы минутта гамәлдә булган көндәлек (актуаль) гадәтне дә, гомумән эш-гамәлләрнең күнегелгән (гадәтләнгән) мәгънәсен дә аңлатырга мөмкин. Вакыт формасының дуративлыгы [*очарга* (5)] чиксезлекне белдергән фигыль дуративлыгы һәм чиксез кабатлану маркерлары [*туктаусыз* (5), *кайвакытта* (6), *еш-еш* (8) яки *гадәттәгечә* (7) фреквентативлыгы] белән яраша, алар эш-гамәлнең бер генә мәртәбә кабатлану дәвамлылыгын һәм кабатлану процессының чикләнмәгән вакыт дәвамында баруын үзара бәйлиләр. Дуратив булмаган аналитик структура *сөйрәп чыгарырга* (6), *озатып калырга* (7) мисалындагы чик семантика белән терминативлыкның үзе белән янәшә килгән сериядәге бердәнбер йогынтыны аспектуаль мәгънәгә әйләндерә.

(5) Кызлар көне буе туктаусыз *очалар* [Рәкыйпов, б. 18]. (6) Тәмәкене телгә алганда, бу кеше автомат рәвештә кесәсенә кулын тыга, кайвакытта янчыгын да *сөйрәп чыгара* [Мәһдиев, б. 150]. (7) Кызларны гадәттәгечә полк командиры үзе *озатып кала* [Рәкыйпов, б. 44]. Башы аска иелгән, үзе еш-еш *сулый* [Рәкыйпов, б. 51].

Хәзерге заман формасының рәвештән башка гына килгән (9, 10) фигыль дәвамлылыгы һәм кабатлаулылыгы кебек аспектуаль төсмерләрен чагылдыру мөмкинлекләренә безнең ил галимнәре тарафыннан

игътибар аз бирелә. Чикләнмәгән мәгънәне аңлатучы фигыльләр семантик яктан хәзерге заман формасының чикләнмәгән дәвамлылыгы мәгънәсе белән ярашалар, кабатлының фигыльдән тыш маркерлары булмаганда, алар эш-хәрәкәтнең күп төрле йогынтысын аңлаталар: *Ул җырлый*. Вакытны белдергән форманың дуративлыгы, кабатлаулылыкның ноль дәрәҗәсендәге маркеры очрагында, акциональ перфиктивлыкка бәйле **билгесезлек итеративлыгы** мәгънәсенең чиклелеген аңлаткан фигыль белән үзара бәйләнешкә керә: *Ул безне күрергә килә*. Күп мәртәбәләр кабатлаулы эш-хәрәкәт мәгънәсен хәзерге заман формасы үзе генә белдерә ала.

(9) Асалар, кисәләр, терелә җиргә *кумәләр* [Рәкыйпов, б. 33]. (10) Сөйләшкән тавышлар *ишетелә* [Рәкыйпов, б. 21].

Димәк, татар телендә хәзерге заман фигыль формасы башка чаралар ярдәмендә кабатлылыкның (билгеле-чикле кабатлылыкны исәпләмәгәндә) билгеле һәм билгесез мәгънәләрен актуальләштерергә сәләтле. Бу форманың функциональ кулланылышы күп очракта билгесез кабатлылыкның йогынты ясау дәрәҗәсенә бәйле.

ӘДӘБИЯТ


Вәли-Барҗылы М. Мәхәббәт мәңгелек. Казан: Мәгариф, 2000. 240 б.

Ганиев Ф.А. Татарский язык: проблемы и исследования. Казань: Татар. кн. изд-во., 2000. 432 с.

Гильфанова Д.Р. Темпоральность художественного текста на материале английского и татарского языков: автореф. дис. … канд. филол. наук. Тюмень, 2005. 21 с.

Закамулина М.Н. Аспектуальность в татарском и французском языках. Казань: Магариф, 1999. 128 с.

Мәһдиев М. Кеше китә, җыры кала. Казан: Татар китабы, 1996. 270 б.

Нуриева А.Х. Система спряжения глагола по категории времени в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1961. 21 с.

Ракыйпов Ш. Кызлар – йолдызлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 464 б.

Салехова Н.Х. Грамматическая категория времени татарского глагола и темпоральность: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1975. 185 с.

Серебренников Б.А. Система времен татарского глагола. Казань: Изд-во КГУ, 1963. 76 с.

Татарская грамматика. Т. 2. Морфология / ред. колл. М.З. Закиев, Ф.А. Ганиев, К.З. Зиннатуллина. Казань, 1997. 398 с.

Тумашева Д.Г. Татарский глагол (Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий): учеб. пособие. Казань: Изд-во КГУ, 1986. 190 с.

Харисов А. Категория глагольных видов в башкирском языке. Уфа: Башкирск. гос. изд-во, 1944. 91 с.

Харисова Ч.М. Татар теле. Морфология: югары уку йортлар өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2010. 126 б.

Хисамова В.Н. Глагольная система татарского и английского языков: сопоставительный анализ в аспекте изучения английского языка на базе родного (татарского) языка. Казань: Изд-во КГУ, 2004. 252 с.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф, 2006. 334 б.



***Лотфуллина Гөлнара Фирдәвес кызы***, филология фәннәре докторы,
Казан дәүләт энергетика университетының чит телләр кафедрасы профессоры
e-mail: gflutfullina@mail.ru

УДК 811/512/145'367

# ШАРТ МӨНӘСӘБӘТЕНЕҢ СӘБӘП-НӘТИҖӘ ҺӘМ ВАКЫТ МӘГЪНӘСЕ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

*Л.Г. Вәлиева*

В статье рассматривается взаимосвязь условных отношений с причинно-следственной и темпоральной семантикой в татарском и некоторых других тюркских языках.

**Ключевые слова:** кондициональность, каузальность, временные отношения, условно-следственные отношения, условно-временная семантика.

Хәзерге тел белемендә төрле тел күренешләренең семантикасын фәлсәфи, логик, психологик карашларны исәпкә алып анализлауга зур игътибар бирелә. Әлеге өлкәгә кызыксыну артуны мәгънәви мөнәсәбәтләрне өйрәнүнең телнең коммуникатив асылын ачарга мөмкинлек бирүе белән аңлатырга була. Бу юнәлештә синтаксик берәмлекләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең мәгънә төсмерләрен һәм белдерелү үзенчәлекләрен комплекслы тикшерү мөһим санала, чөнки нәкъ менә телнең синтаксик төзелешендә уйлау, фикерләү категорияләре бик тулы ачыла.

Синтаксик берәмлекләр арасындагы бер төр мәгънәви мөнәсәбәтләр икенче төр мөнәсәбәтләр белән тыгыз бәйләнештә торалар. Еш кына бер үк формаль күрсәткечләр төрле мөнәсәбәтләрне белдерү өчен хезмәт итә һәм, шуңа бәйле рәвештә, аларны аеруда кыенлыклар туа. Әлеге мәкаләдә шарт мөнәсәбәтенең сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт мәгънәсе белән бәйләнеше тикшерелә.

Шарт фәлсәфи планда сәбәп категориясе белән тыгыз бәйләнгән. Шарт, сәбәп кебек үк, нәтиҗәдән алда булган вакыйганы белдерә. Сәбәп-нәтиҗәнең тормышка ашырылуы билгеле бер шартларга бәйле. Шарт үзе нәтиҗә тудыра алмый, ә аның барлыкка килүе өчен фон ролен генә үти. Төрле шартларда бер үк сәбәп төрле нәтиҗәгә китерә [Философский энциклопедический словарь]. Шарт белдерүче конструкция ике компоненттан тора һәм берсенең тормышка ашуы яки ашмавы тулысынча икенчесенә бәйле була.

Мисалларны анализлаудан күренгәнчә, шарт наклонениесе формасы каузаль мөнәсәбәт белдерүдә кулланыла ала. Мәсәлән: *Битең кызыш**са**, **димәк**, сине яманлыйлар* (Ышану), *Колагың чыңла**са**, **димәк**, сине сөйлиләр* (Ышану).

Югарыда китерелгән җөмләләрдә, нәтиҗәне ассызыклап, *димәк*

сүзе килгән. Логик яктан караганда, шарт наклонениесе күрсәткече (*-са/-сә*) монда шарт мәгънәсен белдерми, чөнки бит кызышу яки колак чыңлау сине яманлауның, сөйләүнең шарты була алмый.

Шарт фигыль формасын алган *бул* фигыле, *кирәк* хәбәрлек сүзе белән килеп, каузаль мөнәсәбәт белдерә ала. Мондый очракта конкрет булмаган, бары тик фараз ителгән сәбәп белдерелә. Мәсәлән: *Ул тегендә дә елаган* ***булса кирәк****: күз төпләре шешенеп беткән иде* (Х. Сарьян), *Йөзе чыннан да ярылган* ***булса кирәк****: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән* (Г. Ибраһимов).

Мисаллардан аңлашылганча, фаразланган шарт реаль нәтиҗәгә китерә алмый, ә фараз ителгән сәбәп реаль нәтиҗә тудыра ала. Димәк, нәтиҗәнең дөреслеге сәбәпнең чынлыгына бәйле түгел. Сөйләүче фәкать нәкъ менә шул сәбәпнең әйтелгән нәтиҗәгә китерүенә шик белдерә. Шундый ук нәтиҗәгә башка сәбәпләр дә китерә алыр иде, ә әйтелгәннәре – нибары сөйләүченең фаразлары.

Мәгълүм булганча, синтетик иярчен шарт җөмлә баш җөмләгә *исә, икән* сүзләре ярдәмендә иярә ала. Моннан тыш, каузаль мөнәсәбәт белдереп, *димәк* сүзе дә кулланылырга мөмкин. Бу очракта иярчен җөмләдә әйтелгән күренеш яки эш-хәл, билгеле бер фикергә килү өчен, нигез ролен үти. Мәсәлән: *Муллык бар* ***икән, димәк****, тырыш* [кеше] (Г. Ахунов).

Сәбәп-нәтиҗә һәм шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләренә карата галимнәрнең фикерләре бердәй түгел. Кайбер тел белгечләре фикеренчә, шарт һәм нәтиҗә арасындагы семантик бәйләнешләр каузаль дип каралырга тиеш. Мондый конструкцияләрдә билгеле бер шартның үтәлүе сөйләүченең теләгенә бәйсез рәвештә нәтиҗәгә китерә [Типология..., с. 28].

Сүзтезмәләр яки җөмләләр арасында бәйләүче чара булып хәл фигыльнең юклык формасы (*-мыйча, -мый, -ми*) килгәндә, шарт мөнәсәбәте дә, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте дә бирелә ала. Мәсәлән: *Атның, яңа киемгә күнегә ал****мыйча****, тәне чымырдап торды* (М. Хуҗин), *Ташкын көченә түзә ал****мыйча****, тегермән буасы ерылган* (Н. Әхмәдиев). Әлеге мисалларда каузаль мөнәсәбәт, җөмләләрне үзгәртеп төзегән дә, ачык күренә: *Атның, яңа киемгә күнегә алмаганга, тәне чымырдап торды; Тегермән буасы ерылган, чөнки ташкын көченә түзә алмаган.*

*Үзең шатлана бел****мичә****, башкаларны сөендерә алмыйсың шул...* (М. Хуҗин). Әлеге мисалда компонентлар арасында шарт мөнәсәбәте урнаша. Хәл фигыль формасы белән башка эш-хәлнең үтәлешенә кирәк булган шарт белдерелә. Җөмләне үзгәртү семантиканы бозмый: *Үзең шатлана белмәсәң, башкаларны сөендерә алмыйсың шул.*

Гагауз телендә *чөнки* (*чўнкў*) теркәгече иярчен сәбәп җөмләне генә түгел, иярчен шарт җөмләне дә баш җөмләгә ияртә ала. Шулай ук баш җөмләгә *ачан* теркәгече ярдәмендә ияргән җөмләнең семантикасын билгеләве дә кыенлык тудыра. «Мондый конструкцияләрдә бер үк вакытта төрле мәгънә мөнәсәбәте – вакыт һәм шарт, шарт һәм нәтиҗә,

сәбәп һәм нәтиҗә мөнәсәбәтләре белдерелә» [Гайдаржи, 1981, с. 64].

Сәбәп-нәтиҗә һәм шарт мәгънәләрен аеруда билгеле бер рольне интонация, контекст башкара. Мәсәлән, *Авылда ут юк икән, яшьләр китап укый алмый, гәзит укый алмый* (Г. Ахунов) дигән җөмләне ике төрле аңларга була: *Авылда ут булмаса, яшьләр китап укый алмый, гәзит укый алмый* яки *Авылда ут булмаганга, яшьләр китап укый алмый, гәзит укый алмый*. Мондый очракта мәгънә йә интонация ярдәмендә (телдән сөйләм вакытында), йә контекст буенча (язма сөйләмдә) билгеләнә. Югарыда китерелгән мисалда исә каузальлек белдерелә, моны алдагы җөмләдән аңлыйбыз: *Электрны авылларда булдыру шуның өчен дә кирәк* (Г. Ахунов).

Бер үк вакытта шарт һәм вакыт мәгънәсен белдергән конструкцияләргә карата да телче галимнәрнең фикерләре төрлечә. Тикшерүчеләрнең күбесе мондый модельләрне йә шарт, йә вакыт мөнәсәбәте кысаларында карый, кайберләре генә иярченле кушма җөмлә системасында шарт-вакыт (условно-временные) җөмләсен аера (әйтик, Л.М. Салмина). Мәсәлән, үзбәк телендә, иярчен җөмлә төре буларак, шарт-вакыт җөмләсе билгеләнә [Кононов, 1960, с. 418].

Кайбер мисалларда вакыт һәм шарт мәгънәләренең кушылуы күзәтелә. Шарт мөнәсәбәте белдергән конструкциянең баш җөмләсендә әйтелгән күренеш иярчен җөмләдәге эш-хәлдән соң үтәлергә мөмкин: *Җитмәсә, мин нәрсә эшләсәм, ул да шуны кыланган була. Мин койма башына менсәм, ул да шунда үрмәли; текә ярдан инешкә сикерсәм, ул да минем арттан сикерә* (Ф. Шәфигуллин).

Кайвакыт әлеге мәгънә баш җөмлә хәбәренең киләчәк заман формасы белән белдерелә: *Сугыша башласак, Габделгазиз мине, әлбәттә, җиң**әчәк*** (Ф. Шәфигуллин). Бу очракта әле үтәлмәгән процесс булуы мөмкин дип фаразлана. Чөнки иярчен җөмләдә әйтелгән вакыйганың тормышка ашачагы сөйләүчегә конкрет билгеле түгел.

Шарт фигыль формасы вакыйгаларның даими яки вакыт-вакыт кабатлануын белдергәндә, шарт һәм вакыт мәгънәсенең кушылуы күзәтелә: *Матур парлар күр**сәм** – куанам...* (Ә. Маликов); *Кит**сә** дә җырлый, кайт**са** да җырлый бу* (С. Сөләйманова).

Кондициональ конструкция компонентларының үзара абстракт вакыт мөнәсәбәте паремияләрдә еш очрый: алт. *Ат киштезе, таныжар, кижи эрмектешсе, таныжар* ‘Ат кешнәсә таныша, кеше сөйләшсә таныша’ [Дыренкова, с. 168]; карач.-балк. *Джангур джауса джерге джауар* ‘Яңгыр яуса, җиргә ява’ [Алиев, 1972, с. 201].

Шарт-вакыт конструкцияләрендә, шартны белдерүче төзелмәләрдән аермалы буларак, теге яки бу эш-хәлнең үтәлүенең конкрет шартлары әйтелә: *Җәй булса – шунда төн чыга. Кыш көне булса – бәләкәй чана алып чыгабыз* (Ф. Сафин).

Шарт фигыль формасының шарт-вакыт мәгънәсен белдерүе гомумтөрки күренеш санала, ул борынгы төрки истәлекләр һәм хәзерге төрки телләр материалында күзәтелә. Мәсәлән: ног. *Пише сувгъа*

*къараса бир ссыпай суьроьт бар сувдынъ ишинде.* 'Хатын суга караса (карагач), су эчендә бер матур сурәт күрә'; к-калп. *Ол дарыҳал уйренти услап алып қараса, онынг қанаты снық екен.* 'Ул үрдәкне тотып караса, аның бер канаты сынган икән'; төркм. *Гүн чыкса, хова майлаяр.* 'Кояш чыкса (чыккач), көн җылыныр' [Гаджиева, 1963, с. 165]. Шарт наклонениесе үзбәк телендә дә вакыт мәгънәсен белдерә ала: *Катта олим блан содда йигит ҳарқачон учрашсалар, бир-бирларига яқин тил топар, оддий мавзуларда мароқли суҳбатлашар эдилар* 'Күренекле галим белән гади егет очрашсалар (очрашканда), үзара уртак тел табалар, гади темаларга сөйләшәләр иде' [Азизова, 1952, с. 13].

Урын-вакыт килешендәге *-ган* формалы сыйфат фигыль, гадәттә, вакыт мәгънәсен белдерә. Кайбер очракларда әлеге форма ярдәмендә вакыт мәгънәсе төсмерле шарт мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән: *Әйт**кәндә** сүзеңчә эшлә, әйтмә**гәндә** уеңча эшлә* (Мәкаль); *Газ исе сиз**гәндә**, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.* Җөмләләрне үзгәртү мәгънәгә зыян китерми: *Әйтсәң, сүзеңчә эшлә; әйтмәсәң, уеңча эшлә; Газ исе сизсәгез, 04 телефоны буенча хәбәр итегез.* Шушы ук семантиканы *-ган очракта, -ган тәкъдирдә* формасы белән күрсәтеп була: *Әйткән тәкъдирдә сүзеңчә эшлә, әйтмәгән очракта уеңча эшлә; Газ исе сизгән очракта 04 телефоны буенча хәбәр итегез.*

*-ганда* формасының шарт мәгънәсен белдерүе башка төрки телләрдә дә күзәтелә. Әйтик, башкорт, алтай, казакъ, үзбәк һ.б. телләрдә: башк. *Теләк менән дәртле йөрәк бул**ғанда**, бөтәһен дә эшләргә мөмкин* 'Теләк белән дәртле йөрәк булганда (булса), бөтенесен дә эшләргә мөмкин' [Грамматика..., 1981, с. 466]; алт. *Бис барбаганда кем барар?* 'Без бармаганда, кем барыр' ('Без бармасак, кем барыр' мәгънәсендә); каз. *Сен маған келгенде, театрға бірге баратын едік.* 'Син миңа килгәндә (килсәң), театрга бергә барыр идек'; үзб. *(Агар) Раҳим бизга келганда (эди) кинога борар эдик.* 'Рәхим безгә килгәндә, кинога барыр идек' [Гаджиева, с. 166].

Мисаллардан күренгәнчә, шарт мөнәсәбәтләре, вакыт мөнәсәбәте белән тыгыз бәйләнешкә кереп, кондициональ һәм темпораль семантика арасында торучы үзенчәлекле конструкция барлыкка китерә. Әлеге конструкцияләрдә вакыйгаларның бер үк вакытта яки бер-бер артлы үтәлүе ачык күрсәтелми, чөнки бу очракта төп мәгънә күренешләрнең нинди вакыт аралыгында башкарылуын түгел, ә аларның бер-берсеннән бәйлелеген аңлата.

Шарт мөнәсәбәте сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт мәгънәсе белән катлаулы бәйләнештә тора, еш кына, ул бер үк чаралар ярдәмендә белдерелә. Бу, үз чиратында, сөйләм һәм фикерләүнең бер-берсеннән башка була алмавын тагын бер кат ассызыклый. Шуңа күрә, синтаксик берәмлекләр арасындагы мәгънәви мөнәсәбәтләрне билгеләгәндә, гомуми эчтәлектән чыгып эш итәргә туры килә.

## ӘДӘБИЯТ


Азизова А.Г. Условный период в современном узбекском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Л. 1952. 14 с.

Алиев У.Б. Синтаксис карачаево-балкарского языка. М.: Наука. 1972. 351 с.

Гаджиева Н.З. Синтаксис сложноподчиненного предложения в азербайджанском языке (в историческом освещении). М.: Изд-во АН СССР. 1963. 220 с.

Гайдаржи Г.А. Гагаузский синтаксис. Придаточные предложения союзного подчинения / отв. ред. Л.А. Покровская. Кишинев: Штиинца. 1981. 133 с.

Грамматика современного башкирского литературного языка / отв. ред. А.А. Юлдашев. М.: Наука. 1981. 495 с.

Дыренкова Н.П. Грамматика ойротского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР. 1940. 302 с.

Кононов А.Н. Грамматика современного узбекского литературного языка. М.–Л.: Изд-во АН СССР. 1960. 446 с.

Типология условных конструкций / отв. ред. В.С. Храковский. СПб.: Наука. 1998. 583 с.

Философский энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия. 1989. 815 с.


## КЫСКАРТЫЛМАЛАР

Алт. – алтай.
Башк. – башкорт.
Каз. – казах.
Карач.-балк. – карачай-балкар.
К-калп. – каракалпак.
Ног. – ногай.
Төркм. – төрекмән.
Үзб. – үзбәк.


***Вәлиева Лениза Газинур кызы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
лексикология һәм диалектология бүлегенең фәнни хезмәткәре.
e-mail: valievalg@mail.ru

# ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

УДК 821.512.145

## Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ З. ВӘЛИДИ КҮРЕРГӘ ТЕЛӘГӘН ТУКАЙ

*З.Г. Мөхәммәтшин*

В данной статье творчество выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая рассматривается через призму литературно-критических суждений Г. Ибрагимова и З. Валиди. Автор рассуждает о справедливости оценки критиков начала XX столетия и выражает свое отношение к ней.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, литературная критика, тукаеведение.

Адәми зат кайсы гына чорда яшәмәсен, аның яшәү рәвешен, дөньяга карашын, эчке психологик кичерешләрен заманнан аерып карау мөмкин түгел. Шунысы ачык: һәр заман үзенчә кызыклы, шул ук вакытта үзенә күрә бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре, язмыш тактасына язылган шатлык-куанычлары, кайгы-хәсрәтләре белән тулы була. Бу уңайдан кискен үзгәрешләргә, фәкать җилле-давыллы, гарасатлы еллардан торган, кешелек җәмгыятенә шактый дәһшәтле вакыйгалар калдырган XX йөз, тарих мәйданында аеруча гыйбрәтле гасыр буларак, хәтергә кереп калды.

Заман һәм Кеше... Гомумән, кешенең үткән тарихы, язмышына язылган көннәре аның дулкынына кушылып, бергә үрелеп бара. Кеше үз заманы проблемалары белән туа, үсә һәм бакыйлыкка күчә. Заманга һәм шул чорда яшәгән Шәхескә бәһа биргәндә нәкъ әлеге принципка таянып эш итү хакыйкатькә ирешү юлларын киңрәк ачар, дигән өмет бар.

Мәгълүм ки, дөнья мәдәнияте тарихында меңьеллык язма әдәбияты булган вә ислам дине нигезендә формалашкан, шуның тәэсирендә яшәгән татар әдәбиятына XIX гасырның икенче яртысында Европа тибындагы әдәби традицияләр үтеп керә башлый. Әдәбиятның заман рухына корылган үзгәрешкә омтылуы һәм 1905–1907 еллар рус инкыйлабы дулкынында татар иҗтимагый тормышында башланган әдәби вә сәяси процесслар татар матбугаты туарга этәргеч бирә. Газета-журналларның дөньяга килүе каләм тибрәткән һәркемгә үзен күрсәтергә, язмаларын укучы хөкеменә тапшырырга юл ача. Фәкать шигъри һәм чәчмә әсәрләрнең яхшысын вә начарын, әдип һәм шагыйрьләрнең талантлысын укучы үзе генә аерып алырга, ул гына тиешле бәясен бирергә хаклы. Л.Н. Толстой «Предисловие к сборнику «Цветник»

исемле китапка язган кереш мәкаләсендә әдәбият мәйданында кибәкне чүбектән аеру өчен әзерлекле тәнкыйтьчеләрнең булуын шарт итеп куя [Толстой, с. 34–36 ]. Һәм Г. Тукайның шуның тәэсирендә иҗади тәрҗемә ителгән «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер» мәкаләсендә (ул «Әлислах» газетасының 1907 елгы 17 октябрь (3) санында басылган) әлеге фикер дәвам иттерелә: «Һәр көн арамызда төрле-төрле яңа исемнәр дә рисалә вә китаплар таралмактадыр, һәр нәрсәнең дә хосулы хәдденнән тәҗавез итсә [җитештерелүе чиктән ашса], табигый, зарарлыдыр. Шуңа күрә безнең дә үз тәнкыйтемез цензорыннан үтмичә, "тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка" кабиленнән таралмакта улан әсәремез эчендә сәдәдил кариине кирам өчен [хөрмәтле гади укучылар өчен] зарарлылары улуы да ихтималдыр [...]. Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы тагы ярамыйдыр. Мөнтәкыйд булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы матлубтыр [таләп ителәдер]. Юк исә, бер гаразы шәхси [шәхси файданы күздә тоту] илә дә тәнкыйть итүчеләр күптер» [Тукай, 1907]. Биредә авторның татар әдәби тәнкыйтенә әзерлекле тәнкыйтьчеләр килүе, аларның әдәби процессны аңлап эш итүләре кирәклеккә басым ясавы аңлашыла.

Шагыйрь-публицистның «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер» язмасыннан өзек алынуы очраклы түгел. Тукай үзе дә халык яклавы, әдәбиятта азмы-күпме ат уйнаткан шагыйрь һәм әдипләрнең, тәнкыйтьчеләрнең уңай фикерләрен ишетеп, аларның рухландырып торулары тәэсирендә үскән талантлы шагыйрь һәм публицист. Мәсәлән, «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 5 декабрь (12 нче) санында шагыйрьнең «Әлгасрелҗәдид»ә маддәтән вә мәгънән» шигыре басылу уңаеннан «Фикер» газетасында (1906 ел, 24 декабрь) әдәбият тәнкыйтьчесе, телче Насреддин әл-Хуҗаши хаты басылган. Ул хатында Тукайның шигырьләрен мактап яза [Насретдин, 1906]. Бу елларда аның шигъри әсәрләренә, аерым алганда «Йолдыз» газетасы «Гәзитәләрдән» бүлегендә «Шагыйрьләребез» мәкаләсеннән алып бастырылган өзеккә үзенең уңай бәясен бирергә дә онытмый [Гәзитләрдән, 1907]. Ләкин шагыйрьнең Казан чоры иҗатына мактау сүзләре, аның шигъриятенә югары бәһа бирү белән янәшәдә, аның телен, шигъри осталыгын тәнкыйть иткән мәкаләләр дә күренә башлый. Ф. Әмирхан «Әлислах» газетасында шагыйрьнең дөнья күргән китабына язган бәяләмәсендә: «Моннан соң Габдулла әфәндедән халис [саф] татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәмез. Татар теленең (дикъкать итеңез – төрек түгел!) аз булса да алга атлавы өчен, мотлак куәи шигърияле [шагыйрьлек таланты булган] затларымызның тәсанныгсыз [табигый] татар булып калулары ляземдер», – дип яза [Дамелла, 1908]. 1909 елда «Вакыт» газетасында Борһан Шәрәф аның хакында бер фельетон бастыра. Тукайны татарның әл-Мәгаррие итеп таныган Р. Фәхретдин дә соңрак шул ук газетада аны тешләп

узуны кирәк тапкан [Борһан..., 1914]. Бу язмада ул Тукайның шигъри мирасын әдәби һәм фәнни яктан тирәнтен анализлаган. Шул ук вакытта ул тудырган шигърияткә шактый таш аткан, күп очракта хаксыз тәнкыйтьләгән әдип һәм әдәбият галиме, тәнкыйтьче Галимҗан Ибраһимов һәм тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Зәки Вәлидинең «Ялт-йолт» журналында (1913 ел, 55 нче (10 июнь) саны) Әхмәдзәки имзасы белән басылган «Тукай илә сохбәтләремнең хәтирәсе»ндә [Әхмәдзәки, 1913] гәүдәләнгән аерым фикерләренә тукталып, «үз мөнәсәбәтемне белдерүне кирәк дип таптым», – ди.

Г. Ибраһимовның 1913 елда Оренбургта «Вакыт» матбагасында дөнья күргән «Татар шагыйрьләре» китабы [Галимҗан, 1913] һәм Тукай вафатыннан соң 1913 елның 6 апрелендә Киев төрмәсендә утырганда язылып, «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 2 сентябрендә нәшер ителгән «Талант трагедиясе» [Галимҗан, 1914] исемле язмасында урын алган фикерләре игътибарга лаек. Алар Г. Тукай белән Г. Ибраһимовның иҗади һәм шәхси мөнәсәбәтләрен ачуда мөһим бер чыганак ролен үтиләр. Әлеге язмалар – киләчәктә тагын да җентекле анализ сорый торган кыйммәтле әдәби вә фәнни ядкәр дә.

Г. Ибраһимовның 8 томлы «Әсәрләр» тупланмасының 5 нче томына (Казан, 1978) «Татар шагыйрьләре» китабы урнаштырылган [Ибраһимов, 1978, б. 110–156]. Аның Г. Тукай иҗатына багышланган өлеше сигез бүлеккә бүленгән. Г. Ибраһимов беренче бүлектә шагыйрьнең шигъри теленә тукталып: «Бездә һичбер шагыйрь Тукай чаклы начар – буталчык вә корама тел белән башламады», – дип шактый кырыс бәясен бирә [Ибраһимов, 1978, б. 112]. Мисалга шагыйрьнең Уральск чорында «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган беренче шигырьләреннән «И, каләм!», «Иттифакъ соңында», «Шагыйрь вә Һатиф», «Гыйшык бу, йа!», «Мөридләр каберстаныннан бер аваз», «Пушкинә», «Дәрдемәнд дәгелмием?», «Япунияи мөселман идәчәк голяма нәрсәдә?» һ.б.ларны тел җәһәтеннән җентекле анализлый. Бу бүлектә тәнкыйтьче Г. Тукайның күпчелек шигъри әсәрләренең Урта гасыр Шәрекъ әдәбияты үрнәкләре «Йосыф китабы», «Бакырган», «Кисекбаш», «Ярым алма», «Бәдавәм», «Кисекбаш», алардагы шигъри ритм, ритмик иҗек саннары тәэсирендә язылуына туктала. Икенче бүлектә Тукай шигъриятенең мәгънә ягына тукталып, нигездә, шагыйрьнең иҗатындагы төп идеяләрнең берсе булган мөселманлыктан татар мәгыйшәтенә килүен, шул фикерләрнең чагылышын ассызыклый. Өченче бүлектә Г. Ибраһимов Тукайны «шагыйрьме-түгелме» дигән үтә дә кискен вә кырыс сорау куеп, аның шигъриятен шик астына куя. Тукай тудырган шигъриятнең нигезендә шигъри тасвирның азлыгын, вәгазьчелек һәм коры фәлсәфә өстенлек итүен дәлилли. Дүртенче бүлектә исә Г. Ибраһимов, өченче бүлектә куелган соравына җавап бирү рәвешендә, Тукайның, шигъри иҗатында С. Рәмиевтә һәм Дәрдемәндтә төп рольне уйнаган сурәтләү чаралары һәм

тасвири алымнарның аз булуына карамастан, ни өчен, ни сәбәпләр белән таныла алуына җавап бирергә омтыла. Нигездә ул аның ике сәбәбен күрсәтә. Беренчесе: «Ул халыкның шигырь вә әдәбият дигән нәрсәгә үләр мәртәбә сусаган заманында чыгучыларның берсе, бәлки иң әүвәлгесе, шул вакытның бердәнбер журналы «Гасыр-җәдит» аңа иң кирәкле урынны бирә барып «Яшь шагыйрьне күрсәтергә тырышты», – дип [Ибраһимов, б.133], аны чор һәм мохит тудырган шагыйрь итеп күрсәтә. Икенчесе исә, шагыйрнең талантлы шагыйрь булып танылa алуын ул: «Халыкның йөрәгендә булып та, теленә килә алмый торган тойгыларны әйтеп бирү һәм укучыны үзе теләгән рәвешчә уйландыру, тәәссерләндерү [тәэсирләндерү] – иштә [менә, нәкъ] язучының үз вакытында күтәрелүнең бердәнбер ачкычы! диләр», – дип яза [Ибраһимов, б. 134]. Бу бүлектә Тукайның тәрҗемәләр белән мавыгуын да, табигатьнең тиешле дәрәҗәдә тасвирланмавын да әйтергә онытмый. Г. Ибраһимов китапның бишенче бүлегендә шагыйрь иҗатында шигъри ялкын, укучы күңеленең эчке тойгыларын кузгалтырлык ярсу җитмәвен дә игътибардан читтә калдырмый. Бу фикерне дәлилләп тәнкыйтьче: «Тукаевта ялкын юк – ул тик кайбер вакыт тын гына авыр тәэсиргә бирелә, бәгъзан [кайвакытларда] бик акрын гына агълый», – дип [Ибраһимов, б.140], XX гасыр башы шигъриятенең, аерым алганда С. Рәмиевнең, шигъри ялкыны җитенкерәмәүне күрсәтеп уза. Алтынчы бүлектә ул шагыйрьне заман вакыйгаларын, аның кимчелекле якларын тәнкыйтьләп язган шигъри әсәрләрен «кәгазь каралары» дисә, яшь буынның эшкә, белемгә, яңалыкка омтылышларын яктыртуын, аларга мәдхия җырлау дип кенә бәяләп, Тукай шигърияттенә түбәнсетеп каравын сиздерә. Шуңа карамастан, бу бүлектә Г. Ибраһимов шагыйрьнең юмор-сатира, ягъни һөҗү шагыйре булуын таный һәм: «Тукаевның каләме, гомумән, көләргә, һөҗү кыйлырга бик ярата, һәм ул бунда үзенең вәгазьләренә караганда байтак артык муаффәкыять тә күрсәтәдер [уңышка ирешәдер]», – дип [Ибраһимов, б. 144] юмор-сатира шигырьләренә шактый саллы һәм лаеклы фикерен җиткерә. Аеруча «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәренә югары бәя бирә. Инде әдип-тәнкыйтьче, башка бүлекләрдән аермалы буларак, җиденче һәм сигезенче бүлекләрдә Тукайның шигъри әсәрләрен тәнкыйтьләүдән бигрәк, татар шигъриятенең классик үрнәкләре булган «Шүрәле» поэмасын, «Су анасы», «Таз малай» шигырьләренә тукталып уза һәм «Габдулла әфәндeнең каләме татарлыкның тышкы сурәтен вә кабыгын гына сызгалап китми. Ул халыкның эченә, җанына да төшә, хыял вә әкият дөньясына да керә. Бунда килсә, аның язуларыннан аңкый торган татарлык исе бигрәк куера да, куәтләнәдер дә», – дип [Ибраһимов, б.148], Г. Ибраһимов Тукай шигъриятеннән үзе күрергә теләгән матурлык үрнәкләрен таба, шуңа басым ясарга тели. Тәнкыйтьче, аеруча шагыйрьнең 1909–1913 елларда язылган әсәрләренә тукталып, Тукайның рухи халәтен ача алган шигъриятендә

тиешле һәм хак бәясен биреп уза. Ягъни Г. Ибраһимов Тукай шигъриятенең эволюциясендә кичергән җитешсез һәм уңышлы якларын җентекле анализлап, шагыйрьнең идеал шагыйрь генә түгеллегенә, аның кимчелекләрдән хилаф булмаган җир кешесе, җир шагыйре, халыкның моң-зарларын җырлаучы Шагыйрь итеп күз алдына китереп бастыра. Шул рәвешле Г. Ибраһимов Тукай шигъриятенә тәнкыйть күсәгенең юан башын ташласа да, Европа һәм рус әдәбият белемендә кабул ителгән әдәбият теориясе нигезендә анализ ясап, шагыйрь иҗатының алтын баганасын тәшкил итәрлек әсәрләрен аерып куюны да кирәк таба.

З. Вәлидинең истәлек язмасында, Тукай бер мөтәфәккир, ягъни фикер иясе түгел иде, ул фәкать үзенең шигырьләрендә яңа бер нәрсә тудыра алмады, дип яза [Әхмәтзәки, 1913]. Шунда ук ул, шагыйрь генә булган бу зат биш-алты еллык татар яшьләренең фикерләрен, уйларын гына җырлаучы, иҗтимагый, әдәби эшләрдә алар уйлап чыгарганны гына белүче һәм бу мәсьәләләрдә фикри карашлары белән башкаларга абруй булырлык түгел иде, дип исәпли. Дөрес, монда З. Вәлидидә дә хаклык бар. Ләкин... Ләкин Шәхескә, бигрәк тә татар шигъриятенең олы талантына бәя биргәндә шагыйрьнең шәхесенә, ул тудырган иҗатка тирәнрәк керү мәслихәт, шул очракта гына объектив караш булырга мөмкин. Тарих белән кызыксынган, инде ул елларда үзенең «Төрек вә татар тарихы» исемле китабы белән танылган З. Вәлидинең Тукай иҗатына югары таләпләр куюы, шул таләпләргә җавап табарга теләве гаҗәп тоелмас мөгаен.

Димәк, Тукай үзе яшәгән дәвердә мактау сүзләре, шигъри әсәрләрен югары бәяләгән фикерләр белән янәшә шактый гына саллысаллы тәнкыйть язмалары белән дә очрашкан, шуларның тискәре тәэсирләрен үзе аша үткәргән. Ни генә булмасын, ул татар шигъриятенең титаник фигурасы, татар кайда гына яшәмәсен, ул халык үзе күрергә теләгән сыйфатта – Халык шагыйре булуыннан туктамады.

* * *

Язманың башында Заман һәм Кеше проблемасы, шәхескә шуның нигезендә бәя биргәндә генә хакыйкатькә ирешергә мөмкинлеге искәртелгән иде. Шунысы ачык: Кеше кем генә булуына һәм кайсы гына дәвердә яшәвенә карамастан, ул – заманының корбаны... Тукай да үзе яшәгән чорның корбаны, фаҗигале язмышлы Бөек шәхесе... Г. Ибраһимов һәм З. Вәлидинең тәнкыйть фикерләре тулы хезмәтләре белән танышкач, алардагы хаклы вә хаксыз фикерләр белән очрашкач, әлеге фикергә бигрәк тә нык инанасың. Мәкаләнең беренче өлешендә әлеге авторларның хезмәтләрендәге аерым карашларын тезис рәвешендә атап үтү белән генә чикләндек, чөнки текст эчендә Тукайның рухи хәле, гасыр башы татар иҗтимагый хәрәкәте, дөнья мәдәнияте эчендә татар әдәбиятының әдәби процессы югалып калырга мөмкин иде. Еш кына әдәби һәм фәнни тәнкыйтьтә болар читтә кала. Атап үткәннәрне истә тотып, язманың төзелешен шул рәвешле корарга уйладык.

Г. Ибраһимов Тукай шигырьләренең теле – «буталчык вә корама тел» дип басым ясап, шуңа игътибарны юнәлтергә теләп, беренче тәнкыйть фикерен җиткерә. Сүз шагыйрь иҗатының башлангыч чоры турында бара. Тәнкыйтьче хаклы идеме? Хаклы. Әмма татар әдәбиятының меңьеллык әдәби традицияләре гасырлар дәвамында формалашып, билгеле бер үсеш этабын узган әдәбият – Урта гасыр Шәрекъ, ислам дине идеяләре нигезендә барлыкка килгән татар язма әдәби теле – әле XX йөз башында да яшәвен дәвам итә. Беренчедән, Тукай шул әдәби мохитта тәрбияләнеп, әдәби тел кагыйдәләрен сакларга теләп каләм тибрәтә; икенчедән, бу елларда шагыйрьнең төрек әдәбияты тәэсирендә булуын да танырга кирәк; өченчедән, татар әдәби теленә XIX йөзнең 80 нче елларында, аерым алганда 1883 елда Бакчасарайда И. Гаспринский наширлеге һәм мөхәррирлегендә дөнья күргән «Тәрҗеман» газетасының уртак төрки тел барлыкка китерүгә йөз тотуының да тәэсире сизелә. Гомумән, XX гасыр башы өчен Тукай шигъриятенең теле һәркемгә аңлаешлы, уртак мәдәни тел буларак хезмәт итә. Әдәбият мәйданына Тукайга караганда соңрак килгән Г. Ибраһимов бу традициянең сакланышын, һичшиксез, белгән, аларны, аерып алып, кимчелек дип тануы, шуңа басым ясарга теләве, 1911–1912 елларда ике талант арасына кара мәче керү белән дә аңлатылса кирәк. Г. Ибраһимовның «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 4 гыйнвар (628) санында Г. Тукай төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле җыентыкка карата язылган шактый җентекле тәнкыйть мәкаләсе [Ибраһимов, 1911], шул ук газетаның 1911 елгы 21 июнь (699) санында шагыйрь тәрҗемә иткән «Мияубикә» әсәренә тәнкыйть фикере белдерү дә моңа сәбәп биргәндер, күрәсең [Ибраһимов]. Тукай 1911 елның 1 гыйнварында С. Сүнчәләйгә язган хатында «Көндез Г. Камал, Г. Ибраһимов вә бәгъзан Ф. Әмирхан вә башка да интеллигентлар белән катышам», – дип язса [Тукай, 1986], инде 1911 елның 4 мартында С. Сүнчәләйгә «Габди Галимҗанның вакытлы матбугатта чыккан язулары шома, ихласлы вә шактый гына төпле чыгалар. Ләкин мин аның аерым рисаләләрендә күңелдә бер-бер төрле эз калдырырлык нәфасәт [матурлык, нәфислек] вә мәһарәт [осталык] күрмим. 10 сәхифәдә язылырлык бер мәүзугъка һәрвакыт әллә ничәшәр өлеш артык кәгазь исраф итә...» – дип [Тукай, б. 103], мәкаләләрендә артык сүз куерту белән мавыгуын искәртә. Чынлыкта, шагыйрь-публицист 1905–1907 еллар инкыйлаб дулкынында дөнья күргән вакытлы матбугатта, бигрәк тә җитди журнал – «Әлгасрелҗәдид»тә язма әдәби тел традицияләрен сакларга тырышып иҗат итә. Монда шуны да искәртү кирәк: китапта Г. Ибраһимов шагыйрьнең фәкать «Әлгасрелҗәдид» журналында дөнья күргән шигырьләрен генә төп тикшерү объекты итеп алган. «Фикер» газетасында һәм сатирик «Уклар» журналында басылган, күпкә халыкчан тел белән язылган шигырьләре игътибардан читтә калган. Әдип-тәнкыйтьченең, Тукай

шигырьләре «корама» тел белән язылган, дигән фикеренә шул рәвешле җавап биреп булыр иде.

Г. Ибраһимов куйган икенче бер мәсьәлә – шагыйрь иҗатында мәгънә, мөселманлык һәм татарлык проблемасы. Бу күренеш тә Тукайның башлангыч чор иҗатында күзәтелә. Гасырлар дәвамында рус империализмының милли изүе һәм милләтнең милләт буларак рухи вә мәдәни үсешенә тоткарлык ясаган дини идеология басымы астында яшәгән татар халкының ислам берлеге идеясенә тартылуы, шул фикерне шигырьләрендә яктыртырга теләве әллә ни гаҗәпләнү тудырмый кебек. 1905–1907 елгы инкыйлаб тәэсирендә татар иҗтимагый тормышында милли идеяләрнең баш калкытуы, шагыйрьнең дә әлеге фикергә йөз боруы, үз халкы белән горурлануы, аңа мәдхия җырлавы, шуларны кыйбла итүе – заман таләбе, аның әдәби процесста бер күркәм күренеш сыйфатында гәүдәләнүе мактауга лаек. Милли-дини изүнең көчле басымында көн күргән халык әлеге идеяләрне пропагандалаган шигъри әсәрләргә сусаган, андый шигырьләрне халык хуплап каршы алган. Чын милли идеяләрне чагылдырган шигырьләрнең яратып укылуы, бердән, шагыйрьгә зур плюс бирсә, аның халык арасында тиз танылалуына сәбәпче дә була. Г. Ибраһимов язмасындагы тәнкыйть фикерләре азмы-күпме үзен акласа да, милләтнең күңел төпкелләренә яшеренгән милли хисне уятуда мондый шигъри әсәрләр дә үзләренең уңай ролен уйнавын искәртү урынлы булыр. Дөрес аларның шигъри табышлары, тасвири алымнары, сурәтләү чаралары, әйтергә теләгән фикеренең гадилеге Г. Ибраһимовны канәгатьләндерә алмый. Шулар Тукайның милли рухта язылган шигырьләрен тәнкыйтьләп узарга сәбәп биргән, булса кирәк. XX гасырның тарихи-иҗтимагый вазгыятеннән чыгып бәһа биргәндә, Г. Ибраһимовның фикерләренә күз йомарга да туры килә.

Тәнкыйтьче «Тукаев шагыйрьме, түгелме?» дип, Тукай иҗатына үтә дә кискен һәм кырыс өченче соравын куеп, шагыйрьнең шигъри мирасын шик астына ала. Төп сәбәп – шигъри тасвирның юклыгы, вәгазьчелек, коры фәлсәфә сату итеп карау. Г. Ибраһимов хаклы идеме? Хаклы, әлбәттә. Беренче карашка шулай. Тукайның талантлы шагыйрь булуын үз дәверендә дә, бүген дә, киләчәк буыннар да татар халкы яшәгәндә беркем дә кире кага алмас мөгаен. Монда Г. Ибраһимовның әдәбиятка, әдәби тәнкыйтькә үз шәхси карашлары һәм Европа, рус әдәбият теориясендә кабул ителгән төп тенденцияләргә таянып эш йөртүе, әдипнең чәчмә әсәрләрендә чыгылыш тапкан табигать һәм кеше язмышы проблемаларының уртак бәйләнеше, табигать аша җәмгыять вә кешенең эчке психологик фәлсәфәсен ачарга тырышуы, шул методны Тукай шигъриятеннән дә таләп итәргә теләүдән килүе ачык сизелә.

Мәгълүм ки, Г. Ибраһимов – заманы өчен иске тип Вәли мулла (Мөхәммәдвәли Хөсәенев) мәдрәсәсендә укыса да, үзлегеннән белем алган, Европа һәм рус әдәбиятын тирән үзләштергән, гомум тарихны,

рус әдәбият теориясен ныклы өйрәнгән һәм дә, XX гасырның 10 нчы елларында шуларны нигез итеп алып, шактый әдәби тәнкыйть мәкаләләре, татар әдәбияты теориясенә карата фәнни китап бастырган әдәбият галиме буларак танылган шәхес тә. Әдип һәм тәнкыйтьченең нигездә 1917 елгы инкыйлабка кадәр романтик рухтагы әдип булып калуы, әдәбият теориясе таләпләренә җавап бирерлек әсәрләр иҗат итүе Тукайның гади сурәтләүләр, үз халкының моң-зарын, хәтерләргә сеңгән тарихи үткәнен, аның фәлсәфи фикерләрен гәүдәләндергән халыкчан шигъриятенә объектив бәһа бирүне чикли кебек. Тукай, барыннан да элек, гасырлар дәвамында килгән әдәби һәм мәдәни традицияләргә тугрылык саклаган шагыйрь. Аның иҗатында Урта гасыр Шәрекъ әдәбияты һәм ислам фәлсәфәсендә формалашкан милли фәлсәфә, әхлакый һәм иҗтимагый фикер яши. Шул традицияләр аша ул XX гасыр башы татар укучысының күңеленә үтеп керерлек шигъри әсәр тудыра алган, иҗатта реалист булып калган. Ике талантлы шәхеснең әдәбиятта ике караш та торулары фикер каршылыгына китергән дә инде. Гомумән, 1911 елның 1 гыйнварында С. Сүнчәләйгә язган хатында Тукайның иҗатта үзен иркен тотуы, аңлашыла: «татарларда теория словесности (әдәбият теориясе) вә шигырьләр өчен хорей, дактиль – фәләнләр язылмаган чакта, вәзен вә гармонияләрнең төрлечә булса да зарар юк, фәкать мәгънә кирәк, гүзәл традиция кирәк», – дип яза ул [Тукай, 99]. Г. Ибраһимов шуларны тәнкыйтьләп уза да инде.

«Татар шагыйрьләре»ндә Г. Ибраһимов Тукай шигъриятендә, С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд белән чагыштырганда, сурәтләү чаралары, тасвири алымнарның аз булуы, табигатьне сурәтләү җитмәүгә тукталып, шагыйрьнең беренче чор иҗатын шактый нык тешләп уза. Г. Ибраһимов бу очракта да хаклы идеме? Бер яктан караганда, һичшиксез, хаклы иде. Ләкин татар әдәбиятының милли үзенчәлекләрен һәм әдәби процессның хәрәкәтен, аның тарихи эволюциясен хәтер аша уздырганда, шулар белән янәшәдә, XX йөз башы әдәби мохите һәм вазгыятен күз алдына китергәндә, тәнкыйтьченең фикерләренә каршы килергә дә мөмкин. Беренчедән, борынгы һәм Урта гасыр татар поэзиясененең тарихын күзәткәндә табигать белән бәйләнеш, сурәтләү чаралары һәм тасвири алымнарга байлык әллә ни күзгә ташланмый, ягъни шагыйрь шигърият кабул иткән традицияләр нигезендә шигъри әсәрләр тудыра. Беренчедән, татар әдәбияты рус һәм Европа әдәбиятының үзенчәлекләре, әдәби процессына ят булган, Шәрекъ традицияләренә нигезләнгән әдәби алымнар белән үсә. Икенчедән, һәр иҗатчының үз стиле, алымнары, формалары бар; өченчедән, XX гасырның 10 нчы елларына кадәр катлаулы тасвирый һәм сурәтләү чараларына ихтыяҗ да күренми шикелле, чөнки, Г. Ибраһимов искәртеп узганча, халык чын милли шигърият җәүһәрләренә сусаган чор була ул; дүртенчедән, шагыйрь-публицист 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкыны белән татар халкының милли үзаңы уяну дәверендә иҗтимагый

тормышның сәяси вакыйгаларын, милли-дини изү астында милләтнең Европа һәм рус мәдәниятеннән күп калышуын төшендерүдә, иң беренче чиратта, халыкка җиңел аңлаешлы формада – Урта гасыр әдәби традицияләре калыбында әдәби әсәрләр иҗат итү шул заман өчен мөһимрәк дип санаган. Бу елларда санап үткән әлеге сәбәпләр күпчелек әдипләргә хас булын истә тотсак, Г. Ибраһимовның 1905–1907 еллардагы тарихи вазгыятькә һәм әдәби процесска азмы-күпме күз йомарга тырышуы күренә. Әмма ул соңрак, Россия тарихында Столыпин реформаларыннан башланган сәяси репрессияләр нәтиҗәсендә, Тукай иҗатында да, лирик-фәлсәфи шигырьләрдә образлы сурәтләүнең шактый көчәюенә, шигырьнең эчке мәгънәсе тирәнәюгә, шагыйрь иҗаты аша татар халкының милли фаҗигасы ныграк ачыла баруына игътибар итә, Тукайның 1909–1913 еллар иҗатындагы нәкъ шул үзенчәлекләренә тукталып, шагыйрьнең бөеклеген таныргa мәҗбүр була.

Г. Ибраһимов китапның дүртенче бүлегендә шагыйрьнең башка телләрдән тәрҗемәләр белән мавыгуын да искәртергә онытмый. Хәер, Тукайның тәрҗемә әсәрләргә күбрәк игътибар юнәлтүен башка тәнкыйтьчеләр дә читләтеп узмый. Чыннан да, Тукай шигырьләрен күзәткәндә, иҗатының шактый өлеше тәрҗемә әсәрләрдән гыйбарәт булуы күренә. Шагыйрьне бу очракта аңлап һәм белеп тәнкыйтьләү кирәктер.

Кешелек дөньясының мәдәни цивилизациясе үткән тарихи юлны күзәткәндә аның икътисади һәм сәяси багланышлар белән генә түгел, бәлки мәдәниятләренең уртак бәйләнешләр нигезендә үсүенә дә игътибар итмичә булмый. Бу, һичшиксез, халыкларның дәүләтле, алга киткән мәдәнияткә тартылуына бәйле. Мәгълүм ки, тарихта беренче дәүләтләр Көнчыгышта, аерым алганда, Мисыр, Вавилония, Кытай, Һиндстанда төзелә, алар тудырган мәдәният, мәҗүсилек нигезендә формалашкан халык иҗаты һәм әдәби мирас, заманы өчен яңа дәүләтләр – Греция һәм Римгә күчеп, тагын да ныграк байый, камилләшә. Соңрак, бу дәүләтләр дә кризис кичергәндә, аларның әдәби һәм мәдәни традицияләре кабат Көнчыгышка әйләнеп кайта. VII–VIII йөздән ислам дине тәэсирендә дөньяга килгән мәдәният Урта гасырларда үсешенең югары ноктасына җитә. Урта гасырда Европа халыкларының милли дәүләтчелеге төзелгәндә алар Шәрекъның күркәм мәдәни-әдәби казанышларын кабул итеп ала, Шәрекъ дөньясының яшәү рәвешен, эчке психологик үзенчәлекләрен, традицияләрен чагылдыра алган әдәби мирасларын үз телләренә тәрҗемә итеп, аларга икенче сулыш та бирәләр. Сүзне ерактан башлауның төп сәбәбе шул: дөнья әдәбиятында тәрҗемә традицияләре, бердән, мәдәни-әдәби багланышларны ныгытуда төп чара булса, икенчедән, яңалыкка омтылган халыкның әдәбиятына яңа сулыш өрергә, традицияләрне баетырга да ярдәм итә. Һәркемгә мәгълүм ки, яңа әдәбиятка, яңа идея һәм әдәби алымга йөз тоткан рус әдәбияты да XVIII йөзнең икенче яртысы – XIX йөзнең башларында

Европа халыклары, шул исәптән грек, итальян, инглиз, немец, француз әдипләренең әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп, аларны укучыга ирештерәләр. Русның мәшһүр шагыйрьләре – Жуковский, Крылов, Пушкин, Лермонтов һәм башкаларның иҗатларында атап үткән милләтләрнең әдәби әсәрләрен күпләп очратырга мөмкин. Татар әдәбиятының Европа мәдәниятына тартылуы рус әдәбиятына караганда күпкә соңрак башлана, аларның идея-эстетик карашларының таралыш алуы да, фәкать XIX йөзнең ахыры – XX йөзнең башларына туры килә, аның нәтиҗәсе Тукай иҗатында да шактый күзәтелә. Ягъни яңалыкка омтылган һәрбер әдәбият, беренче чиратта, телиме-теләмиме, заманы өчен яңа идея-эстетик карашларга бай әдәби мираска мөрәҗәгать итә, милләтнең рухына туры килгән әсәрләрне тәрҗемә итүгә алына. Югарыда күрсәтеп үткән дәлилләр XX гасыр башында тәрҗемә әдәбиятның таралу сәбәпләрен ачык күрсәтә сыман. Гомумән, ул елларда Тукай иҗатында гына түгел, әдәбиятка тартылган һәркем, рус һәм Европа әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемәдә татар укучысына шактый ирештерә һәм алар укучылар арасында популяр санала. Шул рәвешле, рус һәм Европа, шул исәптән төрек әдәбияты ядкәрләре үрнәкләренең Тукай иҗатын тулыландыруы гаҗәпләнү уятмый шикелле. Тукай тәрҗемәсендә, тел һәм әдәбият галиме Җ. Вәлиди язганча, алар чын татарча, Тукайча булып яңгырый. Пушкин, Лермонтов яисә башка шагыйрьләрнең кайсы гына шигыре тәрҗемәсен алсаң да, ул әсәрләргә милли рух, Тукай рухы сеңгән. XX гасыр башы әдәби процессында тәрҗемәләрнең никадәр зур роль уйнавын истә тотканда, Г. Ибраһимовның Г. Тукай иҗатына бәясенең хакысызлыгына ышанырга туры килә. Аны да аңларга мөмкин, чөнки, югарыда күрсәтеп үткәнчә, эдип-тәнкыйтьче әдәбият мәйданына шагыйрьгә караганда берникадәр соңрак килә, икенчедән, аның рус әдәби тәнкыйтенә, теориясенә тартылуы Тукай шигърияtenә берьяклы бәһа бирергә этәргеч була.

Тәнкыйтьче китапның бишенче бүлегендә Тукай поэзиясендә шигъри ялкын җитенкерәмәвен искәртеп үтә. Чыннан да, шагыйрьнең шигъри мирасын күзәткәндә, Г. Ибраһимов язганча, С. Рәмиев әсәрләрендәге шигъри ялкын булмавы игътибарны җәлеп итә. Әдип-тәнкыйтьче бу очракта да хаклы. Ләкин, Тукай шигъриятькә килгәндә татар әдәбиятының традицион әдәби алымнарга нигезләнеп үсүен, иҗатының күпкә реалистик поэзия булуы белән аерылып торган шигърият икәнен истә тотсак, тәнкыйтьченең күпмедер дәрәҗәдә хаксыз икәнлеге дә ачыла. Тукай беренче чор иҗатында нәкъ ялкынлы публицистик шигырьләре белән укучыда танылу ала да инде, дөресрәге, ул аларны, Г. Ибраһимов күрергә теләгәнчә, романтик форма белән язмаган, шагыйрьнең идея-эстетик карашлары исә укучыга җиңел аңлаешлы, гади телдә нәшер ителгән.Тәнкыйтьчене мондый алым канәгатьләндермәгән, әлбәттә. Аны һәркемнең күңелдә хыялый вә мавыктыргыч тасвирый алым,

сурәтләү чараларына бай булган поэзия кызыктыра, шуларны шагыйрь иҗатыннан таләп итә. Кызганыч, татар поэзиясендә үз мәктәбен калдырган талантлы шагыйрь – Тукай өчен Г. Ибраһимов фикерләренең әллә ни әһәмияте дә юк шикелле. Шунысы ачык: инде бу чорда татар поэзиясендә шагыйрь традицияләрен дәвам иткән, яисә аның рухи стилендә язган шагыйрьләр әдәбият мәйданында үз урыннарын табып өлгергән була.

Г. Ибраһимов алтынчы бүлектә, нигездә, шагыйрьне искелекне тәнкыйтьләүче, яңалыкка омтылган яшь буынның эшләренә мәдхия җырлаучы итеп карарга тели. Бу очракта да әдип-тәнкыйтьче, һичшиксез, хаклы. Әмма, икенче яктан килгәндә, ул хаклы да түгел. Шунысы мәгълүм: XX гасыр башында Россиядә башланып киткән кискен сәяси вакыйгалар, 1905–1907 елгы рус инкыйлабының иҗтимагый тормышка тәэсире нәтиҗәсендә гасырлар дәвамында бер тизлектә, тыныч агым белән аккан тормыш ритмы да зур үзгәрешләр кичерә, һәм татар иҗтимагый хәрәкәтендә заманы өчен яңалык вә искелек көрәшенә сәбәп бирә, ягъни юл ача. Бу шартларда, шагыйрь-публицист көн кадагына суккан төп проблемадан читтә кала алыр иде микән? Һич, юк... Мәкаләнең башында ук кешенең заман вакыйгалары эчендә яшәвенә, аның сулышын сулавына игътибар юнәлтелгән иде инде. Шагыйрь шул дөнья белән яши, татар тормышында барган һәр вакыйга Тукайның шигъри әсәрләрендә чагылыш тапмыйча калмый. Алар шул чор өчен ихтыяҗ санала, шагыйрь исә әлеге ихтыяҗны тутыручы булды. Шагыйрь үзе искәркәнчә, йокыга талган милләтне уятуда, Тукайның ялкынлы публицистик шигърияте һәм мәкаләләренең роле биниһая зур. Моны инкяр итү шикле. Тәнкыйтьченең, Тукай поэзиясенә бәя биргәндә, нәкъ тарихи вазгыять һәм иҗтимагый хәрәкәтнең халәтен читтә калдыруы, шагыйрьнең иҗат мирасына берникадәр субъектив бәһа бирергә этәргеч ясаган булса кирәк, дигән фикер туа.

Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» исемле китабының Тукай иҗатына багышланган бүлегендә шагыйрьнең шигъри мирасына җентекле анализы һәм язмада яңгыраган фикерләр болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Язмада әдип-тәнкыйтьченең кайбер кискенрәк табылган яисә каршылыклы уйлар уяткан урыннарына тукталып, Тукайның иҗатында күренгән кайбер азмы-күпме кимчелекләрне, әсәрләрендәге җитешсезрәк якларны күрсәткәндә тарихи вазгыять, әдәби процесс, татар иҗтимагый хәрәкәтендә барган үзгәрешләрне истә тотып, мөмкин кадәр объектив бәяләргә омтылыш ясалды. Мондый алым, нигездә, хакыйкатькә туры килә, дип уйлыйбыз.

Шагыйрь вафатыннан соң аның иҗатына кырысрак фикер З. Вәлиди мәкаләсендә бәян ителә. Ул Тукайны, фикер иясе түгел, дип һәм татар яшьләренең фикерләрен җырлаучы рәвешендә генә тәкъдим итә. Моңа охшаш фикер Г. Ибраһимов язмасында чыгылып үткән иде инде. З. Вәлидинең ул елларда фән белән кызыксынуы, фәнни карашының киңлеге, ә Тукайның фәкать

шагыйрь булып калуы, автор язганча, әсәрләрендәге фикер тарлыгы, татар яшьләре арасында мәгълүм уйларны җиткерүче итеп кенә күз алдына китереп бастыруы, ул тудырган шигърияткә субъектив бәягә юл ача. Бер яктан караганда, З. Вәлидинең әйткән фикере белән килешергә дә мөмкин. Ләкин XX гасыр башы зыялы яшьләре кебек, укымышлы өлкән буынның белемен, буыннар бәйләнешен, аның тәрбия традицияләренең дәвамчылыгын тапшыра алган ата-ана назын күрмәгән, ниндидер фикер уятырлык тирән белем алу насыйп булмаган Тукайда дөнья күләмендә фикер йөртүне эзләү урынсыз да кебек. Һәм шулай ук үзлегеннән шәрекъ һәм рус, рус теле аша Европа әдәбиятын аз-маз укыган, шул заманның сәяси китаплырын тәрҗемә иткән, яисә алардан үзенә кирәкле фикер алган шагыйрьдән югары дәрәҗәдәге фәнни-аналитик карашларны бәян иткән фәнни язмаларны көтү дә хакыйкатькә туры килми. Шуңа карамастан, Тукай барлыгы сигез-тугыз еллык иҗат гомерендә милләте тарафыннан танылган Бөек шагыйрь, халык үзе атап йөрткән – Халык шагыйре булып яши, шуңа тугры кала.

З. Вәлиди мәкаләсендә, шагыйрь фикри карашлары белән башкаларга абруй булырлык түгел иде, дигән фикер дә чыгылып үтә. Талантлы шагыйрьме, яисә әдипме ул, иң беренче чиратта, әсәрләрендә үз халкының фәлсәфи карашларын, милләтнең яшәү рәвешен, аның психологиясен, традицияләрен, фаҗигале вә гыйбрәтле тарихын гәүдәләндерергә тиеш. Шул очракта гына талантлы әдип Бөек вә абруйлы Шәхескә әйләнергә мөмкин. Бу таләпләр – Тукай поэзиясенең төп баганасы, арка таянычы. Димәк, шагыйрь, үзе яшәгән чорда ук, санап үткән таләпләргә җавап бирерлек шигъри әсәрләр тудырып, халык шагыйре исеме алып танылган, милләте каршында зур абруй казанган, титаник фигура булып җитешкән Бөек Шәхес икәнен инкяр итәрлек дәлилләр юк шикелле. Язма авторының, шагыйрь иҗатыннан фәкать үзе күрергә теләгән Тукайны эзләве бер яктан акланса да, икенче яктан, мәкаләдә кат-кат искәрткәнчә, шул заманның тарихи вазгыятен вә иҗтимагый хәрәкәтен, әдәби процессын, фәлсәфи карашларын беренче планга куеп бәяләгәндә, З. Вәлидинең Тукай поэзиясенә субъектив бәһа бирергә тырышуы аңлашыла кебек.

Г. Ибраһимов һәм З. Вәлидинең Тукай тудырган иҗатка карата язган кайбер фикер-карашларын кузгатып узу очраклы түгел. XX гасыр башында рус һәм Европа мәдәнияте аша кергән шул халыкларның иҗтимагый вә сәяси, фәлсәфи карашларының 1905–1907 елгы рус инкыйлабы тәэсирендә татар иҗтимагый тормышында гаять зур тизлек белән таралыш алуы, аның гасырлар дәвамында яшәп килгән традициясендә яңалык буларак кабул ителүе меңьеллык әдәбиятлы татар халкының әдәби мирасына карашны азмы-күпме үзгәртергә мәҗбүр итә. Ул бигрәк тә рус һәм Европа мәдәниятенә тартылган яшь буынга хас күренеш була. Ягъни аларның мәдәни-әдәби калыпларына ияреп, яисә кабатлап, татар халкының

милли үзенчәлекләрен, традицион формаларын бер якка куеп, рус һәм Европа милләтләре кабул иткән фәлсәфи вә теоретик фикерләргә нигезләнеп, XX гасыр башы мәдәни күтәрелешендә танылып өлгергән талантлы каләм ияләре, теләпметеләмичәме, мондый күренешләргә субъектив бәя бирү белән чикләнәләр. Мондый бәһа Тукай шигъриятен дә читләтеп үтмәгән, әлбәттә. Кызганыч, иярү, кемнедер кабатлау – шәхеснең, милләтләрнең һәм аларның мәдәниятләренең, шулай ук дәүләтләрнең һәлакәткә баруына бер адым икәнлеген кешенең аңлау дәрәҗәсе түбән булуын дәлилли. Шәхеснең шәхси йөзе, мәдәниятләрнең милли йөзе, дәүләтләрнең тарихи йөзе юкка чыга баруын күрер күзгә күренмәгән сихри вә серле томан рәвешендә таралган рәшә белән дә чагыштырырга мөмкиндер мөгаен. XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөзнең башында татар иҗтимагый тормышының, гомумән, мәдәниятенең рус һәм Европа мәдәниятенә тартылуы тәэсирендә, милли мәдәни-әдәби мохит шул рәшә артында югалып кала баруга беренче адымын ясый. Бу халыкларның милли үзенчәлекләрен татар мәдәни-әдәби традицияләрендә күрергә теләү, шуларны нигез итеп алырга омтылу аяныч хәлләргә китерәчәген яшь буын зыялылар аңлап та җиткермәгәннәрдер. Каршыда бер генә максат: гасырлар дәвамында милли һәм дини изү астында яшәгән милләтне шул заман өчен алдынгы фикерле саналган Европа мәдәниятенә тартырга теләү, әлеге фикерне милләт аңына сеңдерергә тырышу. Ул вакытларда иярү яисә кабатлауның аяныч турында уйлаучылар гадәттә кадимчеләр дип аталып йөртелгән, һәм алар татар халкының киләчәгенә аяк чалучылар булып саналган. Шул исәптән, Тукай иҗатында да «кадимче» мулла, сәүдәгәрләрне тәнкыйть утына тоткан шигъри һәм публицистик язмалар шактый. Әмма шагыйрь, заманның яңа фикерләрен кабул итсә дә, шигъриятендә милли традицияләрнең дәвамчылыгын саклаган Тукай буларак таныла. 1909–1913 елгы иҗат дәверендә кайбер шигъри әсәрләрендә үзенең кылган гамәлләренә үкенү хисе дә чагылып үтә. Нәрсә генә булмасын, Шагыйрь дә үз чорының баласы, аның корбаны. Ул да заман вакыйгаларын сикереп чыга алмый, шунда кайный, шул дөнья белән яши.

Озын сүзнең кыскасы, Г. Ибраһимов һәм З. Вәлиди язмаларында Шагыйрьнең иҗатына карата никадәр генә тәнкыйди фикерләр гәүдәләнеш алмасын, Тукай шигърияттә татар халкының титаник фигурасы – дөнья мәдәниятенә танылган символик образы буларак яшәвен дәвам итә. Шуны да искәртү кирәк: XX гасыр башы иҗтимагый хәрәкәте тудырган кискен үзгәрешләр дулкынында әдәбият мәйданында каләм тибрәткән Шагыйрь заман вакыйгаларына битараф кала алмас иде. Ул, нәкъ шул агымга кушылып, татар тормышының кимчелекле якларын, бигрәк тә милли-мәдәни вазгыятьне артка сөйрәүче булып саналган муллалар, сәүдәгәрләр, байлар катламын, татар зыялылары арасындагы каршылыкларны сатирик шигырьләре һәм публицистик язмалары белән тәнкыйть утына

тота. Тукай бу чорда татар әдәбиятында сатирик жанрга нигез салучыларның берсе һәм аны кабатланмас югарылыкка күтәрүчеләрнең иң күренеклесе булып танылa. Әмма инкыйлаб дулкыннары артка чигенү белән Шагыйрь күңелендә башланган рухи кризис, ятимлек ачысының нәтиҗәсе – сәламәтлегенең какшавы сәбәпле, ул хис һәм фикер берлеген бергә җыйган лирик, лирик-фәлсәфи шигъриятькә өстенлек бирә. Тукайның күңел җылысы салынган лирик һәм лирик-фәлсәфи шигырьләренә чорга, дөньяга карашы, уй-хисләре, эчке психологик кичерешләре, җан сыкравы сеңдерелгән. Тукай тудырган Бөек шигърияттә татар халкының фаҗигале тарихи үткәне, кайгы-хәсрәте, күңеленең иң тирән урынына яшеренгән моң-зары, милләтнең фәлсәфи карашлары чагылыш табу – шуның мисалыдыр, күрәсең. Милләт фаҗигасе, Тукай кичергән фаҗигале язмыш аңардагы халәт аша укучыга барып ирешә. Татар халкында Тукай образы милли фәлсәфи карашлар системасы, Заман һәм Кеше проблемасының бер чагылышы буларак ачыла. Шагыйрьнең иҗат мирасы шуның белән Бөек тә.

ӘДӘБИЯТ


Әхмәдзәки. Тукай илә собхәтләрем хәтирәсе // Ялт-йолт. 1913. 55 нче сан.

Борһан Шәрәф һәм Риза Фәхретдин фикерләре Тукайның үзе тарафыннан төзелгән «Мәҗмугаи асар» (Казан, Мәгариф матбәгасы, 1914) китабына Җ. Вәлиди язган кереш мәкаләдән алынды.

Гәзитәләрдән // Йолдыз. 1907. 16 май.

Дамелла. Габдулла Тукаев шигырьләре (2) // Әлислах. 1908. 2 февраль.

Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. – Оренбург, 1913.

Ибраһимов Г. Талант трагедиясе // Йолдыз. 1914. 2 сентябрь.

Ибраһимов Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре // Йолдыз. 1911. 4 гыйнвар.

Ибраһимов Г. Мияубикә // Йолдыз. 1911. 21 июнь.

Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Т. 5. Б. 110–156.

Насреддин эл-Хуҗаши. «Әлгасрелҗәдид» журналы хакында // Фикер. 1906. 24 декабрь.

Толстой Л.Н. Собрание сочинений: в 22-х т. / коммент. К. Ломунова. М.: Художественная литература, 1983. Т. 15. Статьи об искусстве и литературе. 432 с.

Тукай Г. Тәнкыйть – кирәкле шәйдер // Әлислах. 1907. 17 октябрь.

Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 5. Б. 368.



***Мөхәммәтшин Зөфәр Гомәр улы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
текстология бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре
e-mail: muhamet_zufar@mail.ru

УДК 821.512.145

# ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ ӘДӘБИ ТОПОГРАФИЯНЕ БИРҮГӘ КАРАТА
## (Казан шәһәре мисалында)

*З.З. Рәмиев*

В статье рассматривается вопрос отражения в готовящейся Тукаевской энциклопедии литературной топографии жизни и творчества поэта. С этой точки зрения интересен город Казань, где жил Тукай до самой своей кончины в 1913 г. В произведениях и письмах отразилась любовь к этому городу, который являлся духовным и культурным центром татарской нации, вместе с тем поэт критиковал некоторые стороны повседневной жизни казанцев.

**Ключевые слова:** Лермонтовская энциклопедия, литературная топография, Тукаевская энциклопедия, Казань, словник, татары, статья, поэт, стихотворение, текст.

Топография атамасы башлыча җир өслеген географик һәм геометрик җәһәттән өйрәнүләргә нигезләнгән фән тармагында кулланыла (шулар нигезендә топографик карталар төзелә). Әмма XX гасыр ахырларында бу атаманың семантикасы киңәя төште, чынында аның нигезендә яңа бер атама барлыкка килде: бу – әдәби топография. Ә аның кулланыла башлавына иң тәүге мисал итеп Лермонтов энциклопедиясен [Лермонтовская..., 1999, с. 22] күрсәтергә мөмкин. Басма ахырында, 11 төркемгә тупланып, энциклопедиягә кертелгән мәкаләләр исемлеге китерелә. Аның IV төркеме исә «Лермонтов белән бәйле истәлекле урыннар һәм музейлары; әдәби топография» дип аталган. Лермонтов энциклопедиясендә чагылган уңышлы якларны өйрәнеп, Есенин энциклопедиясен дә төзүгә керешәләр. Аның концепциясе һәм структурасы турында фәнни конференциядә фикер алышканда бу эшкә алынган белгечләр, махсус пункт итеп, анда әдәби топографиягә караган мәкаләләр урнаштырылырга тиешлегенә басым ясыйлар.

Узган гасырның 80 нче елларында Нил Юзиев белән Әбрар Кәримуллин,«Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсе булдыру мәсьәләсен күтәреп чыкканнар иде. Н. Юзиев, ул чакларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни-тикшеренү планнарына кертү мөмкин булмаганга, төрле фәнни һәм фәнни-педагогик оешмаларда эшләүче галимнәр көче белән генә булса да, Тукай энциклопедиясе төзү фикеренә килеп, 1993 елда аның концепциясен һәм структурасын төзүгә керешкә, әдәби топографиягә караган материалларны урнаштыруны да күз уңында тотты.

Лермонтов энциклопедиясендә урын тапкан мондый төр материалларда шагыйрь тормышы һәм иҗатының шул заман Россия империясендәге шәһәрләр (Петербург, Мәскәү, Воронеж, Пятигорск, Саратов һ.б.), төбәкләр (Кавказ, Азәрбайҗан, Чечня, Грузия) белән бәйлелеге чагылыш таба. Ләкин Н. Юзиев бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗади эшчәнлеге юнәлешендә Лермонтовныкыннан шактый үзгә якларны да искә алып эш итәргә тиеш булды. Лермонтов – шагыйрь, прозаик, драматург, ә Тукай – шагыйрь, журналист-публицист, сатирик-юморист, җәмәгать эшлеклесе. Татар шагыйре «Фикер» газетасында, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт» журналларында җигелеп эшләгәндә, Россиядән читтә барган вакыйгалар турында да күп мәгълүматка ия була, аларга да үзенчәлекле мөнәсәбәтен белдереп тора. Менә боларны да энциклопедиянең әдәби топография жанрында язылган мәкалә-белешмәләрдә чагылдыру кирәк иде. 1998 елда кулъязма рәвешендә күбәйтелгән «Лөгатьлек»не төзүчеләр һәм редакцияләүчеләр, биш томлы Тукай «Әсәрләр»ендәге барлык төр текстларны өйрәнеп чыгу нәтиҗәсендә, Тукай феноменын тулырак гәүдәләндерердәй мондый мәкалә/белешмәләрнең саны кимендә 200 исемдә [Габдулла..., 1998, б. 66–69] булырга тиеш, дигән фикергә килделәр.

Болар арасында укучыны аеруча да кызыксындырырдай топографик объект, билгеле инде – Казан шәһәре. Аның белән Тукай ятимлек язмышына тарыган чакларда ук, реаль тормышта ук «очрашты». 1891 елның урталарында, дүрт яше тулган җәйдә, аны, Казанга алып килеп, асрамага бирәләр. Монда Мөхәммәтвәли һәм Газизә тәрбиясендә «ике елмы, күпмедер торгач» (Тукай сүзе. Р. Якупов фикеренчә, бер елдан артык [Якупов, 1976, б. 150–151]), яңадан Өчилегә Зиннәтулла йортына кайтарыла. «Исемдә калганнар»да Тукай Казанда торган вакытларын «ярты йомык күз белән генә күргән шикелле» булуын әйтә. Монда ул шәһәр тормышының матур якларын (байлар йортларын, ишек алдындагы тавис кошларын, Ташаяк базары күренешләрен) күрә, тамагы тук була. Икенче тапкыр Тукайны Казанга авылдашы Бәдри абзый алып килә. Казандагы бер кунакханәдә «бер-ике атна» яшәгәннең соңында Алты-биш Сапый аны Җаекка алып бара. Бу шәһәрдә Тукай үсә, мәдрәсәдә укый, мөстәкыйль тормышка күчә, шагыйрь һәм журналист, публицист булып җитешә. Г. Шәрәфкә язган хатыннан, газета һәм журналларда чыгып торган мәкалә һәм фельетоннарыннан күренгәнчә, ул Казандагы хәл-әхвәлләрдән шактый хәбәрдәр булган. Казанда чыга башлаган журналлар, газеталар («Казан мөхбире», «Бәянелхак», «Йолдыз», «Азат халык») белән танышкан, анда эшчәнлек алып барган кайбер затларның килешмәгән, үзенә ошамаган гамәлләрен (мәсәлән, Сәйдәшевләрнең) кискен тәнкыйть тә иткән. Шуңа да карамастан, ул Казан турында гаять уңай фикердә була. Моңа ачык дәлил – «Пар ат» шигыре. Җаектан китү мизгеленә әле биш ай чамасы вакыт калып барганда (Фикер. 1907. 6 май) язылган, беренче

мисрагыннан иң соңгысына кадәр романтик рух белән сугарылган бу әсәрдә автор шәһәргә «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» дип мөрәҗәгать итә, аныңча, монда – «...бабайларның түрләре, почмаклары, ...дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары; монда хикмәт, мәгърифәт... гыйрфан, нур... нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур». Казанга килгәч язылган бер хатында (1907 ел, 30 декабрь) ул үзенең «Уральскида вакыт шуны (Казанны – З.Р.) сөйли-сөйли авыз суларым кибет бетдеге» турында әйтә. Казанга кайту уе Тукайда шактый күптәннән туган була, ә инде яше җитеп солдатка каралу тиешлеге бу уйны чынга ашыруга ярдәм иткән шикелле килеп чыга.

Истәлекләргә таянып, Тукайның Казанга килеп җитү көне итеп хәзерге вакытта якынча 1907 елның 10 октябре күрсәтелә [Габдулла..., 2003, б. 78]. Унбиш еллар элек Казанның Печән базарында асрамага бирелгән ятим бала сыйфатында түгел, бәлки танылган шагыйрь, публицист-журналист буларак кайтып кергән Тукай, билгеле инде, үзен шактый кыю тота, «Болгар» кунакханәсенә урнашуга, газета редакцияләренә юнәлә. Казанның татар зыялылары, журналистлары, язучылары (Борһан Шәрәф, Вафа Бәхтияров, Галиәсгар Камал) белән таныша. Болар аны, әйтергә кирәк, үз итеп даирәләренә алалар. «Уклар» журналының 1906 елгы август санындагы «Яңа камустан берничә лөгать»ендә (сүзлексыман фельетонында) «Тәкәббер – Казан татары дигән сүз»ләрне язган шагыйрь, матбугаттагы чыгышларыннан, хатларыннан күренгәнчә, бу тәкәбберлек белән очрашмаган шикелле. «Кәефем вә тормышым яхшы. Дустишләр күп. Казанда тору күңелле, Уральски бик сирәк искә төшә» дип яза ул апасы Газизә Усмановага юллаган бер хатында (1907 ел, 30 декабрь). Шул ук көнне иптәше Габдулла Кариевка юллаган хатында да: «Әлхәмделиллаһ. Монда күңелле. Дуст-иш, зыялылар күп, сөйләшәбез, көлешәбез, укыйбыз, тәгаттыэ әл-әфкярда булынабыз. Кызык соң», – дип яза (һәм үзе дә, һаваланып китеп дияргәдер, Уральскида «Яңа тормыш» газетасын чыгаручыларны наданнар, җаһилләр, сабый балалар дип атый). Әмма бераздан аның тормышындагы «кызыклык»ның икенче ягы да шәйләнә. Серноводскида дәваланучы Ф. Әмирханга җибәргән хатында (1908 ел, 23 июнь) ул: «Язам шунда. Үзем хәзер бернәрсәне дә, беркемне дә сөймим. Күңел эчү белән тәмам бозылган», – дип зарлана. Җ. Вәлиди белән С. Рәмиев аның Казандагы тормышы тәртипсез булуын, кешеләр белән җиңел генә аралашып китмәвен, этикет сакламавын билгеләп үтәләр. Дөрес, холкындагы, җәмгыятьтә үз-үзен тотышындагы бу үзенчәлекле яклар Тукайның шигъри иҗатына, сәнгати фикерләвенә дә тәэсир итми калмагандыр. Ләкин шунысы да хак (һәм аеруча мөһим), тормышының Казан чорында аның иҗаты сүнми, сүрелми, бәлки әле яңа биеклеккә күтәрелә («Татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була» [Ибраһимов, 1978, б. 7] ). Халкыбызның гимнына әверелгән «Туган тел», пейзаж лирикасының

гүзәл үрнәге «Җәйге таң хатирәсе», иҗтимагый лирикага караган «Сайфия», «Көзге җилләр» кебек дистәләрчә шигырьләре нәкъ менә Казанда язылган һәм дөнья күргән. Тукай сатирасының югары ноктасы булып танылган «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында да Казан татарлары арасында яшәмәктә булган көлкеле яклар гаять зур осталык белән гәүдәләнә. Наширләр тулай китапларын бастырырга атлыгып торалар: 1907–1914 елларда аның 33 китабы Казан матбагаларында дөнья күрә. Әйтергә кирәк, шуларның берсендә – Казанның «Үрнәк» матбагасында, 1910 елда чыккан «Яңа кыйраәт»тә, дөресрәге, аның «бик күп яңа фәнни вә әхлакый мәкаләләр вә яңа шигырьләр кертелеп» төзелгән икенче табгында (басмасында) кечерәк кенә бер парча урын алган. Совет чорындагы күптомлыкларына кертелергә лаек табылмаган әлеге текст, ниһаять, хәзерге вакытта Г. Ибраһимов исемендәге институтта әзерләнә торган алты томлы академик басмага урнаштырылачак. Ул Тукайның Казан каласы турындагы уйларын аз гына мәйданда, әмма бик ачык итеп бирү ягыннан гаять тә әһәмиятле. Шунлыктан «Казан шәһәре» дип аталган ошбу текстны түбәндә укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдык:

«*Бу шәһәр мондан дүрт йөз ярым еллар әүвәл безнең ханлыгымызның иң баш шәһәре иде.*

*Бу шәһәрдә мондан биш йөз ел әүвәл Казанда ханбикә булып торган Сөембикә салган мәсҗед манарасы бу көнгә кадәр саклана.*

*Бу шәһәр безнең гыйлем ала торган йирләремезнең иң зурысы һәм иң уртасы, бу шәһәр безгә үз телемездә язылган матур-матур һәм файдалы китаплар тарата. Безнең сөекле мөхәррирләремезнең күбрәге бу шәһәрдә торганлар. Бу шәһәрнең бер-берсенә якын салынган 17 мәсҗеде шулар тирәсендә җыелып торган 20 мең татар халкы белән бөтен Русия мөселманнары күңеленә әүвәлдән бирле бертөрле якын булып килгәнләр. Бөтен Русия мөселманнары үзләренең иң зур эшләрендә башлап йөрүне казанлылардан көткән авылларга тапшырган; әле хазир дә күбрәк шулай итә. Әйе, бу шәһәр – безнең кадерле, сөекле шәһәремез. Ул шул көе калсын, шул хәлдә һаман алга барсын*» (текстны кириллицада Ф. Фәйзуллина әзерләде).

Тукай энциклопедиясе өчен әдәби топографиягә караган мәкаләләрне әзерләүчеләргә, аерым алганда «Казан шәһәре» турында язарга теләгән вакытта, бу язма белән танышу файдасыз булмастыр.

## ӘДӘБИЯТ

Лермонтовская энциклопедия. М.: Большая Российская энциклопедия, 1999.

Габдулла Тукай. Энциклопедик сүзлек-белешмә (мәкаләләр һәм белешмәләр исемлеге). Казан, 1998. 78 б.

Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли // Казан утлары. 1976. № 3.

Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 271 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 5 т. 586 б.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы***, филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты текстология бүлегенең баш фәнни хезмәткәре

УДК 821.512.145

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМ ҺӘМ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ

*Мостафа Өнәр*

Статья посвящена исследованию личности и творчества Г. Ибрагимова в контексте татарской культуры. В частности, рассмотрены его биография, педагогическая, научная и общественная деятельности.

**Ключевые слова:** история татарской литературы, культуры; личность и творчество Г. Ибрагимова.

## Татар мәдәнияте

Төркиядә «Kazan Türkləri» дигән китабы белән татар тарихын һәм мәдәниятен дөньяга таныткан Абдулла Баттал Таймас үз хезмәтендә Галимҗан Ибраһимга да зур урын бирә. Илебездә яшәгән бүтән татар мөһаҗирләре кебек үк, Совет идеологиясеннән ерак торган һәм Русиядәге сәясәтне кабул итә алмаган Баттал мәшһүр татар әдибе Г. Ибраһимның 1917 елдан соңгы иҗатын «хикәя яки роман күренешле сәяси нәрсәләр» дип тәнкыйть итә [Taymas, s. 143]. Ләкин бер үк вакытта, Галимҗан Ибраһимның Совет чорында милли татар мәдәниятен кору юлында зур хезмәт куюын да бәяләп уза [Taymas, s. 208–210].

Тюрколог буларак, Галимҗан Ибраһим турында миңа беренче мәгълүматларны ачкан кеше алтаист, телче Үзбәк Байчура булды. СССРның соңгы елында җәй көне Ленинградта танышкач, татар галиме миңа Г. Ибраһимның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» дигән хезмәтенең оригинал басмасын бүләк иткән иде. Үзенең инглиз телендә язган бер мәкаләсен дә бирде. Совет чоры татар тел белеме турындагы бу мәкаләне тиз арада Төркиядә бастырырга мөмкинлек таба алмагач, аны Һарвард университетында «Türklük Bilgisi Araştırmaları» журналын нәшер итә торган профессор Шинаси Тәкингә җибәрүемне үзенә белгерттем. АКШта басылып чыккан ул мәкаләдә, Гыйбад Алпар, Галимҗан Шәрәф кебек галимнәрдән тыш, Галимҗан Ибраһимның да татар тел белеменә керткән өлеше җентекләп аңлатыла. Язмада, шулай ук, Байчураның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» дигән хезмәт белән махсус рәвештә кызыксынуы хакында да бәян ителә [Байчура Ү., 1993, б. 9–36].

Галимҗан Ибраһимның 120 еллык юбилее уңаеннан басылган «Казан утлары» журналының 2007 елдагы 3 нче санында Шәриф Бай-

чураның мәрхүм әдип Ибраһимов турындагы истәлеген укыгач, остазым Үзбәк Байчураның миңа «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» дигән хезмәтен нигә бүләк иткәнен яхшырак аңлаган кебек булдым. Аның әтисе – мәшһүр татар журналисты Шәриф Байчура – күренекке язучыбыз белән 1911 елда ук танышкан булган икән. Совет революциясеннән соң Кызыл Армия газетасында секретарь булган Шәриф Байчура Галимҗан Ибраһим белән бергә дә эшләгән һәм язучы 1917 елда дәваланырга Кырымга киткәнче күрше булып яшәгән [Байчура, 2007, б. 99–100].

Үзбәк Байчура биргән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» китабы миңа гарәп хәрефле иске татарча текстлар укырга өйрәнер өчен яхшы үрнәк булды. Аны махсус рәвештә күчереп, большевиклар партиясе әгъзасы Галимҗан Ибраһимның милли мәдәниятне яклаган хезмәтен аерым бер мәкалә белән таныттым: *«Bir Tatar Bolşeviğinin Ana Dili Mücadələsi»* (Türk Dili, Sayı 546, Haziran-1997, 551–557). Совет революциясенең унъеллыгында татар теленең дәүләт теле, мәгариф теле буларак үсүенә шатланып, язучы болай дип белдерә: *«Руслашу тенденциясе бөтенләй җиңелде. Шул татарлашу нигезендә хәзер безнең әлифбаларыбыз, уку китапларыбыз, тел сабаклары, имлялар, сарыф-нәһү татар грамматикалары, әдәбият кануннары һәм әдәбият тарихлары тәмам эшләнеп чыгып, юлга салынды. Хәзер инде татар теленең тулы сүзлеге эшләтелмәктәдер»* [Ибраһимов, 1927, б. 34]. *«Партиянең XII съезды карарында ачык әйтелгәнчә, бу шартлар эчендә рус мәдәниятенең татар мәдәниятеннән югарылыгы, шуңар күрә татарлар өчен зәгыйфь мәдәнияттән югары мәдәнияткә күчү тиешлеге турындагы сөйләнүләр Великоруслык милләтенең элекке өстенлеген саклар өчен чыгарылган караш кынадыр. Татар арасында мондый карашларның булуы, иске замандагы русификаторлык сәясәтенең татар зиһенендә калдырган күләгәсе, үзенә түбән, ышанычсыз карарга өйрәнүенең хата нәтиҗәсе генәдер»* [шунда ук, б. 38].

Бу мәкалә чыгып берничә ел узгач, Хуҗа Әхмәт Ясәви Олыслар-арасы Төрек-казакъ университетында, Әнкарада 1 апрель 2000 елда «Идел–Урал мәгърифәтчеләре симпозиумы» булды. Анда Галимҗан Ибраһимның мирасын яктырту вазифасы миңа йөкләнгән иде. Язучының бөтен тормышын һәм хезмәтләрен, телгә алган чыгышымның текстын тулыландырып, «Türk Yurdu» журналында бастырдым: «İdil-Ural'dan Bir Aydın: Galimcan İbrahim» (Türk Yurdu, Əylül – 2001, cilt: 21, sayı 169, 58–61).

Галимҗан Ибраһимның киң әдәби мирасы соңгы елларда да мине һаман кызыксындырып торды. Эгей университеты төрек теле һәм әдәбияты бүлегендә татарча өйрәткән дәресләремдә бу хезмәтләрне кулландым һәм, «Казакъ кызы» романының гарәп хәрефләрендә басылган оригинал текстына таянып, бер диссертация темасы бирдем: Özlem Özmen, *Galimcan Ibrahim'in «Kazak kızı» romanının söz varlığı, Giriş-Metin-Dizin* (Yüksek Lisans Tezi), *2006.*

### Киң мәдәниятле биография

Галимҗан Ибраһим элекке Уфа губернасы Стәрлетамак өязенең Солтанморат авылында туа, әтисе мөгаллим һәм мулла була. Галимҗанның, авыл мәдрәсәсеннән тыш, русча мәктәпкә дә йөрүе игътибарга лаек. 1905 ел революциясенә кадәр үзе укыган Вәли мулла мәдрәсәсендә искелекләргә протест белдергән демонстрацияләрдә катнашканы өчен, аны иптәшләре белән бергә мәдрәсәдән куалар. Россиядә 1905 ел күтәрелеше белән бәйле рәвештә җәмгыятьтә тарала башлаган яңалык фикерләре аңа да тәэсир итә. 1906 елда Уфага «Галия» мәдрәсәсенә килә. 1915–1917 еллар арасында тагын мөгаллим булып кайтачак бу мәдрәсә анда көчле тәэсир калдыра. Г. Ибраһимның Стәрлетамакта башланган, Оренбург һәм Уфадан узган тормыш сызыгы берара яшәгән казакъ далаларына һәм Уралларда эшләгән төрле эшләренә сузылган, һәм ул аны 1909 елда мәдәният үзәге Казанга китерә. Яшь язучы өч ел дәвамында татар газета-журналларында мәкаләләр бастырып, «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю-сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла» кебек танылган хикәяләрен һәм «Яшь йөрәкләр» романын яза [Хәсәнов, 1974, б. 8–9]. Әдип 1912 елда Киевка китә, сәяси эшчәнлеге аркасында бер вакыт кулга алына. 1913 елның апрелендә Казанга кайтып, «Аң» журналының җаваплы секретаре булып эшләгән язучының биографиясендә 1914 елдан тагын Киевка һәм аннары Совет революциясенә чаклы мөгаллим булып эшләгән Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә барганы күренә [Даутов, Нуруллина, 1986, б. 194–200].

Авыл мөгаллименең улы Галимҗанны ул чор Россиясенең Идел–Урал тирәсендәге бөтен зур мәдәният үзәкләре үзенә тарткан: Стәрлетамак – Оренбург – Уфа – Урал – казакъ далалары – Казан – Киев – Уфа. Бу соңгы сәяхәтенең 2116 чакрымга сузылганлыгын ассызыкларга кирәк. Г. Ибраһимовның киң әдәби мирасы, көчле бер мәдрәсә белеменә өстәп алган русча мәгълүматына гына түгел, шул ук вакытта тормышның беренче 30 елында сыйган күпкырлы тәҗрибәсенә дә таяна.

### Җәдитче

XIX йөз ахырында Галимҗан Ибраһим һәм аның чордашларының туып үскән дәвере – модернизмның шәрекъ җәмгыятендә алга бару дәвере, уку һәм агарту, үсеш юлының ишеге ачык чак. XIX йөзнең башында ачылган Казан университеты, бигрәк тә Шәркыят һәм тюркология эшләренең мәркәзе буларак, хаклы рәвештә шөһрәт казана. Бу йөзлектә Россия эчендәге татар халкының секуляр хәлгә килүен (дөньяви үсеш ягына борылуын) күзаллау мөһим. Гасыр азагына табан Исмәгыйль Гаспралы башлап җибәргән, яңа бер укыту һәм мәгариф ысулы булып башланган адым, тормышның һәр ягында диярлек, кадим ысулның, кадим төшенчәсенең каршысында үсеп китә. Монда, һичшиксез, ысулы җәдитнең алга чыккан мәркәзе Казан дип әйтергә кирәк [Курат, 1965, б. 272].

Галимҗан Ибраһимның биографиясендә җәдитчелекнең зур әһә-

мияткә ия булуы күренә: яшь укытучы 1905 елгы революциядән соң ирекле форсат тапкан атмосферадан тәэсир ала һәм үзендә кайнап чыккан протест хәрәкәте сәбәбе белән мәдрәсәдән дә куыла. Язучының бу тормыш тәҗрибәсе 1907 елда язган «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясендә чагылыш таба. «Галия» мәдрәсәсеннән китүенә дә аның җәдитче һәм реформист фикерләре сәбәп була [Хәсәнов, 1974, б. 8–9].

Татар халкын гасырлар коллыгыннан һәм наданлык караңгылыгыннан коткару, укымышлы итү инициативасы белән XIX йөзьеллыкта башланган җәдитчелек адымы күп үзгәрә. Ул XX йөзьеллык башында һәм ил тышыннан, Россиядән һәм халык эченнән килә торган тәэсирләр аркылы татар җәмгыятенең бөтен катламнарына үтеп керәчәк бер көчкә әйләнә. Чөнки йөзьеллык башында инде җәдитчелек яңа заман күтәрелешенең милли идеологиясе хәленә килә. Җ. Вәлиди һәм Г. Ибраһим бу хәрәкәтнең, тормышны яңа ысулга, Европа рәвешенә алмаштыру, көнчыгыштан көнбатышка юнәлү булганын белгертә (Татар әдәбияты..., 2003). Г. Ибраһимда укучылык елларында башланган бу караш реформистлык, укытучылык һәм язучылык елларында үсә һәм 1917 елдан соң, тора-бара, революционерлыкка әйләнә.

### Укытучы

Россиядә патша хөкүмәтенең мөселман халыклары арасында, уку, агарту һәм мәдәният юлында күтәрелеш яклы җәдитчеләрне түгел, схоластик тенденцияләрне сакларга теләгән кадимчеләрне яклавын аңларга мөмкин. Шуның аркылы Галимҗан Ибраһим кебек җәдитченең 1913 елның 17 июлендә кулга алынуы һәм 1917 елгы Февраль революциясенә чаклы күзәтү астында яшәве дә моның бер дәлиле. Патша зинданнарын күргән, сөргеннәрдә яшәгән Гаяз Исхакый (1878–1954) кебек зур татар әдипләре арасында Галимҗан Ибраһимның да мәртәбәле урыны бар. 1915 ел ахырында «Галия» мәдрәсәсендә укытучылык эшен башлаган язучының, аннан аерылып, бу котлы вазифаны Әстерханда нугай татарларын укытып дәвам иткәнен күрәбез [Хәсәнов, 1974, б. 9]. Сабит Муканов һәм Мохтар Ауэзов кебек зур казакъ язучылары укытучылык шөһрәте Уралның көнчыгышына, далаларга чаклы таралган Галимҗан Ибраһимга хөрмәт белдергәннәр [Акъегет, 2007, б. 94–97].

Язучының нинди укытучы булуы, аның җәдитче, модернист ягы белән элемтәсе бигрәк тә хатын-кызларның белем алуы һәм ирекле темасында үзен күрсәтә. Язучының «Татар хатыны ниләр күрми» повесте кызларның мәктәпкә йөрү мәсьәләсен турыдан-туры көн тәртибенә куйган классик әсәр була. Беренче тапкыр 1910 елда басылган һәм баш битендә «Ирләр сурәтендә йөргән хатын, Стәрлетамак өязендә булган вакыйга» сүзләре язылган әсәргә язучы куйган түбәндәге юллар бик тә тәэсирле: *«Белә торгансыз: безнең татар галәмендә, үзенең агыр тормышына, җәбер вә җәфага түзә алмый качып китеп, табигатьнең биргән хатынлык*

*сыйфатын яшереп, ирләр сурәтендә йөрергә мәҗбүр булган мәзлумәләр сирәк-сирәк очраштыргалыйлар. Борын заманда җиде кыз, ирләр кыяфәтенә кереп, күп еллар мәдрәсәдә укыганнар имеш, соңра зур фаҗигагә очраганнар имеш, диләр. Болар хакында байтак җырлар һәм хикәяләр дә бардыр. Шу ачы хакыйкатьне мин үзем ике мәртәбә очраттым: берсе – Стәрлетамак өязендә, икенчесе Оренбургта булып, һәр икесе егерменче гасырдадыр. Стәрлетамак өязендәгесе, тикшерелгәннән соң, кулыңыздагы менә шу сәхифәләр караланды»* (Ибраһимов, 1974, б. 502–503).

Әдәбият галиме Дания Заһидуллина XX йөз башында татар әдәбиятының иң тирән нигезле темаларыннан булган укыту проблемасына карата шуларны яза: «Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек реализмы агымы укыту ысуллары хакында бәхәсләшеп мәйданга чыга. Искечә сабак бирүне, кадим уку-укыту йортларын тәнкыйтьләү һәм яңача белемнең зарурлыгын раслау, әһәмиятен күрсәтү үзәккә куела. Ф. Кәриминең “Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы” (1898), “Бер шәкерт белән бер студент” (1900), З. Һадинең “Җиһанша хәзрәт” (1906), Р. Фәхретдиннең “Әсма, яки Гамәл вә җәза” (1903), Г. Ибраһимовның “Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы” (1907), М. Акъегетнең “Хисаметдин менла” (1886) әсәрләре шундыйлардан» [Татар әдәбияты..., 2003].

**Галим**

Галимҗан Ибраһим Совет революциясенә кадәр, әдәбият һәм тел белеменә караган әсәрләр дә язган: «Татар сарыфы» (1911), «Татар нәһүе» (1911), «Татар имлясы» (1914), «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1914), «Татар телен ничек укырга» (1916) дигән басмалар, татар филологиясенең беренче җитди һәм методик чыганаклары буларак, олы кыйммәткә ия.

Язучының 1925–1927 еллар дәверендә Гыйльми үзәк башлыгы буларак галимлеге дәвам иткәнен беләбез: мәктәпләр өчен тәртипле программалар, дәрес китаплары әзерләү, ил тарихын тикшерү, табигать һәм сәнгать ядкәрләрен саклау һәм татарчаны гыйльми-әдәби яктан эшкәртү кебек гамәлләр аның шәхси тырышлыгы белән бәйле. Г. Ибраһим җитәкчелегендә, бер яктан, М. Корбангалиев, Ш. Әхмәдиев, Г. Сәгъди, Г. Рәхим кебек татар галимнәре һәм педагоглары бу үзәктә эшли, икенче яктан, Мәскәүдән М. Павлович, И. Бороздин, П. Коган вә А. Самойлович кебек галимнәр дә үзәкнең эшләренә катнаша башлый [Хәсәнов, 1974, б. 15]. Монда заманының иң алдынгы тюркологларыннан саналган А. Самойловичның Төркиядә, Мостафа Кемал Ататөрк исән чагында, Долмабакча сараенда җыелган төрек теле корылтайларының да кунагы булганын белгертергә кирәк. Утызынчы еллар ахырында Сталин репрессиясе А. Самойлович белән Галимҗан Ибраһимны бик кызганыч фаҗигале тормыш финалында кабат очраштыра.

**Җәмәгать эшлеклесе**

Язучы үзенең җәмәгать эшлеклесе һәм революционер буларак

үсүен шул юлларда аңлата: «*Минем марксист бер әдип булуым, пролетария байрагы астында эшләүне тормышымның, гомеремнең нигездәге максаты булarak сайлавым, бөтен узган тормышымның тарихи һәм мәҗбүри нәтиҗәседер*» [Хәсәнов, 1974, б. 8]. Галимҗан Ибраһимның, бүтән татар мәгърифәтчеләре кебек зинданында яткан патшадан котылу мәгънәсендәге Совет революциясенә һәм аның юлбашчысы Ленинга ихластан инанганы ачык күренә. Революциягә каләме белән хезмәт иткән язучының әле сугыш вакытында ук Кызыл армиянең иң җитди дошманы булган Колчак армиясе хакимияте астындагы җирләргә, кыяфәт алыштырып, шпион кебек керүе дә мәгълүм. 1919 елның май–август айлары арасындагы дүрт айлык сәяхәттә язучы, сатучы документы алып, авылларда урак, чалгы сатып йөри, бөтен Урал тирәсен урый, Көнбатыш Себергә кадәр бара һәм исән-сау кайта. Г. Ибраһимның үз рәхәтен уйламыйча чыккан бу зур маҗарада да бүлмәсендә утырып тормаган романтик бер җәмәгатьче икәнлеген күрәбез.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң аның сәяси һәм социаль тормышка актив катнашканын күрәбез: Ф. Сәйфи-Казанлы һәм С. Сүнчәләй белән бергә «Ирек» газетасын чыгара. Аннан аерым, Октябрь революциясеннән башлап, М. Вахитов вә Ш. Манатов белән бергә Үзәк мөселман комиссарлыгын оештыруда эшли. 1920 елда исә Татарстан халык мәгарифе комиссарлыгында һәм «Безнең юл», «Мәгариф» журналларының нигез салучысы була. Татарстан Республикасын төзүчеләр арасында, чын йөрәктән ышанган ленинчыл милли сәясәтне чынбарлыкка ашыру юлында армый-талмый эшләп, газета һәм журнал битләрендә, җыелышларда, конференцияләрдә мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать темалары белән катнашканын күрәбез [Хәсәнов, 1974, б. 13].

1926 елда Бакуда 131 рәсми делегатның катнашы белән җыелган СССРның беренче тюркология корылтаена (Первый всесоюзный тюркологический съезд) Татарстаннан да бер төркем (Гали Рәхим, Гыйбад Алпар, Сәлах Садри улы Әтнәгулов, Сибгат Гафуров, Галимҗан Ибраһим, Гаяз Максудов, Габдерахман Сәгъди, Галимҗан Шәрәф) бара. Бик күркәм гыйльми мәҗлес булуыннан тыш, монда алдан ук билгеләнгән иң мөһим эш тәртибе – Советлардагы төрки халыкларны латин әлифбасына күчерү карары кабул ителү була. Төрки дөньядагы XX йөз буенча иң мөһим җыелышларның берсе булып торган Баку тюркология корылтаенда ул көнге гарәп хәрефле әлифбаны яклаучылар арасында казакъ телчесе әдип Әхмәт Байтурсун белән бергә татар делегатлары Галимҗан Шәрәф һәм Галимҗан Ибраһим игътибарны җәлеп итәләр. Алар соңгы дәвердә билгеле бер дәрәҗәдә реформалаштырылган әлифбаны ташлап, латинга күчүгә каршы чыгалар.

Г. Ибраһимов бу корылтайдагы чыгышында төрки телнең сингармонизм һәм агглютинация үзенчәлекләрен сөйли. Орфографиягә, фонетикага нигезләнгәч,

диалектлар арасыннан сайлау кебек аермалар барлыкка киләчәген күрсәтә, морфологик принципның язуда һәм телдә берләштерүче булачагын ассызыклый. СССР КПнең моннан чыгарырга бик тырышкан латин әлифбасы карарына каршы торган Г. Ибраһим һәм иптәшләре биографияләрен уку бик кызык нәтиҗәләр биргән иде [Өнәр, 1996]. Тюркология корылтаеның 70 еллык юбилее уңаеннан Әнкарада төрек теле академиясендәге җыелыш өчен миңа Үзбәк Байчура бүләк иткән стенография беркетмәләрен эшкәртергә туры килгән иде. Соңгы елларда бу стенография китабын азәрбайҗанлы профессор доктор Камил Вәлиев белән бергә төрекчәгә тәрҗемә итеп бастыру да насыйп булды (1926, Баку тюркология корылтае, Тутанаклар).

Г. Ибраһим 1927 елдан башлап, үпкә авыруы сәбәбеннән, Кырымга урнаша һәм даими рәвештә анда яши. Исәнлеге начарайса да, гомеренең ахырына кадәр язудан туктамый. Гыйлем һәм мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1928 елда Дәүләт сәнгать фәннәре академиясе әгъзасы итеп сайлана. 1932 елда исә, Россия Үзәк Башкарма комитете карарына таянып, аңа «Хезмәт герое» исеме бирелә.

1937 елда репрессия күтәрелгән чорда Г. Ибраһимны, троцкист милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы булган оешмасында катнашуда гаепләп, кулга алалар. Хаста хәлендә Кырымнан Казанга китерәләр һәм ул төрмә хастаханәсендә 1938 елда үлә, вафатыннан соң гына аклана. Татарстан Фәннәр академиясенә караган Тел, әдәбият һәм сәнгать институты 1967 елдан бирле аның исемен йөртә.

Язучының төрмә хастаханәсендә стенага язган сүзләре искитәрлек: *«Утыз ел буенча әдәбият юлында эшләгән эшләрнең соңгы көнләрнең болай бетәчәген уйламаган идем. Нишләрсең! Тарих тикшерер, дөрес кыйммәтне бирер»* [Шамов, 2007, б. 104].

Галимҗан Ибраһим кебек патша туфракларында XIX гасыр ахырында туган буынның халыкка хезмәт итү, агарту, уку һәм укыту идеаллары белән дөнья картасын һәм дөнья тарихын алыштырганын күрәбез. Идеологияләрнең мәгънәсен югалткан бу чакта, зур татар язучысының йөз ел элек әһәмият биргән татар мәдәнияте давы әле дә көн тәртибендә тора.

ӘДӘБИЯТ

1926 Bakü Türkoloji Kurultayı, Tutanaklar. Çevirenler: Kamil Veli Nerimanoğlu, Mustafa Öner, Ankara 2008, s. 486+44. Türk Dil Kurumu Yayınları: 936.

Baitchura U.S. An overview of the development of Tatar linguistics in the Soviet Time (Introduction and Part I. Achievement in Linguistic Theory; Part II. Achievement s in Lexicography; Part III. Achievements in Grammar, GiybadAlpar and his Grammatic Teaching // Journal of Turkish Studies. 1993. Vol. 17. P. 9–36.

Kurat A.N. Tanıtmalar (Bennıgsen, Alexandre et Ch. Lemercier-Quelquejay; La Presseet le movement national chez les Musulmans de Russieavant 1920). 1965. Cilt: 23 Sayı: 3.–4, 257–282. URL: http://dergiler.ankara.edu.tr/dergiler/26/1047/12641.pdf

Öner M. I. Baku Türkoloji Kongresinde İdil-Ural Türkleri, 1926 Baku Türkoloji

Kongresinin 70.Yıl Dönümü Toplantısı (29–30 Kasım 1996), TDK. yay. 726, Ankara, 1996, 13–25.

Öner M. Bir Tatar Bolşeviğinin Ana Dili Mücadelesi // Türk Dili. Sayı: 546, Haziran-1997, 551–557.

Öner M. İdil-Ural'dan Bir Aydın: Alimcan İbrahim (1887–1938) // Türk Yurdu, Eylül – 2001, cilt: 21, sayı: 169, 58-61.

Taymas A.B. Kazan Türkleri, (3. basım) Ankara: Türk kültürünü araştırma Enstitüsü, 1988yay. 81.

Zahidullina D. Tatar Edebiyatı Tarihi (төрекчә басылуда).

Акъегет Р. Галимҗан Ибраһимов турында күренекле әдипләр // Казан утлары. 2007. № 3. 94–97 б.

Байчура Ш. Без узган еллар // Казан утлары. 2007. № 3. 98–100 б.

Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: библиографик белешмә. Казан, 1986. Б. 194–200.

Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? Казан: Татарстан Дәүләт нәшрияты басмасы, 1927.

Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т.

Саляхова З.Г. Натурализм в творчестве Галимджана Ибрагимова: дис. ... канд. филол. наук. Казан, 2004. 181 с.

Заһидуллина Д. Модернизм һәм ХХ йөз башы татар прозасы // Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов // Ибраһимов Г. Әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 1 т.

Шамов А. Галимҗан Ибраһиовның соңгы көннәре турында истәлекләр // Казан утлары. 2007. № 3. Б. 101–104.

***Мостафа Өнәр,***
Эгей университеты профессоры, Измир
e-mail: mustafa.oner@ege.edu.tr

УДК 821.512.145

# ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВ: ТЫЕЛГАН ТЕМАЛАР – ЯҢА ФОРМАДА

*Д.Ф. Заһидуллина*

В статье устанавливается теоретический потенциал категории «постромантизм» относительно татарской литературы 1960-х гг. На примере произведения Ш. Хусаинова «Печаль любви» исследуются разные формы синтеза принципов романтической и реалистической поэтики. Определяются уровни художественной структуры произведения, на которых она осуществляется, и приемы интеграции элементов, принадлежащих к разным художественным системам. В частности, романтический герой и мир искусства, с одной стороны, и критический тип авторского сознания, аналитико-оценочное начало, направленное против тоталитарной системы, внутренний конфликт героя-романтика, сформированный под влиянием внешних факторов, социальная мотивация его поступков приводят к трансформации романтических традиций. Психологизм, направленность на общечеловеческие ценности, лиризм и философичность придают особое звучание повести.

**Ключевые слова**: татарская литература, постромантизм, романтический герой, субъектная сфера, символ, психологизм.

1960–1980 еллар татар драмасында үзгәрешләрне башлап җибәргән, аның тематика һәм сурәтлелек ягыннан баюын, эчтәлек һәм форма ягыннан камилләшүен тәэмин иткән талантлы драматургларның берсе Шәриф Хөсәенов (1929–1999) була. Аның «Профессор кияве» (1952) комедиясе, бигрәк тә «Әни килде» (1965) драмасы татар әдәбиятында милли әхлакый канупнар, аларның яңа заманда югалуы-бозылуы, шул сәбәпле кешеләрнең кешелек сыйфатларын югалтуы хакында зур сөйләшү башлап җибәрә, тамашачы алдында яшь буындагы әхлаксызлык һәм эгоистлык, җәмгыятьнең ялганга корылуы, кешенең кадере җуелу, туган җирне ташлау кебек проблемаларны күтәрә. Драматург әхлаксызлыкның кеше холкына хас булуын, ләкин җәмгыятьтәге борынгыдан килгән милли тормыш-яшәеш рәвешенең әхлак кануннарын саклауга юнәлтелгәнлеген ассызыклый. Яңа җәмгыятьнең дини-мәдәни йола-гадәтләргә каршы көрәшүе кешелеккә килгән фаҗига дәрәҗәсенә күтәрелә. Драма үзе татар сәхнәсен тоткан әсәрләрдән булып, 17 телдә илнең 48 театрында куела [Әдипләребез, 2009, б. 608].

Драматург проза өлкәсендә дә каләм сыный, һәм аның «Мәхәббәт сагышы» (1964) лирик-романтик повесте татар прозасында яңа мәй-

дан ачкан әсәр булып танылa (әсәр укучы кулына иртәрәк тә барып җитә: «Казан утлары» журналы аны 1960 елның 4, 5, 6 саннарында бастырып чыгара. Аерым китап булып 1965 елда дөнья күрә). Ул бик тиз популярлашып китә, халык тарафыннан җылы кабул ителеп, кулдан-кулга йөртеп укыла. Моның сәбәбен билгеләп, Р. Фәйзуллин болай дип яза: «Хикмәт повесть каһарманнарының кемнәр һәм вакыйгаларның кайда һәм ничек баруында түгел, хикмәт – мәгълүм бер чор, әйтик, 50 нче еллар яшьләренең рухын ачуда, күңел тибрәнешләренең тәңгәллеген сиздерүдә, уртак кылда уйный алуда!» [Фәйзуллин, 1998, б. 111]. Чыннан да, әсәр шундый итеп уйланылган: бер яктан, повесть геройлары «Хрущев җепшеклеге» алып килгән фикер иркенлеге заманында яшиләр. Ләкин шәхес культы, аның өрәге җәмгыятьтә исән һәм шул иркенлекне тыючы, тоткарлаучы көч булып кала бирә. Язучы әлеге каршылыклы рухи-мәдәни атмосфераны тулы бер образ итеп тергезә алган.

Сәяси-иҗтимагый тәнкыйть сыйфатлары калку бирелгән повесть, басылып чыгуга, матбугатта шактый каршылыклы бәя ала. Аерым алганда, «Социалистик Татарстан» газетасының 1960 елгы 11 декабрь санында татар мәдәниятенең күп талантияләрен советчыл идеологияне аңламауда гаепләп, язмышларын сындырган Ф. Мөсәгыйть тискәре рецензия белән чыгыш ясый (шунысын да билгеләп үтәргә мөмкин, Мөсәгыйть элегрәк гаять ямьсез рецензияләре белән Ш. Хөсәеновның драма әсәрләрен «төзәтергә» мәҗбүр итә). Әлеге бәя әсәрнең үз вакытында анализланып, әдәби процесста урыны билгеләнүгә комачаулаган иң төп факторлардан була. Чөнки 1937 еллардагы Мөсәгыйть кебекләрнең тәнкыйтеннән соң кулга алынулар, юкка чыгулар, бер бирелгән бәяне үзгәртергә тырышуларның да тәнкыйтьче-галимнәрне эзәрлекләүгә җирлек булуы хакындагы мәгълүматлар җәмгыятьнең хәтерендә әле.

Әсәрнең әдәби процесста объектив бәясен алмауга тагын бер сәбәп – аның чор әдәбияты фонында нык аерылып торуы, идеология тарафыннан читләштерелгән романтизм, дөресрәге, постромантизм юнәлешендә иҗат ителүе була. Бу очракта «пост» элементы классик романтизм мөрәҗәгать иткән мотивларны файдаланып та, аның чикләреннән чыгып китү, «үзен туендырган бөтен нәрсәне кире кагу» турында сөйли [Лексикон нонклассики]. Шул ук вакытта «төрле эпохалар һәм халыклардагы романтикларны тормышның романтик тәгълиматы берләштерә» [Гуляев, 1998, с. 11]. Н.А. Гуляев фикеренчә, романтизмның төрле формалары һәм агымнары да асылда бер үк кыйммәтләр тирәсенә тупланып бетәләр.

1960 еллар татар әдәбияты мәхәббәт, шәхеснең рухи хөрлеге, бәхет, сайлау иреге шикелле саф романтик мотивларга бары тик иҗтимагый шәрехләп мөрәҗәгать итә. Саф романтизм традицияләре шигърияттә, массачыл әдәбиятта сакланып килә. Бу гомумән совет әдәбиятларына хас күренеш, рус әдәбиятында да 1950 еллар ахырына

кадәр романтизм читкә тибәрелә [Хрулев,1994, с. 10]. Менә шундый шартларда иҗат ителгән «Мәхәббәт сагышы» повесте, бер яктан, алга таба милли әдәбиятыбызда саф романтизмны тергезүгә этәргеч бирә. Икенче яктан, үзенчәлекле яңа сукмак – построматизм агымы өчен чишмә башы булып тора.

Галимнәр фикеренчә, построматизм классик романтизм куйган барлык сорауларны кабат укучы белән сөйләшү мәйданына менгерә, ләкин ул сорауларга табылган барлык җавапларны кире кага. «Романтизмда илаһилык, югарылыкны беренче урынга чыгару күзәтелә, боларның дошманы да төгәл билгеләнә. Построматизмның үзенчәлеге дә шунда, монда инде мәхәббәтне, иҗатны, намусны юк итү – иҗтимагый төсмерле, ул әхлакый, табигый сәбәпләр белән генә аңлатыла алмый башлый» [Лустенко]. Ш. Хөсәенов повестенда да без шуны күрәбез.

Күләмле повесть 34 бүлектән гыйбарәт. Әсәрдә төп герой – «этиәниләре үк Казанда туып үскән төп Казан кешесе» [Хөсәенов, 2006, б. 15] Хәбир Сыртланов. Повестьта аның үсмерлектән яшьлеккә аяк басуы, гашыйк булуы, профессиональ композитор буларак уңышларга ирешүе, мәхәббәтен югалтуы тарихы бәян ителә. Беренче бүлеке музыка өлкәсендә Хәбирнең таланты хакында сөйләүче – берничә ел элек сәхнәгә куелган балетының кабат тамашачыга күрсәтелеп, халык тарафыннан гаять җылы бәяләнүе күренешеннән башланып китә. Үткәннәргә әйләнеп кайтып, язучы шул әсәр язылган вакытка, Хәбирнең мәхәббәт тарихына мөрәҗәгать итә.

Гомумән алганда, татар әдәбияты сәнгать кешеләренең, шәһәрдә яшәүчеләрнең тормышын сурәтләүгә сирәк алына. Бу очракта тормыш материалы үзе үк татар укучысын үзгә, ят дөньяга дәшә.

Хәбир саф романтик герой итеп уйланылган: хис кешесе, талант иясе. «Музыкага талант аңа этисеннән – Габәши һәм Сәйдәшев белән якыннан таныш булган, күңелендә якты һәм зур хыяллар тибрәткән, ләкин, музыкаль белеме булмау сәбәпле чәчәк атмыйча йомылып калган һәвәскәр музыканттан күчкән» [Хөсәенов, б. 15]. Шунда ук автор Хәбирнең сәләтен күрсәткән бер вакыйганы искә төшерә: этисе янына килгән Сәйдәшевның «моңа кадәр бер җирдә дә башкарылмаган» көен бәләкәй Хәбир бер кулы белән пианинода кабатлап чыга. Әнисе Бибиҗамал, ире һәм ике олы улы сугышта үлеп калгач, бөтен көчен Хәбирне үстерүгә, аны зур кеше, танылган музыкант итеп әзерләүгә бирә. Музыка мәктәбен, аннан музыка училищесын тәмамлап, консерваториянең композиция классына укырга кергән героеның беренче курста имтиханнар биреп йөргән вакытта гашыйк булуыннан, бишенче бүлектән башлап, автор каләме әлеге мәхәббәтнең нинди сынаулар үтүен тасвирлауга алына.

Әдәбият белемендә саф романтик геройларның өч тибын аерып карыйлар [Слюсарь, 1992, с. 133]: үз «Мин»ен бөтен дөнья белән тәңгәлләштергән шәхес (бу төр романтик геройлар милли әдәбиятыбызда

гыйсъянчылык агымын хасил итә); идеал һәм чынбарлыкны бербөтен кебек кабул итә торган табигый гармониядәге шәхес; гавам кешесе. Хәбир – бу төркемләүдәге икенче типка караган, яшәеш белән табигый-гармонияле мөнәсәбәттәге герой (татар әдәбиятының милли традицияләрендә тудырылган герой дип тә әйтә алабыз). Язучы аның гашыйк булуын да шул табигый агымга буйсыну кебек тәкъдим итә.

Мәхәббәт аңга бәйсез хис, инстинкт итеп тасвирлана. «Үзеннән берничә өстәл аша утырган, «Сезең сәгатегез юкмы?» – дип, вакыт белән кызыксынган карасу йөзле, сул яңагында кечкенә генә миңе дә булган бу кызга ни өчен игътибар итүен Хәбир үзе дә аңламады. Ул әле дөнья күргән, хатын-кыз тирәсендә йөреп шомарган ир булудан ерак, хатын-кызга ирләрнең ник табынуларын чынлап аңламаучы сафлыкның чын мәгънәсендәге мисалы булган егет иде. Ләкин ниндидер бер инстинкт, ул аңламаган, аңа таныш булмаган, шул ук вакытта аңа буйсынмаучы, аның өстеннән хакимлек итүче көч аны тагын һәм тагын шул кызга карарга мәҗбүр итте» [Хөсәенов, б. 19]. Ул көч егетне тулысы белән үзенә буйсындыра, уйлары, эш-гамәлләре һәм хисләре белән идарә итә башлый. Бер үк вакытта шифасы аның күңелен матурлык тойгысы белән тутыра: «Хәбир бөтенләй икенче кешегә әйләнде. Башта аңа һәр кеше үзгәргән, матурланган, әллә нишләгән булып күренде. Аннары кешеләр аның үзен әллә нишләгән дип таптылар» [Хөсәенов, б. 20]. Һәм шушы дулкында Хәбирнең музыкага карашы, аны кабул итүе дә үзгәрә: «Ул алар да элек күрмәгән дә, уйламаган да гүзәллекне ачты, музыканың сихерле авазларыннан моңсу күңеленә шатлык, авыру йөрәгенә шифа тапты. Музыка тудырган кичерешләр аны юаттылар, яшәргә, тормышның нурлы биеклекләренә өндәделәр. Һәм ул юанды, яшәде (...) Ул авазлар күңелнең иң нечкә кылларын чиртәләр, Хәбирне икенче мохиткә, мәхәббәт белән, бәхет белән тулы хыялый дөньяга алып китәләр» [Хөсәенов, б. 21].

Шуннан соң язучы, лирик-эмоциональ чигенеш ясап, Хәбирнең хыялын, хыялында кояш чыккан вакытта чишмә буенда Мәдинә белән җитәкләшеп басып торуларын, үргә менүләрен, давыл чыгуны, Хәбиргә канатлар үсеп, аларның очып китүләрен, гүзәл болынга төшеп кунуларын... сурәтли башлый. Шуның артыннан ук авторның, укучыга эндәше рәвешендә, тагын бер кат мәхәббәткә мөнәсәбәте белдерелә: бу хисне татымаган кешеләрне кызгануын әйтеп, язучы мәхәббәтне бернинди исәп-хисапка да буйсынмаган «иң зур, иң бөек гүзәллек» дип атый.

Шунысын да искәртергә мөмкин: дөньяга романтик караш герой аша гына түгел, автор тарафыннан да җиткерелә. М.М. Бахтинның «әсәр белән ике закончалык: герой закончалыгы һәм автор закончалыгы, эчтәлек һәм форма закончалыклары идарә итә» [Бахтин, 1972, с. 172] дигән сүзләре романтизмда аеруча ачык чагылыш таба. Татар әдәбиятында XX йөз башында мәйданга чыккан саф романтизм авторның да романтик карашлы

булуына нигезләнгән иде. Ш. Хөсәенов иҗатында исә без авторларның аналитик-бәяләүче башлангычының алга чыгуы белән очрашабыз. Ул һәрчак вакыйгаларны алдан ук мотивлаштырырга, шәрехләргә омтыла. Әйтик, Хәбир күңелендәге сөю хисләре, аның фикер һәм кичерешләре белән янәшә, улындагы үзгәрешләрне сизгән ана күңелендәге икеләнү-борчылуларны да язучы янәшә тасвирлый, анада әлеге билгесез кызга карата нәфрәт хисе уянуны күзәтә башлый, шулай алга таба булачак гайре табигый хәлне шәрехли-аңлата бара.

Әсәр сюжеты табигый агым белән үсә: күп каршылыклар аша узып булса да, геройлар танышалар, Хәбир үзенең яратуын аңлата. Менә шулай классик традицияләр буенча барган әсәргә 11 нче бүлектән бөтенләй үзгә мотив килеп керә: шәхес культы. Бу бүлек Мәдинәнең искә төшерүе кебек уйланылган. Абыйсына 11 яшь булган, Мәдинә беренче класска укырга кергән елны әтиләре Хисаметдин Сәгыйдуллинны «нахак бәлаләр» белән төрмәгә утырталар. Язучы беренче җөмләдә үк, «нахак бәлаләр» фразасын кулланып, әлеге хәлгә бәя биреп уза. Мәдинәнең әнисе «Фәхрия апа берничә ай аһ-ваһ килеп йөрде дә, үзе башлангыч классларны укыткан мәктәптә “Халык дошманы булган кешенең хатыны яшь буынны тәрбияли аламы?”дигән ың-шың чыккач» [Хөсәенов, б. 39] иреннән баш тартып, «колхозлашу елларында авылдан качкан Хәбибулланы» йортка кертә. Алга таба язучы ялкау-эшлексез, сансыз, эчкече ирнең тискәре образын бик төгәл детальләрдә тергезә. «Ана белән балаларны өйдән куды». «“Синең ирең – халык дошманы. Синең үзеңне дә, бурсыкларыңны да атып үтерү кирәк!” дип җикеренде Хәбибулла». «Гаилә корып яшәгән унике еллык гомере эчендә йорт салып, әллә никадәр өй җиһазлары, көнкүреш әйберләре булдырып өлгергән Хисаметдин Сәгыйдуллинны ул буржуй дип сүкте, хәзер замана безнеке, без буржуйларның тамырын корытырга тиешбез, дип кәперенде» [Хөсәенов, б. 40] һ.б. Шул рәвешле язучы 1917 елдан соң илдә эш кешесеннән сыйнфый дошман ясап, эшлексезләргә юл ачкан үзгәрешләр булуын, аларның гомумкешелек кыйммәтләрен киресенә алмаштыруын ассызыклый. Хәзер инде без, татар әдәбиятында романтик әсәр авторының амплуасы үзгәрү мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, моны әсәрдә җитди мәсьәләләр күтәрелү белән бәйләп куя алабыз. Романтик типтагы автор, әлбәттә, мондый катламны әсәрдә күтәреп чыга алмаган булыр иде. Бу үзенчәлеккә Барлас Камалов та игътибар итә (1989): «Ул повесть, заманында, кайберәүләрне сагайтты, бер иш кешеләр аны хәтта кабул итә алмадылар, чөнки бу – тормышыбызны бизәп күрсәтеп, үз-үзебезне алдап яшәгән заман иде. Шәриф исә шул чакта ук үзенең алдашырга теләмәүче икәнен исбатлады. Һәр изге эшнең ялганга түгел, хакыйкатькә нигезләнгәнлеген, ышанмаучылыкка түгел, инануга, шөгыльгә, матурлыкка корылганлыгын яшь автор яхшы белә иде» [Камалов, 2006, б. 175].

Бу урында автор биографиясендәге аның гражданлык активлыгы, битараф булмавы турында сөйләүче тагын кайбер детальләргә игътибар итәргә кирәк. Шәриф Хөсәенов – җәмгыятьтәге тискәре күренешләр белән риза булмыйча, төрле инстанцияләргә ачык хатлар юллаган шәхес. Әйтик, 1955 елда Н.С. Хрущевка гади кешеләрнең матди яктан бик авыр яшәвен әйтеп хат язуы, 1957 елда К.Е. Ворошиловка заемнар мәсьәләсендә халыкка ярдәм итүен сорап мөрәҗәгате, 1989 елда Мәскәүгә депутатларның битарафлыгын искәртеп телеграмма сугуы, шул ук елда М.С. Горбачевка милли республикалардагы хәл өчен ачынып хат юллавы, үзәк газета-журналларга мөрәҗәгатьләре һ.б. документлар аның ихластан илдәге хаксызлыкларны, кимчелекләрне бетерергә омтылышын дәлиллиләр. Әдәби әсәрләре аша ул бу хәрәкәткә халыкның үзен дә тартырга тели.

Тышкы, көнкүрештәге үзгәрешләр белән чикләнмичә, язучы әсәрендә яңа идеологиянең кешеләрнең эчке дөньясын бозуына да игътибар итә. Моны иреннән баш тарткан Фәхрия апа кичерешләреннән башлап, Мәдинә һәм Искәндәр кабул итүендә үстерә килә. Сеңлесенең әтисенә кагылышлы сорауларына Искәндәр ялган белән җавап бирә: «Ул әтисен яхшы итеп кенә хәтерли. Икәүләп демонстрациягә чыгуларын, трибуна алдыннан узганда әтисенең ничек иңбашына утыртуын, Иделгә балык тотарга төшүләрен, әниләре төенләп биргән азыкның өйдә онытылып калуын, ашыйсылары килеп бетүен, аннары әтисенең әллә каян бик тәмле икмәк табып килүен – шундый бик күп хатирәләрне күңелендә саклый Искәндәр. Шуңа да карамастан, ул үз ялганына үзе ышана язып, Диккенс китапларыннан укып белгән явыз кешеләрнең сыйфатларын әтисенеке итеп сөйли. Соңыннан сеңлесенең башын арык, сөякчел күкрәгенә кыса да тәкърарлый башлый: «Безнең әтиебез юк. Ул халык дошманы. Безнең андый кешенең балалары буласыбыз килми» [Хөсәенов, б. 42].

Мәдинәнең пионерга керергә теләве белән бәйле хәлләр, башка балаларның аны ачыктан ачык гаепләве, үги атаның очраган бер кешегә Мәдинәнең әтисе «утыз җиденче елгылардан, төрмәдә бетте» дип кычкыруы – болар барысы да, аталарын ни өчен төрмәгә утыртуларын беркемнең дә белмәве турында кат-кат кабатлау белән янәшә килеп, шул елларның ялган һәм куркку белән тулган атмосферасын, шул атмосфераның кешеләр күңелен гарипләндерүен күрсәтә.

Әлеге мотивны тагын да үстереп, язучы әсәрнең 12 нче бүлегендә Искәндәр белән Мәдинәне әтиләре белән очраштыра. Гаять тәэсирле язылган бу бүлектә ата һәм балалар язмышы фаҗига дәрәҗәсендә тасвирлана. Автор Хисаметдин авызыннан гаебе юклыгы, халык алдында намусы чиста булу хакындагы сүзләрне әйттерә. Шушы бүлектә ул Хисаметдиннәр гаиләсе фаҗигасен ил фаҗигасе – куркытылган, җәберләнгән халык фаҗигасе – кебек бәяли.

Алга таба бу мотив 20 нче бүлектә кабат калкып чыга. Мәдинәне

кабул итә алмаган, аннан гаеп эзләгән Бибиҗамал – Хәбирнең әнисе – әлеге фаҗигаләр турында ишетә. Аның улы белән сөйләшүендәге «Күрәләтә дошман белән бәйләнергә башына тай типмәгән», «Синең атаң эрвалүтсия елларында совет власте өчен сугышып йөргән кеше. Шушы властьны яклап, үткән сугышта башын салды. Җиләк кебек ике абыең шушы власть өчен үлеп калды. Судның бусагасын атлап баскан кеше юк безнең нәселебездә, шаһит булып кына да судта булган кеше юк. Атаң белән абыйларың истәлеге кадерле булса, якларына да әйләнеп карама, өйләренә бара торган юлны да оныт. Менә шул сиңа актык сүзем. Атаң белән абыйларың җаннарын биргән хөкүмәткә каршы кешеләр белән аралашырга, нәсел пычратырга мәңге рөхсәтем юк!», «Гаебе булмаган кешене төрмәгә утыртмыйлар» [Хөсәенов, 2006, б. 86–87] кебек сүзләре Хәбир күңеленә шик сала. Ләкин бу шикләргә мәхәббәт һәм аның җимеше – Хәбирнең музыкасы каршы төшә. «Шул йөрәк бит инде аңа канатлар үстерде, композитор булырга ярдәм итте. Тик шул йөрәк өчен генә, шул йөрәктә тамыр җәяргә лаек булу өчен генә, ул тән һәм җан аруны онытты – егерме өч яшь тә тулмаган килеш, сәхнәгә менәрлек әсәр тудырды. Шулай булгач, тормыш дулкыннары аларны очраштыргач, мәхәббәт аларның чәчләрен бер-берсенә бәйләгәч, кайчандыр аерым-аерым саркыган бүгеннәре һәм киләчәкләре тоташып, аралашып, уртак бер чишмәгә әйләнгәч, икесе ике җирдә пыскыган өмет һәм хыяллары бергә кушылып, баш очларында маяк булып кабынгач, үкенергә, кире чигенергә мөмкинмени?!» [Хөсәенов, б. 88–89].

Ләкин бу уйлар Хәбирне барыбер борчудан туктамый. Аның өчен фикере өстенлекле чын абруй булган остазы Салават белән сөйләшү дә шуны күрсәтә. Бу очракта, карт композитор да Хәбирнең әнисе фикерен яклый. Аның «анкета – зур нәрсә, иҗат кешесе өчен бигрәк тә» [Хөсәенов, б. 99], дигән сүзләре инде Хәбир күзлегендә мәхәббәтне киләчәк карьерага каршы куя.

Салават ага белән сөйләшү һәм Хәбирнең премьерасы мәхәббәт сюжетының кульминациясенә әйләнә. Шуннан соң Хәбир Мәдинәдән читләшә, кыз исә, укуын тәмамлап, шәһәрдән үк китеп бара. Ул кияүгә чыга, кызы – Гүзәл туа. Хәбир янәдән Мәдинәне кайтарырга омтылып караса да, бала бу адымга комачау ясый.

Югарыда Хәбирне икенче типка караган герой, яшәеш белән табигый-гармонияле мөнәсәбәттәге шәхес буларак бәяләгән идек. Әдәбият теориясе беренче һәм өченче тип геройларны – эгоцентриклар, үзләрен яратучылар, икенче тип геройларны – альтруистлар буларак карый [Хөсәенов, б. 134]. Чыннан да, аның дөньяга альтруистик карашы, иң беренче чиратта, гашыйк булгач, кешеләргә искиткеч әсәр бүләк итүдә күренә. Ләкин Мәдинәдән баш тарту аның шәхесендә эгоцентрик башлангычны алга чыгара. Саф романтизм традицияләрендә, автор героендагы эчке карашылыкны шулай формалаштыра. Мәхәббәт белән бергә иҗат итү сәләте дә югалу – Мәдинә киткән-

нән соң, Хәбирнең башка көчле әсәр иҗат итә алмавы – шул хакта сөйли. Әгәр классик романтизмда мәхәббәтне югалту – рухи үлемгә, матурлыкның, бәхетнең югалуына тәңгәлләштерелсә, Ш. Хөсәенов повестенда ул гармониянең, табигыйлекнең, талантның, рухи көчнең җуелуы булып аңлашыла. Әсәрнең йомгагы, геройның көчле позициягә чыгарылган сүзләре аны җыеп торучы үзәккә әверелә: «Төпсез өметсезлек һәм өметсез сагыш тулы күзләре өй эченә төште. Болын хәтле квартира. Водопровод, электр, газ. Әллә никадәр мәшәкатьләр белән, әллә кемнәргә «чәйлек» төртеп эләктергән чикләвек гарнитур: кием шкафы, сервант, карават, өстәл, тумбочка, көзге һәм креслолар. Болгариядән килгән китап стеллажлары, китаплар. Әнисе Ашхабадтан алдырткан зиннәтле келәмнәр. Теләсә кемне кызыктырырлык немец рояле. Кытай вазалары... Никадәр байлык. Мәскәү радиосы аның музыкасын тапшыра. Аны бөтен ил, бөтен дөнья тыңлый. Һәммәсе җитеш, һәммәсе бар. Һәм бернәрсәсе дә юк. Чөнки күпләр табынган бу мал-мөлкәт, бу зиннәт, бу дан-шөһрәт чүп кадәрле дә тормый хәзер. Ул аларның барысын, барысын да, хәтта талантын да шып-шыр өйнең ялангач сәкесендә утыручы бер Мәдинәгә дүрт куллап алыштырыр иде. Ләкин моны эшли алырлык тылсымчы дөньяда бармы соң?!» [Хөсәенов, б. 148]

Шулай итеп, әсәр Хәбирнең Мәдинәне мәңгелеккә югалтуын аңлау ноктасында төгәлләнә. Бер яктан, язучы шәхес культы фаҗигасен, аның кешеләрдәге куркуны беренче планга чыгаруын, коммунистик идеология алып килгән ялганны, ялган кыйммәтләргә йөз белән борылуны әдәбият мәйданына чыгара, татар әдәбиятында мондый тәнкыйть беренче тапкыр яңгырый. Әсәр ахырында китерелгән эчке монолог та сайлау алдында калган романтик геройның, иң беренче чиратта, асыл кыйммәтләр, гомумкешелек кыйммәтләре белән ялган кыйммәтләрнең берсен сайларга тиешлеген ассызыклый, төп вакыйганы иҗтимагый мотивлаштыра. Шушы сыйфаты белән әсәр классик романтизм традицияләрен кире кага да. Хәтта соңгы көрәшүдә, әсәр ахырында кызның әтисендәге төрмәдә дә исән сакланып калган йөзекне (ул повестьта әнисенең үзендәге йөзекне саклый алмавы белән янәшә урнаша) калкытып куе йөзекне символга әйләндерә.

« – Хуш, Хәбир!

Мәдинә кулын суза. Кинәт Хәбир баскан урынында чайкалып китә: Мәдинәнең бармагында йөзек. Теге шомлы төндә әтисе бүләк иткән, күз яше шикелле җемелдәп торучы зөбәрҗәт кашлы йөзек. Изге ядкарь кигән кулга кагылырга Хәбирнең көче җитми» [Хөсәенов, б. 148].

Шул рәвешле, йөзек – намусны саклау, асылыңа хыянәт итмәү символы мәгънәсендә күрсәтелә. Үз асылына хыянәт иткән Хәбир аңа кагылырга базмый. Иҗтимагый сызыкның идеясе дә, теләсә нинди заманнарда, ситуацияләрдә кешенең кешелеклелеген, намусына, үзе ышанган-табынган кыйммәтләргә тугрылыгын саклавын тормышта матурлыкның,

мәхәббәтнең саклануы өчен төп шарт итеп куя.

Романтизмның асыл сыйфаты, аның башка юнәлеш-методлардан аермасы – чынбарлыкны түгел, аның моделен күрсәтүдә [Тураев, б. 159] булу гомумбилгеле. Шәриф Хөсәеновның мәхәббәтне югалту сюжетына корылган лирик-романтик повестеның идея-эстетик кыйммәте, татар әдәбиятына алып килгән зур яңалыгы да шушы модельнең чиктән тыш гомумиләштерелгән, кешелек кыйммәтләре хакындагы гуманистик карашларны ассызыклауга корылган булуы белән билгеләнә.

Ш. Хөсәенов иҗатына үзенчәлекле бәя биргән Б. Камалов аңа популярлык китергән «Әни килде» драмасы (бу әсәрне кайбер театр коллективлары «Әниемнең ак күлмәге» исеме белән сәхнәләштерде) турында болай яза: «Монда инде мәгънә тирәнәя, күңел сафлыгы, рухи сәламәтлек белән бергә масштаблылык алга чыга. Монда инде Әни балалар анасы гына булып калмый. Ил-Ана дәрәҗәсенә үсә» [Камалов, б. 176]. Чыннан да, татар драматургиясе тарихында иң билгеле әсәрләрдән булган әлеге драмада автор ана язмышын – Ил-Ана язмышы кимәленә куя, һәм тамашачы-укучыны Анага – Илгә – узганга мөнәсәбәт хакында сөйләшүгә тарта. Моңа ана образын типиклаштыру, символ дәрәҗәсендә тәкъдим итү аша ирешелә.

Әлеге драма белән янәшә, бер үк вакытта иҗат ителгән «Мәхәббәт сагышы» повестенда исә мәхәббәт символ югарылыгына күтәрелә. Ул Хәбир белән Мәдинәнең генә беренче мәхәббәте булып аңлашылу чикләреннән чыга, гомумән сөю, аның кеше тормышындагы һәм кешелекнең яшәешендәге урыны, роле, әһәмияте мәсьәләләре куела. «Әниемнең ак күлмәге»ндә Ана (Ил) – ерак гасырлардан килгән рухи-әхлакый кыйммәтләрне, кешелек җәмгыятендәге Яхшылык, миһербанлылык, сабырлык кебек нигез баганаларын саклаучы, киләчәк буыннарга тапшыручы буларак шәрехләнсә, повесть эчтәлегендә мәхәббәт – рухи гармонияне, камиллекне, талантны, Матурлыкны булдыручы һәм саклаучы кыйммәт төсен ала. Язучы рухи байлыкны матди муллыкка каршы куя да, мәхәббәтне ике арадагы чик итеп карый. Байлыкның рухи бушлыкка тәңгәллек фикерее Ш. Хөсәеновның башка әсәрләрендә, публицистикасында, хәтта әңгәмәләрдә ассызыклана [Юныс, 2006, б. 158–173].

Әлеге повесть артыннан ук татар әдәбиятында романтизмга өстенлек биргән, шәһәр зыялылары тормышын үзәккә куйган башка әсәрләр дә иҗат ителә. Бу хәрәкәткә роман кебек зур жанрлар да тартыла (Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» (1965) романы). Ләкин акцентларны билгеләү ягыннан Ш. Хөсәенов повесте чор әдәбиятында аерылып тора. Аннан соң иҗат ителгән әсәрләрдә эш-гамәлләрне иҗтимагый мотивлаштыру, детерминацияләүгә омтылыш сакланса, без анализлаган әсәрдә тоталитар системага каршы иҗтимагый-сәяси тәнкыйть алга чыга.

ӘДӘБИЯТ

Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 том. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 608–609.

Бахтин М.М. Эстетика словесного творчества. М.: Наука, 1979. 423 с.

Гуляев Н.А. О формах романтической типологии // Романтизм: грани и судьбы. Ч. 1. Тверь, 1998. С. 11–36.

Камалов Б. Тормышның тамырын тоеп (Шәриф Хөсәеновка 60 яшь) // Шәриф Хөсәенов: повесть, очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар / төз. һәм кереш сүз авт. Р. Йосыпова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 174–177.

Лексикон нонклассики. Художественно-эстетическая культура XX века / под. ред. В.В. Бычкова. URL: http://www.//niv.ru/doc/aesthetic/lexicon/index (мөрәҗәгать итү көне: 27.01.2014.)

Лустенко А. Метафизика французского постромантизма. URL: http://www. krylya. se-ua.net› (мөрәҗәгать итү көне: 26.01.2014).

Слюсарь А.А. О поэтике романтического произведения // Романтизм: вопросы эстетики и художественной практики. Тверь, 1992. С. 131–149.

Тураев С.В. От Просвещения к Романтизму. М.: Наука, 1983. 256 с.

Фәйзуллин Р. Очрашулар // Р. Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 4 нче том. Б. 111–119.

Хөсәенов Ш. Мәхәббәт сагышы // Шәриф Хөсәенов: повесть, очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар / төз. һәм кереш сүз авт. Р. Йосыпова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 8–149.

Хрулев В.И. Романтизм Александра Грина (эволюция и сущность). Уфа, 1994. 229 с.

Юныс Р. Кримпленнан тегелгән бәхет (драматург Шәриф Хөсәенов белән әңгәмә) // Шәриф Хөсәенов: Повесть, очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар / төз. һәм кереш сүз авт. Р. Юсупова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. Б. 158– 173.

*Статья написана при поддержке гранта РГНФ. № 14-14-16002*

***Заһидуллина Дания Фатыйх кызы***,
филология фәннәре докторы, профессор, академик,
Татарстан республикасы Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе,
e-mail: zagik63@mail.ru

# ХАЛЫК ИҖАТЫ

УДК 398.2

## ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫНДА «КҮР УГЛЫ» ДАСТАНЫ

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

«Кур углы» знаменателен как произведение, удовлетворявшее потребности татарского народа в письменной эпической литературе. Статья посвящена исследованию некоторой специфики бытования в татарском народном творчестве данного эпического памятника. Автором проанализированы различные варианты дастана, прослежены отдельные мотивы знаменитого эпоса о Кур углы, выявлены особенности и определено значение татарской версии в целом. Автор отмечает бесценность дастана «Кур углы» в плане изучения этнической истории, тюрко-татарских культурно-литературных связей и как героическое произведение приключенческого характера.

**Ключевые слова:** дастан «Кур углы», вариант, версия, народ, традиция.

«Күр углы» – төрле халыкларның эпик фольклорында очрый торган, XVII–XVIII йөз тарихи вакыйгаларына нигезләнгән мәшһүр ядкарь. Бу исемдәге дастаннар Себер, Кавказ, Урта Азия һәм Казакъстанның, Якын Көнчыгыш һәм, хәтта, өлешчә Европаның төрки телле һәм башка халыкларында гаять популяр булган.

Кайбер халыкларда «Күр углы» шул кадәр киң таралыш алган ки, бу циклдагы сюжетларның күплеге, хәтта, башка сюжетларны халык иҗатыннан кысрыклап та чыгарган. Әйтик, В.М. Жирмунский төрекмән-угызларның соңгырак чор дастани иҗатында атаклы «Алпамыш», яисә «Коркыт» циклларының очрамавын шушы сәбәп белән, ягъни XVII–XVIII йөзләрдән биредә милли каһарман турындагы «Күр углы» эпосының гаять киң таралганлыгы белән аңлата [Жирмунский, 1974, с. 167].

Ашуг авызыннан язып алынган кайбер төрки версияләрнең XVIII йөз уртасында ук инде басылып та чыккан булуы турында мәгълүматлар бар. «Күр углы» дастанына безнең халык та битараф калмаган. Татарларга ул чагыштырмача соң – башка халыкларның язуга теркәлгән текстлары аша XIX йөз уртасында килеп кергән. Татар халкындагы «Күр углы» – сөйләмә вариантлары булмаган, язма нөсхәләрдә генә сакланган, фәкать күчерелеп һәм укылып йөргән дастаннардан. «Күр углы»нда телгә алынган тарихи шәхесләрнең, реаль вакыйгаларның татарларга турыдан-туры бернинди катнашы юк. Халкыбыз аны иң беренче чиратта традицион китап культурасына омтылышы һәм әсәрнең мавыктыргыч сюжеты ар-

касында үз иткән, этноним, топоним, антропонимнарны үз фонетик үзенчәлекләренә яраштырып, әсәргә төрле үзгәртүләр керткән, кыскартулар ясаган. Нәтиҗәдә, популяр дастанның безнең халыкка хас китаби үз версиясе хасил булган.

Татарларда «Күр углы» дастаны, аерым алганда аның В.В. Радлов тарафыннан язып алынган варианты [Радлов, 1872, с. 258–261] турында төрекмән галиме Б.А. Каррыев [Каррыев, 1968, с. 250–254], үзебезнең галимнәребездән Ф.И. Урманчеев [Урманчеев, 1984, с. 164–170], М.И. Әхмәтҗанов [Әхмәтҗанов, 2000, б. 186–187], И.Г. Закирова [Закирова, 2010, с. 371–372] һәм Л.Х. Мөхәммәтҗанованың [Мөхәммәтҗанова, 2010, б. 378–379; Мухаметзянова, 2012, с. 40–43] фәнни хезмәтләре мәгълүм. М. Әхмәтҗанов исә В. Радлов вариантыннан тыш «Күр углы»ның татарлардагы башка кулъязма һәм басма вариантларына да әһәмият бирә. Әлеге хезмәтләрдә «Күр углы»ның татар дастаннары арасында һәм шул исемдәге башка халык эпосы янәшәсендә тоткан урыны турында кайбер фикерләр әйтелә. Әмма татар халкының «Күр углы» дастанына татар фольклористикасында тиешле игътибар бирелгән дип әйтеп булмый әле. Татар китаби дастаны буларак та, этник тарихыбызны, төрки-татарларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрен барлау һәм, гомумән, татар версиясенең башка халыклар эпосы яссылыгында үз әһәмиятен ассызыклау җәһәтеннән дә ул махсус фәнни өйрәнүгә лаек.

Себер татарларыннан В. Радлов язып алган кыска гына «Күр углы» дастаны татар халкында, бай язма әдәби традицияләр белән беррәттән ерак гасырлардан килә торган эпик традицияләрнең дә яшәп килгән булуын искәртә.

«Күр углы» дастанын В. Радлов XIX йөз ахырында Төмән өлкәсендә яшәүче себер татарларыннан язып алган. Дастан прозаик характерда, фәкать берничә урында диалог яисә баш каһарман әйткән сүзләр генә ике-дүрт юллы тезмәләрдә җиткерелә. Мәсәлән:

Күрнең углы әйтте:
– Килсен ханларым, солтанларым!
Башлары миңа караган кеше килсен!
Боерылган әмерләрем инде алсын!

Яисә Күр углының Ага Цаус белән ат өстендә торып әйтешүеннән бер мисал:

Ага Цаус әйтте:
– Эстәрсәң дә инде малымны,
Син күрерсең минем көчемне.
Мине үлтерсәң, ал малымны,
Мин кайтмыймын, син кит иленә!

Дастанның шушы берничә шигъри юлдан калган өлеше кыска җөмләле тезмә юлларда бәян ителә. Текстның күләме чагыштырмача зур түгел – дүрт биттән артмый. Вакыйгалар корылышы да артык катлаулы дип әйтеп булмый, ул төп каһарман гамәлләренә нигезләнгән бер генә сюжет сызыгыннан гыйбарәт.

Күр батыр исемле вәзир Истанбул патшасына көтүдәге бер биянең озакламый толпар колынлаячагын хәбәр итә. Колын тугач, күк биянең әлеге кара колынчагын патша хуп күрми, аның толпар булачагына ышанмый, шуңа Күр батырны сукырайтып җәзалый. Ә колынчак,

бераз үсә төшкәч, чыннан да толпарга әйләнә. Шуннан кызу канлы Күр батыр, улына кара айгырны җитәкләтеп, алдан әйткән сүзләренең хак булуын расларга дип, патша янына бара, аны каргый:

– Күрдеңме? Син минем күземне чыгардың, синең дә күзеңне чыгарсыннар! – ди. Патшаның ачуы чыга. Күр һәм аның улы качалар.

«Күр» исеменең килеп чыгышын Б.А. Каррыев ике төрле аңлата: «гүр» сүзе (таҗик, үзбәк версияләрендә төп каһарман, чыннан да, анасыннан кабердә, ягъни гүрдә туа) һәм кайбер төрки телләрдә күр сүзенең «сукыр» мәгънәсен аңлатуы белән бәйли [Каррыев, 1968, с. 227]. В. Радлов вариантына икенче аңлатма, ягъни, патша тарафыннан сукырайтылган сукырның улы буларак, каһарманны Күр углы исеме белән атаулары күбрәк туры килә, ә кабердә туу мотивы исә биредә урын алмаган. Алай да үзенең төрки телләрдәге төп мәгънәсе белән «күр / гүр / кер» сүзе каберне аңлата, төп каһарманның исеме дә шуңа бәйле булу ихтималы зуррак. Шул ук вакытта бу исемнең тарихи тамырлары булу мөмкинлеген дә истән чыгарырга ярамый.

Күр батырның углы атасын патша эзәрлекләвеннән коткарып кала, үзе Шәмливил дигән шәһәрдә «егетләр башы булып, узган-барганны коткармый, кәрванны талап тора», ягъни байлар-солтаннарны талау һәм үтерү белән шөгыльләнә. Башка милли версияләрдә вакыйгалар озын-озак итеп тәфсилләп сөйләнсә, В. Радлов вариантында шул ук вакыйга турында мәгълүмат кыска гына бер-ике җөмләдә җиткерелгән. Бу – соңгырак чор эпик стиль чагылышы, себер татарлары вариантының әүвәлге милли версияләрдән чагыштырмача соңрак формалашкан булуы галәмәте.

Алга таба Күр углының бер төркем батырлар башлыгы Ага Цауз (башка халыклар, шул исәптән казан татарлары вариантындагы тәрдәше – Ага Чауз) белән сугышуы һәм аны җиңүе, малын тартып алып, үзен әсир итүе тасвирлана.

Бер көнне боларга бер карт килә. Күр углы төркеме бу картның булган акчаларын талап ала. Карттан: «Бу дөньяда улың юк, кызың юк килеш үләрсең», – дигән сүзләр ишеткәч, Күр углы аннан үзенә яраклы кыз турында сораша. Карт аңа Истанбулдагы Никар ханым дигән кыз турында әйтә. Әлеге карт образы гади генә карт булмыйча, башка милли версияләрдәге, әйтик, таҗик дастанында тәфсилләп сөйләнгән Хозыр образының бераз үзгәртеп китерелгән варианты булса кирәк. Бу хакта татар дастанында бер сүз дә әйтелмәсә дә, картның Күр углы янына үзе килеп кергән булуы, рәнҗетелгәч, Күр углының язмышын юрап әйткән сүзе, аңа яраклы кыз турында мәгълүмат җиткерүе карт образын изге Хозыр белән тәңгәлләштерү мөмкинлеген тудыра. Хозыр – татар дастаннарында еш телгә алына торган персонаж.

Шуннан Күр углы Истанбул каласына дип чыгып китә. Дастан каһарманының, кәләш эзләп, үз иленнән читкә чыгып китүе – төрки халыклар эпосында киң таралган мотив. Бу мотив махсус «героик ярәшү мотивы» дигән исем белән билгеле. Гадәттә Себер һәм Урта

Азия төркиләре кәләшне башка кабиләдән ала торган булганнар. Казакъларда, мәсәлән, җиде буынга кадәр кан кардәшлеге булмаган очракта гына никахлашу рөхсәт ителгән [Ауэзов, 1939, с. 215]. Кәләшне читтән эзләү мотивының экзогамиягә бәйле булуы турында, Себернең төрки-монгол халыклары иҗатына мөнәсәбәттә, Е.М. Мелетинский җентекләп язган иде [Мелетинский, 1963, с. 259–260]. Алтай әкияте «Кан-Пудей»да [Радлов, 1886, с. 68 – 86] «алтын күкрәкле, көмеш аркалы» каһарман күк кызын бик ерактан, «җир белән күк тоташкан урыннан» алып кайталар. Төрки һәм монгол халыклары өчен уртак әлеге сюжетның ерак кайтавазы Чура батырга багышланган дастаннарда да чагылыш тапкан [Ибраһимова, 2002, б. 40]. Себер татарлары «Күр углы» вариантындагы каһарманның Никарны эзләп чыгып китүе дә әлеге традицион ярәшү-никахлашу мотивына килеп тоташа. Биредә ул үзгәргән, бу мотивка киң тукталу юк, сүз, нигездә, Күр углының атасын һәм үзен рәнҗеткән социаль гаделсезлеккә каршы көрәш турында бара.

Юлда әсир төшкән Күр углын зинданга ябалар, Никар ханым аны коткара. Патриархаль күчмә тормыш шартларында барлыкка килгән төрки халыклар эпосына каһарман хатынын яисә аның кәләшен, бик теләп, аның тигез хокуклы, акыллы ярдәмчесе итеп тасвирлау хас. Моңа мисалны без «Алпамыш»та (Барчин), «Кобланды батыр»да (Кортка), «Манас»та (Каныкей), «Чура батыр»да (Миңле Сылу яисә Гөлханыс, Акменде) һ.б. эпосларда очратабыз. «Күр углы»нда да борынгыдан килә торган шушы эпик традиция чагылыш тапкан. Зинданда думбра чиртеп утыручы Күр углын Никар ханым күреп ала, аның ярдәмендә төп герой юлын дәвам итә. Күр углы Бул бәк ханның сараена кереп, аннан бер кызны, кара атны урлап кача. Бул бәк үзенең гаскәре белән боларны куа чыга. Алар, ук атышып, Күр углы белән бик каты сугышалар. Күр углына ярдәмгә аның егетләре килеп җитә. Бул бәкнең гаскәрен җиңеп, үзен Шәмливилгә әсир итеп алып кайтып китәләр. Күр углы Бул бәкне бик нык җәзалап үтертә.

Күр углы Бул бәкнең эченә салам тутырылган гәүдәсен Истанбул патшасының капкасы төбенә китереп куя. Бу эшкә бик ярсыган патша даны илгә таралган Күр батырның кара атын тотып китергән кешегә үзенең кызын вәгъдә итә. Хәйлә юлы белән бу эшне Хәзәл исемле егет башкарып чыга.

Истанбул патшасы тарафыннан Күр углын һәм аның кара атын алып кайтырга дип җибәрелгән Хәзәл, Шәмливилгә килеп, Күр углына хезмәткә керә, аның ышанычын яулый. Дастанда Хәзәлнең еллар буе Күр углының малчысы булып торуы әйтелә, соңыннан ул Күр углының кара атын урлап, Истанбул патшасына качып китә.

Күр углы аны куа чыга, тиз арада хыянәтчене куып та җитә. Юлда тегермән ишегенә бәйләнгән кара атын күреп, атыннан төшкән Күр углын Хәзәл хәйлә юлы белән төп башына утырта: Күр углы тегермәннең бер ишегеннән кереп киткәч, үзе икенче ишектән чыгып, кара

атны ияртеп, Күр углы атланып килгән туры атка менеп, кача. Хәзәл белә: атын калдырса, Күр углыннан мәрхәмәт булмаячак, ә качып котылса, Истанбул патшасы аңа кызын бирергә әзер. Әлеге тактик алым Хәзәл өчен уңай, әмма ул Күр углы белән дә арасын бозмый, киресенчә, аны туйга чакыра, шунда кара атны кире кайтарырга вәгъдә бирә. Соңыннан, сүзендә торып, вәгъдәсен үти.

Хәзәл традицион героик эпос өчен типик образ түгел. Хәзәл белән Күр углы арасындагы конфликтның ике батыр арасындагы көрәш-алыш формасында түгел, ә хәйлә-мәкер катнашында чишелүе – соңгырак чор эпик традиция чагылышы. Батырлар арасындагы сугыш-орыш картинасына акыл-мәкер көрәше килеп керү белән башка китаби дастаннарда, әйтик «Каһарман Катил» героик дастанында да очрашабыз. Хәзәл кылган гамәлләр иле өчен, идея өчен түгел, ә үз амбициясеннән чыгып – патша кызына өйләнү, үзен күрсәтү өчен башкарыла. Әмма әлеге эпизод дастанда төп каһарманның дәрәҗәсен һич төшерми, киресенчә, күтәрә. Моны шул ук Хәзәлнең Истанбул патшасы ягында калмыйча, туйдан соң ук патша кызын, ягъни үзенең хатынын алып, Күр углы артыннан Шәмливилгә качып китүе үк раслый.

Дастан каһарманы Күр углы – курку белмәс батыр, җитез җайдак, үтә катлаулы хәлләрдән дә шома чыга белүче, нинди генә көчле дошманны да җиңә алучы елгыр егет, оста оештыручы-җитәкче. Әмма шул ук вакытта бу егет – кеше үтерүче, талаучы куркыныч башкисәр, аны, атын тотып китерә алган кешегә кызын бирергә риза булып, Истанбул патшасы үзе эзләтә. Шуңа күрә бу яктан җинаятьчене аклап булмый кебек. Әмма героик дастан батырының үз-үзен тотышы бүгенге этика кагыйдәләренә һәрвакыт туры килеп бетмәве – эпос өчен табигый хәл. Күр углы холкына, һәрбер дастан каһарманына хас булганча, намуслылык, вөҗданлылык та ят түгел. Әйтик, Никар ханым зинданнан коткаргач, Күр углының качып китү йә яшеренеп яту мөмкинлеге була, ә ул бу юлдан китми:

– Егетлек алай булмас, – ди, һәм, кире шәһәргә кайтып, дошманыннан каты итеп үч ала. «Егетлек алай булмас!» дигән гыйбарә текстта берничә урында кабатлана. Бу – каһарманның курку белмәс батыр булуын тасвирлау алымы. Әлеге алым әсәрнең героик дастаннар рухына тәңгәллеген искәртә. Тагын шунысы бар: Күр углының дошманнары – һәрвакыт социаль дошманнар, алар – бай кәрванчылар, ханнар һәм патша. Әлеге факт вакыйгаларның тамырына – Күр углының җинаятьче-батыр булып әверелү сәбәпләренә алып кайта. Чыннан да, каһарманның атасы Күрне хаксызга рәнҗеттеләр, шуның нәтиҗәсендә карт күзсез калды, иленнән качарга мәҗбүр булды. Рәнҗетүче – үзенең хакимиятеннән явыз файдаланучы Истанбул патшасы. Дошманлыкның, явызлыкның сәбәбе әнә шул. Күр углы кылган гамәлләр үч кайтару мотивы белән башкарыла, шуңа да мантыйкый рәвештә аклана.

Биредә Күр углының үз егетләре-көрәштәшләре арасында зур

абруйга ия булуын да истә тотарга кирәк. Һәрвакыт, һәр җирдә бу егетләр җитәкчеләренә ярдәмгә килергә әзер һәм бу бирелгәнлек, көч кулланып түгел, фәкать Күр углының кодрәтен, чын батыр булуын тану бәрабәренә башкарыла.

Әле батыр туганчы ук ат белән аның арасында якын мөнәсәбәтләр урнашу – күп кенә төрки дастаннар өчен уртак күренеш. «Күр углы»-ның азәрбайҗан версиясендә Хәсән бәк атасы-баһадирның Гырат («кыр аты») кушаматлы тулпарыннан туасы җирән колын белән дуслаша. Кыргызларның «Манас»ында да шуңа охшаш эпизод бар. «Чура батыр»ның казакъ версиясендә исә Гөлханыс, каршыларына чабып килгән тулпарны күреп, «Туачак баламның аты булыр бу», – ди, һәм аның юравы чынга аша. Себер татарлары «Күр углы»нда да каһарман янында, аңа тугры кырык көрәштәш егет белән бергә, әлбәттә, төрки эпосның аерылгысыз атрибуты – каһарман үзе генә иярли ала торган тулпар аты тасвирланган.

Эпик герой – һәрвакыт горур, гаделсезлеккә түзеп тора алмый, кызу канлы һәм үз көченә нык ышанучан. Күр углына да әлеге сыйфатлар хас. Әсәрдә ул гаделлек өчен көрәшүче курку белмәс батыр образын гәүдәләндерә.

Дастанның тел-стиль һәм шигъри үзенчәлекләренә килсәк, бу әсәрне сөйләмә вариантка якын тора дип билгеләү дөрес булыр. Халык сөйләменә хас артык озын булмаган гади яисә тезмә кушма җөмләләр, чәчмә стиль дастанны сөйләмә характердагы иҗатка якынайта. Себер (тобол) татарлары варианты халык стиленә хас билгеләргә ия килеш теркәлеп калган. Әмма тобол вариантының стилистик үзгәреш кичереп, китап культурасына якынайганлыгын яисә соңгы чор эпик стилендә оешканлыгын күрми узу да дөрес булмас иде. Чынлыкта, әсәрне «автор»ның әдәби үзгәртүләренә бөтенләй дучар түгел, дип әйтеп булмый. Дастанга килеп кергән «яңалыклар» нигездә кайбер образ-персонажларның соңгырак чорда әдәби-китаби характерлар һәм сюжетлар йогынтысында формалашкан булуыннан гыйбарәт. Шул ук вакытта китабилашу процессында әсәргә килеп кергән билгеләрнең саф традицион эпос геройлары, аларның холык-фигыле, эш-гамәлләре белән гармонияле керешүе күзәтелә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкының себер татарларындагы «Күр углы» варианты – тубыл татарларының иҗади эшкәртүенә дучар булган, бай эпик җирлеккә ия дастан. Ул Урта Азия чичәннәре белән язма культура арасын үзенчәлекле тоташтыру функциясен үти. Дастан синкретик характерда, ягъни үзендә индивидуаль башлангычны да, фольклор традицияләрен дә үзенчәлекле берләштергән. Бу вариант төрки героик эпосы рухын, башка вариантларына караганда, ныграк саклаган булуы белән кыйммәт.

Авантюралы сюжетының социаль-көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы булуы, күрәсең, дастанның халыкта киң һәм төрле формада таралуына сәбәп булган. Дастанның Татарстанда табылган кулъязма варианты бар. Аның хакында М. Әх-

мәтҗанов хәбәр итә [Әхмәтҗанов, 2000, б. 187]. Ул кулъязма бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Кулъязма һәм музыкаль мирас үзәгендә (39 колл. сак. бер. № 5013) тасвирланган хәлдә саклана.

Кулъязма фәкать ике генә битлек, гарәп язуында. Текст шәмәхә кара белән 1920 елларда эшләнгән кәгазьгә язылган. Әлеге дастан бары фрагменттан гыйбарәт, 26 тезмә юлны тәшкил итә. Дастан кулъязмасының 13 нче һәм 14 нче шушы ике битеннән кала башка өлеше сакланмаган. Өзектә Күр углы уллыкка алган Хәсән ханның гаскәрдәге егетләрне яуга өндәгән чыгышы китерелә. Менә, мәсәлән, әлеге тексттан берничә юл:

Фәрәмуш булмасын (*онытылмасын*) имди хәтерләр.
Корыңызлар сарә (*сөенеч, шатлык уңаеннан*) пәрдә чатырлар.
Ак керүгә савыт кигән (*ак түгәрәк көбә күлмәк, кольчуга*) батырлар,
Йә алыңлар, йә үлеңләр егетләр.
Йулымызда үзе Күр углы солтан,
Гаваз ханны килтерер дип кырык арслан.
Ук үтмәгәй, кирек тиресе бу калкан (*киергегә тарттырылган калкан*),
Йә үлеңләр, йә алыңлар егетләр.

Фрагмент кына булуга карамастан, кулъязманы китаби «Күр углы»ның бер варианты дип бәяләргә мөмкин. Бу шигъри өзекнең табылуы «Күр углы»ның татарларда кулъязмада укылганлыгын, димәк, популярлыгын раслый. Әлеге вариант себер татарларыннан язып алынган дастан сюжетыннан ерагая төшкән. Кайбер антропонимик һәм топонимик уртаклыклар, мәгълүм Күр углы турында каһарман характерындагы дастан булуы һәм бердәй мотивлар (әйтик, Күр углының баласы булмау) гына аларны бер үзәккә тупларга мөмкинлек бирә.

Аның каравы әлеге фрагмент кулъязма дастанның басма варианты белән аваздаш. Әйтик, дастанның 1894 елгы басмасында югарыда китерелгән өзек юлга-юл кабатланган [Хикәяте..., 1894, б. 13–15].

Мәгълүм булганча, XIX йөз – XX йөз башында Казан типографияләрендә «Хикәяте Күр углы солтан» әсәре кат-кат басыла. Әйтик, бу дастанның 1889 дан алып 1916 елгача 11 тапкыр басылып чыгуы мәгълүм. Югарыда каралган кулъязма фрагменттагы юллар, кайбер лексик, морфологик һәм орфографик үзгәрешләр кичереп, нәкъ менә шушы басма хикәяттә очрый.

«Хикәяте Күр углы солтан»ның теле гарәп-фарсы алынмалары белән чуарланган һәм бүгенге көн укучысына шактый кыен аңлашыла. Күләме зур – 90 битне тәшкил итә, гарәп язуында.

Әсәрдә ханнар тарихы риваять ителә, хронологик тәртиптә берничә ханның исеме атала, шуннан соң. Күр углының унбиш яшендә хаким булуы бәян ителә. Кайбер милли (әйтик, төрекмән) версияләрдәгечә, Күр углының, бала чагыннан алып, егет булганга кадәрге тормышын, геройның могҗиза юлы белән туган атын җентекле тасвирлау-бәян итү кебек элементлар татар дастанында юк. Татар китаби дастаны Күр углы тормышындагы вакыйгаларның кайберләренә генә тукталган. Әмма, әлеге вакыйгалар башка милли версияләрдәге

эзлеклелеккә һәрвакыт туры килеп торалар, дигән нәтиҗә ясап булмый, бер үк исемнәр, охшаш вакыйгалар төрле уңай белән сюжетның төрле урынында очраргa мөмкин. Төрекмән, таҗик, азәрбайҗан һ.б. версияләр бер-берсеннән аерылып торган кебек, татар дастаны да яңа җирлектә яңача корылган, әлеге иҗат процессында күп үзгәрешләргә дучар булган.

Күр углы утыз яшькә җиткәндә моның янына Хозыр галәйһиссәлам, кырык изге җан, унике имам киләләр һәм аңа изге дога багышлыйлар. Кырык яшендә болар Күр углына кабат килеп, «бездән ниләр теләр идең?» – дип сорыйлар. Күр углы дан-шөһрәткә ия булып озак яшәүне сорый, ә үзенең варисы итеп калдырырлык бала сорарга башына килми.

Дастанда аның күп хатыннар алып та, берсенең дә моннан бала тапмаулары турында сөйләнә. Варис кирәклеген аңлап, Күр углы, йөз яшенә җиткәндә, Исфаһан шәһәреннән Хәсән ханны алып кайтып, аны үзенең улы дип игълан итә, батыр егетләренә шул Хәсәнне башлык итеп куя.

Алга таба дастан Хәсән хан җитәкчелегендәге кырык егетнең Хункар иленә баруы турында сөйли. Биредә «Булдырык исемле итченең Гаваз исемле бик чибәр улы» яши икән, Күр углының аны күрәсе, үзенең варисы итәсе килә. Шуңа күрә ул: «Хәсәнне тыңлап, буйсынып торыгыз», – дип, Гавазны алып кайтырга Хункар иленә яу җибәрә.

Татар версиясендәге Гаваз төрле милли версияләрдә телгә алынган Айваз (Овез, Иваз, Аваз) исемле бик чибәр үсмер егет образы белән тәңгәл килә. Дастанның көнбатыш һәм көнчыгыш версияләренең һәркайсында, талау-буйсындыру сугышларының берсендә Күр углының Айваз исемле бик чибәр яшь ир баланы урлап китү эпизоды бар. Әлеге үсмер егет башта Күр углы хезмәтендә – аның шәраб коючысы булып тора, соңыннан үч алучы башкисәрнең көрәштәше-фикердәшенә әверелә. Дастан версияләрендә тасвирланган әлеге эпизодның чынбарлык вакыйгаларына барып тоташуы һәм тарихи документларга нигезләнеп раслануы әһәмиятле. Җәләлидләр түнтәрелеше турында Төркиядәге архив документларын барлаганда Х. Короглы бу турыда гаять кызыклы тарихи мәгълүматларга юлыга. Галим реаль вакыйганың дастанга килеп кергән булу ихтималы хакында хәбәр итә [Короглы, 1973, с. 143]. Әмма татар версиясенә бу вакыйга турыдан-туры кагылмый, бирегә ул фольклорлашу процессында туган башка милли версияләр аша килеп кергән.

Кырык егете белән Хәсән хан Хункар дәүләтенә килеп җитеп, Бәдбәхет тавында туктала. Бу тау Гөрҗестан җирендә була. Таудан түбән карап, каланың зурлыгын, капкаларының күплеген күреп, каушап калган егетләргә Хәсән бәк кулъязма вариантта да теркәлгән, 26 юлдан торган шигъри тезмәдә бәян ителгән сүзләрне әйтә. Ул юлларның эчтәлеге егетләрне орышка үгетләүдән, Күр углы солтанның ышанычын акларга өндәүдән гыйбарәт.

Татарча «Күр углы солтан» – төрки героик эпосы рухын тулысынча

саклый торган әсәр. Әйтик, баһадирга даими рәвештә изге картларның ярдәмгә килүе – төрки халыкларның дастаннарында еш очрый торган күренеш. Мәсәлән, «Алпамыш» дастанында батырга Хозыр үзе булыша [Диваев, 1901, с. 77]. «Гашыйк Гариб»нең азәрбайҗан версиясендә каһарман шул ук Хозыр Ильяс ярдәме белән кирәкле вакытта тиешле җиренә барып өлгерә [Антология, 1939, с. 214–217] һ.б.

«Күр углы солтан»да бу мотив төрки дастаннар өчен гаять популяр икенче бер әһәмиятле күренешкә – баласызлык мотивына барып бәйләнә. Баласызлык мотивы казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак кебек төрки халыклар эпосы өчен бик популяр. Мәсәлән, казакъ халык героик эпосы «Кобланды батыр»да Токтарбай сиксән яшенә җитә, әмма баласы булмый [Антология, с. 228]. Кыргыз эпопеясы «Манас»та улы булмаган Якуп кайгысыннан кан-яшь түгә [Кыдырбаева, 1988]. Киң таралган бу мотив Чура батырга багышланган казакъ дастаннарында да күзәтелә [Ибраһимова, 2002, б. 119].

«Күр углы солтан»да баласызлык мотивы дастанның төп нигезе булып әверелгән дисәк тә хата булмас, чөнки нәкъ менә шушы проблема Күр углын башта Хәсән хан, аннары Гаваз хан өчен көрәшергә мәҗбүр итә һәм дастан сюжетын төзи.

Халкыбызның «Күр углы солтан» дастаны төрки-иран мәдәни һәм әдәби бәйләнешләре нәтиҗәсендә безгә килеп ирешкән китаби дастан буларак кыйммәт. Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Күр углы» исеме белән бәйле дастаннар безнең халыкта чичән авызыннан язып алынган ядкарь буларак, кулъязма текст буларак һәм басма китап формаларында очрый. Халыкның язма әдәбиятка ихтыяҗын канәгатьләндерә торган, борынгыдан килгән традицияләребезне язуга күчереп тарата торган әсәр буларак, «Күр углы» дастанының әһәмияте зур. Үзенең сюжет корылышы, образ-персонажлар бирелеше, вакыйгалар эзлеклелеге, күләме һ. б. ягыннан татар версиясе башка халык версияләрен кабатламый. Татар дастанының китаби төренә карый торган иҗат буларак та, этник тарихыбызны, төрки-татарларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрен барлау җәһәтеннән дә, маҗаралы героик әсәр буларак та «Күр углы» дастаны – гаять кызыклы, бай хәзинә.

## ӘДӘБИЯТ


Антология азербайджанской поэзии М.: Гослитиздат, 1939. 428 с.

Ауэзов М., Соболев Л. Эпос и фольклор казахского народа // Литературный критик. 1939. № 10/11. С. 201 – 217.

Әхмәтҗанов М.И. Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр, 2000. 270 б.

Диваев А.К. Памятники киргизского народного творчества. Алпамыс-батыр. Ташкент, 1901. 88 с.

Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. 727 с.

Закирова И. Г. «Күр углы» дастанының татар версиясе // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 371–372.

Ибраһимова Л.Х. Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 190 б.

Каррыев Б.А. Эпические сказания о Кер-оглы у тюркоязычных народов. М.: Гл. ред. восточ. лит-ры, 1968. 260 с.

Короглы Х.Г. Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 130–145.

Кыдырбаева Р. Р. Манас эпосунун варианттары. Фрунзе: Илим, 1988. 160 с.

Мелетинский Е. М. Происхождение героического эпоса. М.: Изд-во восточ. лит-ры, 1963. 463 с.

Мөхәммәтҗанова Л.Х. Татар халкының китаби дастаннарыннан «Күр углы» // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 378–379.

Мухаметзянова Л.Х. «Кур углы»: модель книжного дастана в творчестве татарского народа» // Вестник ЧелГУ. Филология и искусствоведение. Выпуск 72. № 36 (290) 2012. С. 40–43.

Радлов В.В. Образцы народной литературы северных тюркских племен. Ч. I. СПб., 1886. 418 с.

Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. IV. Наречия барабинцев, тюркских, тобольских и тюменских татар. 528 с.

Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. книж. изд-во, 1984. 310 с.

Хикәяте Күр углы солтан. Казань: Типо-литография Имп-го ун-та, 1894. 90 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
халык иҗаты бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре
e-mail: lilmuhat@mail.ru

УДК 398.3

# КЫТАЙДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАРДА ТУЙ ЙОЛАСЫ

*Л.Х. Дәүләтшина, Л.И. Вәлиуллина*

Настоящая статья посвящена описанию свадебного обрядового цикла, присущего татарской диаспоре, проживающей в Синьцзян-Уйгурском автономном районе Китая. В работе авторы останавливаются на предсвадебных (кыз ярәшү (сговор), өй киендерү (одевание дома), әрвахлардан хәер-фатыйха сорау (просьба благословения у арвахов), чәй эчкезү (чаепитие), сандык туе (свадьба сундука), никах и др.), свадебных (авызландыру (букв. «делать рот»), зур туй (большая свадьба), бирнә сандыгы илтү (доставка приданого в дом жениха) и др.) и послесвадебных (кодалар чәе (чай для сватов)) обычаях и обрядах татар.

**Ключевые слова:** обряд, обычай, семейно-бытовой обрядовый цикл, свадьба, текст.

Татарлар – шактый киң таралган халыкларның берсе. Россиядән тыш, чит мәмләкәтләрдә дә аларның дистәдән артык эреле-ваклы төркемнәре – диаспоралары бар. Диаспора дип, бер милләт вәкилләренең тарихи үз ватаннарыннан чит җирләргә күченеп китеп, башка тел-мәдәниятләргә ия халыклар арасында үзләренең этник сыйфатларын – телләрен, гореф-гадәт һәм милли аңнарын саклап яши торган төркемнәренә карата әйтелә. Дөньяда киң таралган бу күренеш безнең халыкны да читләтеп узмаган.

Катлаулы, чуар һәм үзенчәлекле язмышка ия диаспораларыбызның берсе хәзерге көнбатыш Кытайның Шенҗан дигән регионында, ягъни борынгы Уйгырстан – Шәркый Төркестан җирләрендә (соңрак, коммунистлар чорында, «Шенҗан-Уйгыр автоном районы» дип үзгәртелгән төбәктә) оешкан [Йосыпова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н., б. 269].

Кытайның Шенҗанда яшәүче татар диаспорасы татарларның көнчыгыш эмиграциясе үзәге булып санала. Кытай һәм татар чыганаклары дәлилләвенә караганда, Шенҗанда Идел–Урал төбәгеннән килгән татар сәүдәгәрләре һәм коммерсантлары XIX гасыр уртасында күренә башлый. Инде XIX гасыр ахырына Шенҗанның барлык эре шәһәрләрендә татарларның сәүдә итү урыннары була. Алар, сәүдә итүдән тыш, тире эшкәртү һәм тире иләп, мех эшләү белән шөгыльләнгәннәр. Октябрь революциясеннән соң Кытайга интеллигент һәм бай сәүдәгәр гаиләләре күченә башлый. XX гасырның 40 нчы елларында алар репрессияләргә дучар булалар, шуңа күрә татарларның күпләп авыл

җирлегенә күченүе күзәтелә. Авыл җирендә яшәүче кытай татарлары, нигездә, терлекчелек белән шөгыльләнәләр, ә интеллегенция вәкилләре һәм белем бирүчеләрнең төп өлеше шәһәр һәм бистәләрдә яши [Национальные меньшинства..., 2008, с. 32].

2000 елгы рәсми статистик мәгълүматлар нигезендә хәзерге вакытта Кытайның Шенҗан-Уйгыр автоном районында 4873 татар яши. Татар милли оешмалары исә 5,5 меңнән артык татар булуын билгеләп үтә. Кытайның төп татар үзәкләре булып Голҗа, Үремче, Чүгәчәк шәһәрләре исәпләнә.

Татар телендә сөйләшүче диаспораның традицион мәдәниятен төрле яклап өйрәнү һәм тикшеренүләрне фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү, чит төбәкләрдә яшәүче татар халкының тормыш-көнкүреше турында тулаем күзаллау тудыру өчен, төп чыганак булып тора. Көнчыгышта яшәүче татар диаспорасы фольклорын Шенҗан-Уйгыр автоном районындагы милләттәшләребез арасында таралыш тапкан туй йоласы комплексы мисалында күзәтү бу юнәлештә чираттагы гамәл булып санала.

Кытай татарларының гаилә-көнкүреш йола комплексына кергән туй йоласына күзәтү ясаганда, аларның формалашуында роль уйнаган этнографик төркемнәрнең һәм күрше халыкларның фольклорына да игътибар итәргә кирәк. Диаспораның формалашуында Идел буе һәм Урал төбәгеннән килгән татарларның урыны зур. Ул гына да түгел Кытайда төпләнеп яши башлаган татар халкы, әлбәттә, ут күршеләре – уйгырлар белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәгән һәм татар мәдәниятендә уйгыр тәэсире дә үзен сиздерә.

Кытай татарларында да туй йоласы, фәнни әдәбиятта кабул ителгәнчә, өч этапка бүленә: туй алды, туй һәм туй арты йолалары [Бакиров, 2008, с. 167]. Туй алды гадәтләренең берсе – *кыз ярәшү*. Кыз йортына мәхәлләнең акыллы, белемле, арадашчы булырлык ир-атлары – аксакаллар бара. Аларны илчеләр дип атыйлар. Элек алар ике гаиләне бер-берсе белән таныштырганнар, килештергәннәр, ә хәзер никах өчен төп шарт – яшьләрнең үзара килешүе.

«Кызны ярәшергә илчеләр бара. Илчеләр мәхәлләнең аксакаллары була. Кияү егетнең туганнары да булырга мөмкин. Танышларына барырга ярый. Күчтәнәч, бүләк алып барылмый. Чөнки кызны ярәшергә ирләр генә бару кабул ителгән. Ә ирләр Кытайда күчтәнәч, бүләк алып бармыйлар. Кергән вакытта «Әссәләмәгаләйкүм» дип исәнләшәләр генә. Кыз сорарга матур итеп киенеп баралар. Түргә утыралар. Табын артына узалар. Үз-үзләре белән таныштыргач, нинди йомыш белән килгәнлекләрен әйтәләр» (З. Чапаевадан (1942 елда туган), Голҗа шәһәрендә язып алынды. 2012 ел).

Кемдер, йолага туры килсен дип кенә, беренче килүдә үк ризалашмый, яучыларны ике-өч рәт йөртә, ә икенчеләр шунда ук туй турында сөйләшүгә күчә – егет ягына бирергә дип, әзерләгән исемлеген тапшыра. Ике як та уртак килешүгә килә алса, ата-аналар катнашында салым хакы турында *исемлек төзелә*. Бу исемлеккә кунаклар саны (500 дән артык кеше), туй табыны-

на кирәк булачак әйберләр (дөге, ит һ.б.), мәһәр күләме (утыз грамм тирәсе алтын, кызга бер кат язлык-көзлек, кышлык-җәйлек өс-баш киемнәре, бизәнү әйберләре яисә акча) языла. Салымның яртысы кыз ярәшкән чакта ук бирелергә мөмкин, аңа кәләшкә кием-салым, бизәнү әйберләре алына. Бу вакытта һәр яктан туйга нинди кунаклар килү, «картлар» һәм «яшьләр» туйларын кайчан һәм кайда үткәрү турында сөйләшүләр алып барыла.

Кытай татарларында кыз ягы да кияү ягына салым сала. Гадәттә, килен беркайчан да каената-каенана йортына төшми – егет ягы туйга кадәр үк яшьләргә йорт яки фатир алып бирергә тиеш. Кияү белән кәләш торасы фатирны җиһазландыру килен ягы өстендә. Әгәр дә кияү белән кәләш ата-ана йортында торасы булса, килен бер бүлмәне «киендерә». Кияүне дә туйга баштанаяк кыз ягы киендерә, хәтта балдакка кадәр алар ала. Шулай итеп, туй көнне, йә булмаса, туйдан соң башкарыла торган *«өй киендерү»* гадәте кытай татарларында туйга кадәр үк тормышка ашырыла.

«Кыз ягы өйне киендерә. Элек-электән бар. Дус кызлары булыша. Өй киендерү туйга кадәр була. Әгәр дә егет белән кыз яңа өйгә яшәргә чыксалар – кыз тулысынча киендерә. Әгәр дә әти-әни янәшәсендә яшиячәкләр икән – үз бүлмәләрен генә киендерергә тиеш була. Кагыйдә буенча, егет ягы өй ала – кыз ягы шул өйне киендерә. Яшьләр торачак өй була» (З. Чапаевадан язып алынды).

Ике як та үзара килешкәннән соң, туйга кадәр башкарыла торган матур гадәтләрнең тагын берничәсен карап китик. Беренчесе – әрвахлардан хәер-фатыйха алыр өчен зиратка бару, Корьән сүрәләре уку (*әрвахлардан хәер-фатыйха сорау*). Бу вакытта егет, булачак гаиләсенә тыныч тормыш теләп, вафат туганнарыннан ризалык сорый.

Икенче гадәт – «*чәй эчкезү»* яисә *вәгъдәләшү чәе.* Кыз ягы туйга ризалык биргәннән соң, егет ягы кызның өенә «чәй» алып бара. Бу көнне егет ягы кыз ягына бүләкләр алып килә, шул ук вакытта кәләшкә егетнең әти-әнисе махсус йөзек бүләк итә һәм аны кызның исемсез бармагына киертәләр [Жэмуцзыя, 2012]. Икенче мәгълүматларга караганда, «егет ягы туйга кадәр яисә туйдан соң мәхәлләгә чәй уздыра. Ул чәй дә туй шикелле була» (З. Чапаевадан язып алынды).

Туйга кадәр гамәлдә йөргән гадәтләрнең берсе – *«сандык туе».* Бу көнне егетнең әти-әнисе кыз ягына «туй сандыгы» җибәрә. Сандыкка кызның туена дип бүләк ителгән киемнәрне, кызның әти-әнисенә дип алынган бүләкләрне урнаштыралар. Аннан тыш, кызның әнисенә дип, *«сөт хакы»* өчен акча салына. Сандыкны егетның туганнары, дусишләре, аның өстенә кечкенә балаларны утыртып, җыр-бию, кызыклы уеннар белән кыз өенә алып баралар. Кызның әти-әнисе килгән кунакларны көтеп ала.

Туйга кадәр авылларда ат белән урам әйләнеп, «фәлән көнне фәләннәрнең туе була», дип кычкырып узалар. Шул ук вакытта традицион рәвештә кулланыла торган чакыру кәгазьләре тарату гадәте дә гамәлдә йөри.

Туйга бер көн кала *«мал тапшыру»* була: егет ягыннан 30–40 кеше килеп, исемлек буенча ни соралган булса, шуны тапшыра. Каршы як барысын да тикшереп, санап ала. Шул көнне кияүнең дуслары – унлап егет кыз ягына күченә: мал чалалар, казан асалар, үзләре белән алып килгән утынны ярып, күмер әзерлиләр, туйның төп ризыгы пылауга кишер чистарталар. «Кишерне дә дус егетләр чистарта. Бер килограмм дөгегә бер килограмм кишер салабыз, шуннан күпме кирәклеген чамалыйсыз инде» (З. Чапаевадан язып алынды).

Пылау пешерер өчен илле-йөз килограмм дөге, шуңа кирәк кадәр май, ит – боларны барысын да кияү ягы әзерләп килә. Кияү ягы күп вакытта туйга сыер, сарык суя. «Туйга бер көн калгач, мал тапшыру була. Анда егет (дуслары, туганнары) кыз ягына килеп туйга кирәкле булган әйберләрне тапшырып китәләр. Мал суела шунда. Пылауга кишер чистартыла. Туйда пешерелә торган пылауга. Табынга кирәкле, ашлар пешерә торган әйберләрне тапшыралар. Баллы ризыклар, дөге, май, суган һ.б.» (З. Чапаевадан язып алынды).

Туйга кадәр шаһитләр билгеләнә. Шаһитләр итеп өйләнмәгән егетләрне һәм кияүгә чыкмаган кызларны билгелиләр. Информантлар әйтүенчә, шаһитләр элек тә булган. Егет ягындагы шаһит туйга бер көн калгач, егетнең эти-әнисеннән сорап, кияү егетен алып чыгып китә. Бу вакытта кияү егете иптәшләре белән җыелып, «мальчишник» уздыра. Әлеге гадәтне кияүнең егет чагы белән саубуллашуы дип аңларга кирәктер.

Туйга кадәр башкарыла торган төп йолаларның берсе – *никах* ике якның да ата-аналары килешүе буенча кыз ягында үткәрелә. Никах – ике ят кешене бер-берсенә баглау дигән сүз, ике затның бер-берсенә тормыш юлында гомер буена бергә яшәргә Аллаһы Тәгалә каршында вәгъдә биргән көннәре. Шуның белән алар бер-берсенә тормыштагы бөтен шатлык-сөенечләрне, кайгы-хәсрәтләрне, балалар тудыру, аларны тәрбияләү һәм башка эшләрне дә уртаклашырга, бер-берсенә ярдәмче булырга вәгъдә бирәләр. Никах мәҗлесенә туганнар, дуслар, күрше-күлән җыела. Бу мәҗлес атнаның теләсә кайсы көнендә, гадәттә, төшкә кадәр сәгать уннарда үткәрелә.

Иң элек мулла вәгазь сөйли, егеттән, мөмкин булса, Корьән сүрәсен укыта. Никах укыганда, егет бер читтә тыңлап басып тора, ә кыз өйнең башка бер бүлмәсендә яисә челтәр артында әнисе һәм иптәш кызлары белән көтеп тора. Никах мәҗлесендә бары тик ирләр генә катнаша. Никах укылып, егет белән кыз үз ризалыкларын белдергәч, мәҗлес тәмамлана.

Никах мәҗлесе тыныч кына, изгелек һәм бәхет теләү сүзләре белән уздырыла. Никах мәҗлесенә исерткеч эчемлекләр куелмый, туй ашамлыклары белән бергә, йола ашы итеп, бал-май, баллы су – ширбәт куела. Ул *«никах суы»* дип атала. Никах суын, гадәттә, чишмәдән алалар һәм аңа шикәр салалар. Никах укылгач, мулла суны өшкереп, кызга да, кияүгә дә йоттыра.

Никахтан соң кыз егет ягына китә һәм туйга кадәр шунда яши.

Егет йортына төшкәч, яшь киленгә беренче мәртәбә бал-май каптыру – *«авызландыру»* йоласы башкарыла. «Бездә киленне мондагы кебек мендәргә түгел, ә ак җаймәгә бастыралар. Кияүнең эти-әнисе түгел, ә якын туганнарының берсе аларга «бал шикелле тәмле телле, май шикелле йомшак күңелле булыгыз» дип, бал белән май каптыра. Аннан бу бал-майны бөтен туганнарга да авыз иттереп чыгалар» (З. Чапаевадан язып алынды). Ягъни, татар халкының төрле этнографик төркемнәрендә таралыш алган кияү йортына төшкәндә бал-май каптыру гадәте кытай татарларында да кулланылышта йөри.

Кияү йортында яшьләргә ап-актан урын әзерләнә, аны егет ягындагы җиңги (җиңги – егетнең абыйсының хатыны) җәя (*«кыз куйнына керү»*). Җиңги булмаса, туганнары арасындагы кияүдәге хатын-кыз җәя. Урын җәйгәндә, яшьләр бәхетле булсын, тигез гомер итсен, дип, теләкләр теләнә. Иртән яшьләр урын җәйгән кешегә рәхмәт йөзеннән мендәр астына акча салып куялар.

Туй буласы көн билгеләнгәч, ике як кодалар да туйга әзерләнәләр. Татарлар яшәгән күп кенә җирләрдә туй йортларда үткәрелә. Зуррак шәһәрләрдә махсус ресторан яки мәҗлес залларында уздыралар. Кытайда туйга ирләр, хатын-кызлар аерым-аерым чакырыла. Информантлар фикеренчә, бу гадәт җирле халык булып яшәүче уйгырлардан татарларга күчкән.

*Зур туй* кыз ягында үтә һәм иртәнге сәгәть биштә үк башланып китә. Бу көнне иртәнге якта табын әзерләнә һәм табын янына җәмәгатьчелек, егетнең һәм кызның этиләре, ир туганнары җыела. Туйда хезмәт итәргә кияүнең иптәшләре килә, чөнки мәҗлестә ике меңләп кеше булырга мөмкин. Егетләр кунакларны каршы алып, озатып калалар, өстәл әзерлиләр, ашлар чыгаралар. «Килгән кодаларны аерым сары май һәм бал ашатып, туй булачак егет белән кызның киләчәк тормышының балдай тәмле, майдай ләззәтле булуын телиләр. Кодалар кайтып киткәндә, туйга ризалыгын белдереп, егет белән кызга дип, подноска акчалар салып китәләр» [Жэмуцзыя, с. 53].

Төшкә кадәр туйда ирләр генә була, төштән соң кияүдәге хатын-кызлар килә башлый. Бу вакытта егетләр китә, хатын-кызлар табынында кызлар хезмәт күрсәтә. Кичке якка туйга туганнар парлашып килә, кияү белән кәләшнең дуслары җыела, бу туй күпкә мулрак, матуррак була.

«Иртәнге намаздан соң бар мәхәллә, бөтен җәмагать туйга килә. Сәгать алтыга пылау инде әзер булырга тиеш. Иртәнге унга кадәр ир-атларны гына сыйлыйлар. Унар-унар кеше утырырлык итеп аерым-аерым өстәлләр куялар. Ирләргә пылау һәм чәй чыгарыла. Сәгать уннан соң хатын-кызлар килә башлый. Аларга пылау да, аш та бирәләр. Чәй ризыклары, тәм-томнар ике табында да бертөсле үк була. Уйгурларда кичке мәҗлескә яшьләр генә җыела, ә бездә – татарларда – туганнар да, олылар да килә. Кичке табын күпкә мулрак, баерак була, унлап төрдә кайнар һәм салкын ризык кына әзерләнә. Кичке ашка килгән

һәр хатын-кызга бүләк итеп сөлге яки яулык тараталар. Уртага төшеп биегән-җырлаганнарның иңбашына янә яулык яки шарф салалар. Бию-че-җырлаучы ир-егетләрнең дә һәр-кайсына түбәтәй бүләк итәләр» (З. Чапаевадан язып алынды).

Туй мәҗлесенә әзерләнә торган ризыкларны табынга чыгару тәртибенең кытай татарларына хас үзенчәлекләре бар. Кытайдагы татарларда табынга иң беренче чиратта чәй чыгарыла. Чәй янына җиләк-җимеш, варенье, баллы ризыклар бирелә. Чәйдән соң өстенә ит кисәкләре куеп пылау чыгарыла. Пылау – Кытайдагы татар туйларының иң төп ризыгы. Мәҗлескә уйгур халкының ризыклары да әзерләнә, шулай ук каз-тавык итләре дә табынга чыга, әмма туйга атап пар каз алып килү гадәте биредә күзәтелми. Информантлар моны бу якларда каз үстермәү белән аңлаталар.

Туй мәҗлесләре бик зурдан үткәрелгәнгә, хуҗалар да, аларның якын туганнары да кунакларны каршы алу белән генә мәшгуль була.

«Аш-су тирәсендә тирә-күршеләр, мәхәллә кешеләре кайнаша, кунакларны урыннарына утырту, сыйлау да алар өстендә. Хуҗалар бу эшкә катышса, аларга ышанмаган кебек килеп чыга. Туйны үткәрүдә ничә кеше катнаша, булыша, хуҗа аларга бүләккә шуның кадәр алъяпкыч, кулъяулык, аяк киеме әзерли. Якын туганнар туйны бик күтәрешә, алар, гадәттә, бүләккә акча сала. Туй хуҗаларына да бүләк – киемсалым, күлмәклек тукыма алып киләләр. Татарда: “Туйга барсаң, пар казыңны алып бар”, – дип әйтү бар. Кытайда без каз үстермибез, шулай булгач, ул-кызларыбызны башлыкүзле иткәндә, каклаган казлар әзерләмибез. Аның каравы, поднос тутырып тәм-том алып барабыз» (З. Чапаевадан язып алынды).

Туй мәҗлесе үтә торган көнне башкарыла торган тагын бер гадәт – *бирнә сандыгы илтү* бүгенге көндә, кызганыч, шактый гадиләштерелгән. Элек бирнәне кызлар үзләре әзерләгән, бүген исә әнисе, туганнары җыя. Бирнә эченә савытсаба, мендәр, юрганнар һәм шулай ук кияүнең әти-әнисенә, әби-бабайларына, туганнарына бүләкләр дә салына. Бүгенге көндә бирнә әйберләрен кыз ягы егет ягына машина белән алып килеп кенә бирәләр. XX гасыр урталарында әле кыз бирнәсен сандыкка тутырып, бу сандыкны туй вакытында олырак яшьтәге хатын-кызлар ача торган булган. Мәҗлес вакытында ике як туганнар бергәләп бирнәне караганнар, үз фикерләрен әйткәннәр.

Кияү кешенең кәләше янына килүе *(«кияү каршылау»)* кызны язылышырга алып бару һәм кичен аның ягында үтәчәк туй мәҗлесендә катнашу белән бәйле. Хәзерге вакытта туй мәҗлесен кафеда яки ашханәдә уздыру да гадәти күренеш.

Яшь кияү туй көнне кич белән сәгать дүрт-бишләрдә дуслары белән гармун тартып, җыр җырлап кызның өенә килә. Капка яки ишек-подъезд төбендә аларны махсус рәвештә тудырылган төрле каршылыклар, берсеннән берсе хәйләкәррәк итеп корылган тозак-киртәләр каршы ала. Борынгы заманнарда егет кешегә булачак хатынын чит кабиләдән алып кайтканда көрәшергә, төрле авырлыклар җиңәргә

туры килгән кебек, бүгенге көндә дә кияү кеше кызны яулап алу өчен, символик рәвештә булса да, төрле кыенлыклар үтәргә тиеш. Алар – элек-электән калган көрәш яки кияүне сынау йолаларының җиңеләйтелгән һәм үзгәртелгән бүгенге вариантлары, юмор белән үрелгән формалары.

Кызның дуслары яки абый-энеләре аркан тартып машина юлын бикләп, егетләрне кертмәгән булып шаяралар. Егетнең дуслары аларга күчтәнәч бүләкләр яки акча биреп узалар. Капка янына килеп җиткәч, кызның дуслары келәмнәр җәеп, егетләрне каршы алалар. Кыз янына кергәнче, егетләр җәза үтәргә – биергә, җырларга тиеш булалар. Җәзаларны үтәгәч, егетләр гармун тартып, такмаклар әйтеп, өйгә килеп керәләр.

«Кызның йөзе фата белән капланган була. Кызның йөзен ачтырткан өчен егет бүләк яисә акча бирергә тиеш. Кызны туйга әзерләгән кешегә. Аннары исә табындагы тәм-томнар белән яшьләр чәй эчәләр. Өстәлдә торт кебек ризыклар була. Кияү аларны кискәндә һәрберсе өчен акча түләргә тиеш, ул ризыкларны әзерләгән кешегә» (З. Чапаевадан язып алынды). Өйгә кереп чәй эчкәч, яшьләр җырлыйлар, күңел ачалар һәм җыелышып «әйләнеш»кә, ягъни урам әйләнер өчен кызны алып чыгып китәләр. Өйдән алып чыкканда, кыз өстенә конфетлар сибү гадәте яшәп килә. Бу гадәт кытай татарларында *«чәчмә»* дип атала. Аның нигезендә яшьләргә мул, татлы тормыш теләү ята.

Туй машинасы өй яныннан кузгалып киткәндә, күрше-күлән юлны ябарга мөмкин. Гадәттә, кияүдән юл хакы таләп итәлә. Акча түләп, кузгалып киткәч, яшьләр истәлекле урыннарны әйләнәләр *(«әйләнеш»)* һәм кичке туй буласы җиргә кайтып мәҗлесне башлап җибәрәләр [Сафиуллина, 2012, б. 30].

Кичке туйга килгән кунаклар барысы да, иң элек, ишек төбендә утыручы хуҗаларның ышанычлы кешесе аша узарга тиеш була. Бу кеше һәрбер кунакның алып килгән бүләген дәфтәргә теркәп бара (*«бүләк язу»*). Алып килгән бүләкләр исемлеге язылган дәфтәр гаиләдә гомер буе саклана.

«Беләсезме, ни өчен кирәк ул: үзең әлеге кешеләргә туйга алып барасы бүләгең алар алып килгәннән ким булмасын өчен. Шуннан аз булса – килешми. Ничек тә арттырырга тырышасың инде, һичьюгы бер күлмәклек тукыма өстисең. Без күлмәклекләрне бик күп бүләк итешәбез. Кызымның туе, аннан оныгымның бишек туеннан соң сандык-сандык булды инде алар» (З. Чапаевадан язып алынды). Бүләкне туйга ир-атлар алып килергә тиеш түгел, бары тик хатын-кызлар гына китерә. Туй мәҗлесе барганда, һәр хатын-кызга бүләк итеп сөлге яисә яулык тараталар. Биюче, җырчыларының һәрберсенең иңбашына йә яулык, йә шарф салалар, егетләргә түбәтәй бүләк итәләр. Гомумән алганда, кытай татарларында туйдан беркем дә бүләксез кайтмый.

Туй мәҗлесе вакытында үтәлә торган гадәтләрнең тагын берсе – *кәләшнең йөзен ачу*. Киленнең йөзен теләкләр әйтә-әйтә кияүнең әнисе ача. Теләкләр әйткән вакытта,

ул аның маңгаен сөеп куя һәм кызга алтын әйбер бүләк итә. Кияүнең әнисеннән соң, егетнең якын туганнары да кияү белән кәләшне котлыйлар.

Туй мәҗлесендә танышлардан яки туганнардан кем дә булса *«алып баручы»* ролен башкара. Ул сүз остасы, туйдагы кунакларны яхшы белүче булырга тиеш. Алып баручы кунакларга сүз бирә, шаян мәзәкләр сөйләп җибәрә, гомумән туйның күңелле үтүе өчен җавап бирә. Туйда, һичшиксез, гармунчы була. Шулай ук кытай татарлары арасында аккордеонда, баянда, заманча музыка уен коралларында уйнаучылар да күп. Уен коралларында уйнап, алар кунакларны җырлаталар. Туйда «Сарман», «Сагыну», «Баламишкын», «Каз канаты» кебек халык җырларын яратып башкаралар, шулай ук хәзерге заман җырлары да җырлана. Биючеләр уйгыр биюләрен һәм кытай татарлары арасында гаять киң таралган «Атнушка»ны башкаралар [Жэмуцзыя, с. 5]. Туй мәҗлесе тәмамланып, кунаклар таралышканда, һәр кешегә тәм-том, конфет-печенье тутырган пакетлар өләшәләр. Кем пакетка күчтәнәчне күбрәк сала, шуның туе күркәмрәк, баерак санала.

Материал туплаганда, кытай татарларының туй вакытында җырлана торган котлау җырларын һәм кара-каршы җырларны (кода-кодагый җырлары дип атау гадәте дә бар) язып алырга туры килде.

***Котлау җырлары:***

*Төркем-төркем куегыз,*
*Берсен безгә суегыз.*
*Җыру белән тәбрик итәм,*
*Котлы булсын туегыз.*

***

*Әй икегез-икегез,*
*Икегезнең битегез.*
*Икегез дә пар килгәнсез,*
*Тигез гомер итегез*

***

*Ал итәрсез, гөл итәрсез,*
*Бергә гомер итәрсез.*
*Сөбханалла, күз тимәсен,*
*Матур парлар икәнсез.*

***

***Кара-каршы җырлар:***

*Новый город күчәсенә*
*Тал читәннәр үрәмен,*
*Сез дусларны дус-ишләрене*
*Җаннан артык күрәмен.*

***

*Новый город күчәләрен*
*Себермәсәң дә такыр.*
*Безнең Колҗаның кызлары*
*Бизәнмәсә дә матур.*

***

*Быел килгән кошлар әйтә:*
*«Агач башы буштан», дип.*
*Кемне күрсәң, шулар әйтә:*
*«Аерылмагыз дустан» дип.*

***

*Тянь Шань таулары биек*
*Йөри арыслан көек.*
*Су сипмәгән гөлләр кебек*
*Йөрибез кибеп.*

Туй мәҗлесеннән соң, яшьләр кияү белән кәләшне яңа өйләренә хәтле озатып баралар һәм аларны анда янә бер кат тәбрик итәләр. Өйгә җыелгач, килен кунакларына чәй эчерә. Бу чәй мәҗлесе *килен кулыннан чәй эчү* дип атала.

Туйдан соң, якынрак танышу өчен, ике якның да туганнары килен белән кияүне кунакка чакыра башлый. Иртәгесе көнне кыз ягы егетнең әти-әниләрен *«кодалар чәе»*нә чакыра. Егетнең әнисе һәм хатын-

кыз туганнары кызның бүлмәсенә кереп яңа киленне күрәләр. Икенче көнне егет ягы кызның әти-әнисен һәм туганнарын кунакка чакыра. Аннан инде башка туганнары да кунаклаша башлыйлар. Кияү йортына кунакка килгәч, иң беренче эш итеп, яшь киленгә токмач бастырып карыйлар. Әгәр дә кискән токмачы әйбәт килеп чыкса, «булдырган килен була» дип әйтәләр. Яшьләрнең туганнарына кунакка йөрүләре атналар буена сузыла һәм кайсы вакытларда бәби туена кадәр дәвам итә.

Кытай татарларында туй йоласы үзенчәлекле гадәтләр, ышанулар, йола текстлары белән үрелгән. Аларга күзәтү ясаганнан соң, без туй йоласында төрки, Идел буе һәм Урал татарлары һәм уйгырларга хас йола-гадәтләрнең керешеп китүен күзәттек. Әйтик, кыз яучылау, ярәшү, килешү, никах, кияү каршылау, бирнә илтү, туйдан соң кунаклашу гадәтләре төрки халыкларның барысы өчен дә уртак. Шул ук вакытта әрвахлардан хәер-фатыйха алу, киленне авызландыру, урын җәю тәртибе һәм җәйгән кешегә бүләк калдыру, киленнең йөзен ачу, кодалар чәе, токмач кистерү гадәтләре, туй җырлары текстлары татар халкына хас булган йола-гадәтләрнең гәүдәләнеше булып тора, ә туйга кадәр чәй эчертү, егет ягыннан кызның анасына сөт хакы бирү, мал тапшыру, туй ризыгы – пылау пешерү гадәтләре уйгырлардан кергән дип фаразларга мөмкин, әмма катгый нәтиҗә чыгару дөрес булмас. Югарыда әйтелгән фикерләр, әлбәттә, алга таба эзләнүләрне таләп итә, чөнки бер мәкалә кысаларында гына кытай татарларының гомумтөрки контексттагы урынын билгеләү мөмкин түгел.

ӘДӘБИЯТ


Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 347 б.

Газизуллина Р. Шенҗан уйгырлары // Татарстан яшьләре. 2011. № 35. Б. 3.

Госманов М.Г. Ябылмаган китап. Казан: Татар. кит. нәшр. 1996. 206 б.

Жэмуцзыя Фатихэ. Кытай татарларында туй йоласы үзенчәлекләре // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 3. Казань: Ихлас, 2012. С. 13–16.

Зәкиев М.З. Төрки-татар этногенезы. М.: Инсан, РФК. 1998. 539 б.

Йосыпова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Мәдәниятара бәйләнешләрдә Кытай татарлары // Фәнни язмалар: фәнни мәкаләләр җыентыгы. Казан: Вестфалика. 2011. Б. 269–272.

Национальные меньшинства в Китае // Восточный свет. 2008. № 1. С. 65–71.

Сафиуллина Г. Өч хыял, яки килен төшә бүген бер өйгә // Сөембикә. 2012. № 1. 28–31 б.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 319 б.

Торопова А.В. К вопросу о жанровой классификации свадебного фольклора // Фольклор и этнография: обряды и обрядовый фольклор. Л.: Наука, 1974. С. 155–161.

Чанышев М.К. Кытайда татар мәгарифе тарихы. Казан: Җыен; Идел-пресс, 2007. 240 б.

Шәрифуллина Ф. Касыйм татарларында туй йоласы // Татарстан. 1993. № 11. Б. 45.

Этнотерриториалные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования. Историко-этнографический атлас татарского народа. Казань: Дом печати. 2002. 248 с.



***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
халык иҗаты бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре
e-mail: leyla.davletshina@yandex.ru

# ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

УДК 94(47).083

## 1897 ЕЛГЫ БЕРЕНЧЕ ХАЛЫК САНЫН АЛУГА КАРШЫ КҮТӘРЕЛГӘН ФЕТНӘ ИСТӘЛЕГЕ

*И.К. Заһидуллин, З.И. Гыймадиева*

В статье рассматривается позиция нерусских народов к первой всеобщей переписи населения 1897 г. в России на примере отношения к переписной кампании татар-мусульман Казанской губернии.

**Ключевые слова:** перепись 1897 г., татары-мусульмане, народное волнение, переписчик.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган кулъязмадан өзек Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана[1]. Аның авторы – Казан өязе Карыш волостеның Кариле авылында 1859 елның 2 гыйнварында игенче гаиләсендә туган Таҗетдин Сәйфетдин улы Ибраһимов. Аның балалык, үсмер еллары Казанда узган, бераз Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган, белемне Казан шәһәре сәүдәгәрләре бертуган Юнысовларның мөселман балалар ятимханәсе мәктәбендә алган. Таҗетдин, тормышы авыр булу сәбәпле, Алафузов фабрикасында яшьли киндер суккан, җәй көннәрендә Казан дары заводында эшләгән, гыйлемле егет Олы Кибәхуҗа волостена караган Сауш (Саваш) авылында дүрт ел мәктәптә мөгаллимлек иткән.

Мөгаллимлек елларыннан соң Таҗетдинның дин әһеле вазифаларын башкаруы мәгълүм. Аны Җанбулат авылы халкы үзләренең мәчетләренә мөәзин итеп чакыра. Биредә өйләнеп, гаилә кора. Указсыз мөәзинне Җүзин (Зюзинский) волостеның Түбән Ырга[2] авылы мәхәлләсенә имам вазифаларын башкарырга күндерәләр. Яңа җиргә имам булып китүе 1890–1891 еллардагы ачлыкка туры килә. Күченүенең төп сәбәпләреннән берсе дип гаиләсе белән ачлыкны исәнимин уздыру теләген, икенчесе итеп мәктәп ачып, үзе теләгәнчә балалар укыту омтылышын күрсәтә. Уфа шәһәрендә, Мәхкәмә-и шәргыя Ырынбургыяда имтихан бирүдән тыш, ул Казан шәһәр училищесы имтихан комиссиясенә кереп, русча белүе турында шәһадәтнамә ала, чөнки хөкүмәт 1891 елдан мулла итеп русча укый белгән кешеләрне генә билгели башлый.

Әйтергә кирәк, Таҗетдин Ибраһимовның биографиясе ул заман муллаларыныкыннан нык аерылып торган. Юнысовларның мөселман балалары приюты мәктәбендәге яшьли рус сыйныфында да белем

алган. Үзе язганча, гомере буенча гыйлемгә омтылган, мәдрәсәдә, гимназиядә, университетта укырга хыялланган, ләкин, тормышы авыр булу сәбәпле, беренче планда җан асрау торган. Приют мәктәбендә укыган иптәшләре белән бергә ул яңа ачылган Казан татар укытучылар мәктәбенә керергә җыена, әмма имтиханнарга соңга кала, кабул ителми. Икенче елны да, хәрби хезмәткә чакырылучыларны бу уку йортына алмау турында яңа канун чыгып, Т. Ибраһимов тагын укырга керә алмый кала.

Кульязмада тасвирланган вакыйгаларны тирәнрәк төшендерү өчен, аларны бераз шәрехләп китү урынлы булыр. Беренчедән, Түбән Ырга авылының элекке имамы Зыятдин Габделҗаббар улы, әтисе үлгәч, Олы Елга авылына күченгән, үзе, Т. Ибраһимовның муллалыкка сайлануын ишеткәч, аның блән таныш булмаса да, сез ялгышкансыз, ул русча укыган, «ертык газеталар укып йөрүче, динсез, дәһри» кеше дип сөйләп, авыл халкын, мулла килгәнче үк, аңа каршы котыртып куя. Нәтиҗәдә, авыл халкының бер өлеше Т. Ибраһимовка кырын карый башлап, ярдәмнәрен киметәләр. Мәктәптә хисап укыта башлагач, балаларның дәфтәрләрендә күргән кушу билгесен, плюсны (+), тәре билгесе дип санап, балаларыбызны урыс итәргә тели, дип, мәдрәсәдән куарга омтылалар. Т. Ибраһимовның указы булу гына мөгаллимлек эшен саклап калырга мөмкинлек бирә.

Икенчедән, Т.Ибраһимовның русча китаплар, газеталар укуы, «Тәрҗеман»ны алдыруы, илдә барган вазгыять, яңалыклар белән танышып барырга мөмкинлек биргән, шул сәбәпле аның кайбер фикерләре, яңалыкка карашлары күрше авыл муллаларыныкыннан, авыл халкыныкыннан нык аерылып торган. Бер сүз белән әйткәндә, түбәндә китерелгән текстның авторы – XIX гасыр азагы җәдитче мулласы дип әйтсәк, һич тә ялгышмабыз.

Өченчедән, автор 1897 елгы Беренче халык санын алу кампаниясенә хисапчы булып языла, статистик мәгълүмат җыюның мөселманнарның дини хокукларына турыдан-туры тискәре тәэсир итмәвен белә. Ләкин Т. Ибраһимов башка төрле фикер йөрткән, җан исәбен алу мөселманнарны чукындыруның башы дип, чын күңелдән ышанган авыл җәмгыяте белән кискен каршылыкка керә, аздан кына кыйналудан качып кала.

Т. Ибраһимов халык чуалышы биләп алган татар авылларындагы вакыйгаларны «эчтән» торып күзәтүче булып кына түгел, ә шул вакыйгаларда турыдан-туры катнашучы кебек бәян итә. Текст шул заман татар игенчеләренең дөньяга карашын, аларның коллективизм психологиясен, борчу-шөбһәләрен, мәхәллә халкының муллалар белән мөнәсәбәтләрен анукларга ярдәм итә. Җан исәбен алу вакыйгаларыннан соң Т. Ибраһимовның мәхәллә халкы белән мөнәсәбәте тагын да начарая, ахыр чиктә ул башка авылга күченеп китәргә мәҗбүр була. Кайбер вакыйгаларны, шәхесләрне бәяләвендә мулланың субъектив карашы да сизелә. Күрәсең, Түбән Ырганы ташлап китү аның күңеленә авыр җәрәхәт ясаган. Гомере буена

сузылган үпкә, рәнҗү шушы бәяләрдә дә чагылыш тапкан.

1897 елгы җан исәбен алу XVIII–XIX гасырның беренче яртысында салым салу өчен уздырылган халык хисабын алудан тамырдан аерыла. Аның нормативлары Европа стандартлары буенча эшләнә, һәм кеше турында 14 төрле мәгълүмат хисап бланкларына языла (респондентның исем-фамилиясе, гаилә хәле, гаилә хуҗасына карата кем булуы (кызы, улы, ир туган һ.б.), җенесе, яше, сословиесе, дине, туган урыны, торган урыны, даими яшәгән урыны, туган теле, укыйяза белү-белмәве, шөгыле, физик кимчелекләре).

Бу яңа, дәүләт дәрәҗәсендә мөһим эшне башкару җирле хакимияткә йөкләнә. Губернада сан алу комиссиясенең башлыгы итеп губернатор билгеләнә, өяз җан исәбен алу комиссияләрен өяз дворян собраниесе рәисе яисә өяз земство управасы рәисе җитәкли. Җан исәбен алу участоклары земский начальник участоклары кысаларында оештырыла, ә санау участоклары волостьлар чикләренә тәңгәл китереп төзелә.

Өязләрдә аңлату эшләре соңга калып, фәкать 1896 елның октябрендә земский начальникларны җан исәбен алу участоклары җитәкчеләре итеп билгеләгәч кенә башлана. Беренче чиратта, булачак хисапчылар исемлеге төзелә, аларны волость идарәләренә җыеп, земский начальниклар, хисапчылар өчен язылган «Наставлениеләр» тараталар, инструктаж уздыралар, бланкларны тутырырга өйрәтәләр, торак пунктларында йөргәндә кирәк булачак хисапчы портфеле, значогы, кәгазьләрне тутыру үрнәкләре, кирәк санда бланклар тараталар һ.б. Мондый оештыру эшләре 1896 елның декабрь аенда башкарыла.

Төбәкләрдә билгеләнгән хисапчылар арасында рус булмаган милләт вәкилләре бик аз була. Әйтик, Лаеш өязендә мөселманнар халыкның 36,8%[3] тәшкил итсә, 127 хисапчы арасында бары тик 10,2% мөселман була. Алар арасында – 4 мулла, бер өлкән унтерофицер, 1 рус-татар мәктәбе укытучысы, 4 волость идарәсе әгъзасы һәм 3 гади игенче. Муллаларның тулы исемлеген китерик: Югары Ыргадан Таҗетдин Сайфетдинов (Ибраһимов), Олы Кибәхуҗа волостеның Кече Шынар авылыннан Мөхәммәтҗан Мозаффаров, Казаклар авылының беренче мәхәлләсеннән Борһанетдин Габдерәфыйков һәм Күгәрчен авылы имамы Фатих Зәитов[4]. Мондый диспропорция татарлар арасында аңлату эшләрен кыенлаштыра, төрле ялган сүзләр таралуга нигез була. Әйтергә кирәк, татарлар арасында хисапчы булып язылырга теләүчеләр күбрәк була (медаль бирәбез дип кызыктыралар, акча да түлиләр). Алар русча яхшы сөйләшсәләр дә, земский начальниклар тарафыннан русча язу осталыклары чамалы дип бәяләнә, респондентларның җавапларын төгәл итеп русча кәгазьгә төшерә алмаслар дип, шикләнеп, эшкә кабул ителми. Казан губернасы хакимияте тутырылган бланкларны санауны җиңеләйтү һәм өстәмә тәрҗемә итүдән котылу өчен, Санкт-Петербургтан җибәрелгән татарча хисап бланкларын файдаланудан баш

тарта. Нәтиҗәдә татарлардан хисапчылар саны нык кими.

1897 елгы Беренче гомуми җан исәбен алу турында брошюраның татарча тәрҗемәләрендә кайбер төгәлсезлекләр китү – җирле хакимияткә тәмам ышанычларын югалткан татар игенчеләре арасында төрле имеш-мимешләр таралуга сәбәп була. Әйтик, анда шундый җөмлә бар: хөкүмәт яңа мәктәпләр ачу өчен һәр волостьтә, авылда мәктәп яшендәге балаларның санын белергә тели һ.б. Бу сүзләрне мөселманнар, безнең барлык авылларда да мәктәпләр инде бар, балаларыбызның санын ачыклап, хөкүмәт рус мәктәпләре ачарга һәм аларны мәҗбүри русча укытырга җыена дип аңлыйлар, «һ.б.» дигәне тагын төрледән-төрле вәсвәсәләргә нигез була.

Мәхкәмә-и Шәргыя Ырынбургыя 1896 ел 18 июль һәм 9 декабрь циркулярлары белән барлык дин әһелләренә мәхәлләләрдә җан исәбен алуның әһәмиятен һәм аның максатын аңлатуны йөкли.

Хисапчылар декабрь азагыннан гыйнвар ае дәвамында йорттан-йортка кереп, гаилә әгъзалары биргән җавапларны теркәргә һәм 28 гыйнвар көнне авыл җыеннарында тагын бер ачыклап, төзәтергә тиеш булалар.

Гомумән алганда, мөселман авылларында җан исәбен алу барышы ике сценарийга «сыеп» бетә. Шушы авыл кешеләре – игенчеме, мулламы – хисапчы булган авыл җәмгыятьләрендә матур гына башланган җан исәбен алу, базарлардан чукындыру турында хәбәрләр кайткач, тукталып тора. Халык бланкларны башка татар авылларында җан исәбен алу бетмичә хакимият органнарына тапшырмауны таләп итә. Бик сирәк очракларда гына хисапчы эшен ахырына җиткерә алган.

Декабрь азагында сан алучыларның авылларда күренүе мөселманнар арасында чуалышлар китереп чыгара. Халыкның каршылыгын күргән һәм кыйналып имгәнүдән, үтерелүдән курыккан күп кенә муллалар хисапчы вазифасыннан баш тарталар...

Күпчелек җәмгыятьләрдә хисапчыларны авылга, йортларга кертмиләр, һәр килгән чит кешене ныклап тикшерәләр, килү максатын ачыклыйлар, хисапчыларны куып, кыйнап, кире китәргә мәҗбүр итәләр. Авыл старосталарына һәм муллага нинди дә булса рәсми документларга кул куюны тыялар, аларны да кыйнау белән яныйлар.

Таҗетдин Сәйфетдин улы Ибраһимов истәлекләрендә шушы вакыйгаларның Түбән Ырга авылында барышы тасвирлана. Ул волость идарәсеннән алып кайткан бланкларны ике хуҗалыкта гына тутырырга өлгерә, халык белеп алып, аның бу гамәленнән тыя. Тагын өйгә килеп, тентеп, кыйнап китмәгәйләре дип, икенче көнне бер тәүлеккә башка авылга барып төн уздыра. Земский начальник янына барып, килеп туган хәлне аңлата, хисапчы вазифасыннан баш тартуын белдерә.

Шулай итеп, гыйнвар башында бер Түбән Ыргада гына түгел, Казан губернасының күпчелек мөселман авылларында җан исәбен алу туктап кала. Шул сәбәпле, хакимият кораллы җәзалау отрядлары оеш-

тыра һәм төрле өязләргә җибәрә. 10 гыйнвардан Мамадыш, Лаеш, Спасс һәм Тәтеш өязләре татар авылларында, кулга алулар һәм чыбык суктырып җәзалаулар уздырып, вице-губернатор А.Г. Левченко җитәкчелегендәге отряд йөри. 3 рота солдаттан торган икенче отряд губернатор П.А. Полторацкий җитәкчелегендә 9 гыйнвардан 30 ына кадәр Казан, Чуел, һәм Цивильск өезләрендәге баш күтәргән авыл җәмгыятьләрен буйсындырып йөри. Өченче отряд (160 солдат һәм 7 офицер) исә 14 гыйнварда Чистайга килеп, шәһәрдә татарлар арасында җан исәбен алуга күзәтчелек итә һәм, 30 гыйнварга кадәр татар авылларында йөреп, гаепле дип табылган 254 кешене кулга ала, прокуратура вәкилләре аларга җинаять эшләре ача, күпләр суд җаваплылыгына тартыла. Дөрес, Чистай өязендә җәзалаулар уздырылмый[5].

Истәлекләрдә аталган җәзалау отряды түбәндәге маршрут буенча хәрәкәт итә. 2 рота солдат башта Җылыш волосте Төбәк авылында туктый, халыкны буйсындыра алмыйча, 11 гыйнварда Иске Җөригә килә. Монда да, өяз исправнигының һәм отряд командиры подполковник Арбузовның үгетләүләренә карамастан, җан исәбен алу башланмый. 13 нче көнне хәрбиләр Усалы авылына күченәләр. Биредә төрле авыллардан китерелгән 30 игенченең алтысын 15 тән алып 30 тапкырга кадәр чыбык белән суктырып җәзалыйлар. Карга тезләндерелгән авыл халкы буйсынуларын белдерсәләр дә, хисапчылар йорттан-йортка йөри башлагач, пассив каршылык күрсәтә – ир-атлар хуҗалыкларын калдырып чыгып китәләр, өйдә русча белмәгән хатын-кызлар белән балалар гына кала, яки йорт хуҗасы сорауларга җаваплар бирүдән баш тарта. Нәтиҗәдә көне буена, 8 сәгатькә, фәкать 10 гаиләдә генә гына җан исәбен алу уздырыла.

14 гыйнвар көнне офицерлар, авылны 8 участокка бүлеп, бланклар алып, тәрҗемәчеләр һәм солдатлар ияртеп, хуҗалыкларга керәләр, гаскәриләр, авылны уратып алып, бер кемне дә торак пунктыннан чыгармыйлар. Шулай итеп, тиз арада эшне тәмамлап, гаскәр башка авылга күченә.

Вице-губернатор А.Г. Левченко җитәкчелегендәге гаскәриләр 16 гыйнварда Кече Кирмән авылына килеп җәзалау уздыралар. 17 гыйнварда Нырсыга китерелгән халыкны җәзалыйлар, 18 гыйнварда Сабада булалар. Биредә гаепле крестьяннар гына түгел, тәртипсезлекләргә юл куйган һәм аларда катнашкан авыл старосталары, сотниклар да җәзага тартыла. «Тәҗрибә» туплаган вице-губернатор Лаеш өязе татар авылларында үзенең гамәлләрен тагын да камилләштерә: Солтан һәм Сингели авылларында 7 шәр кешене җәзалый, Кабанда 5 кешене чыбык белән суктыра.

Таҗетдин Сәйфетдин улы Ибраһимов үзенең истәлекләрендә Солтан авылына барлык күрше-тирә авыл халкын, мулларны җыюларын бәян итә. Гаскәриләрнең беренче рәткә муллаларны, алар артына калган халыкны карга тезләндергәнен яза. Үзе исә алар арасына булмый, бинага кереп, земский начальниктан,

кайтып, җан исәбен алу кәгазьләрен тутырырга рөхсәт сорый, шул сәбәпле, аның биредә булган вакыйгаларны тасвирлавы башка кешеләр сөйләвенә таянып язылган. Гаепле дип табылган берничә крестьянны мунчада пешекләнгән чыбык белән 15–30 тапкыр суктыралар.

Архив чыганакларында язылганча, җәзалау бер үк тәртиптә башкарылган. Җыелган халыкны ярым ай рәвешендә карга тезләндергәннәр, алар шушы кыяфәттә авылдашларын җәзалауны карап торганнар. Вице-губернатор, барлык гаеплеләрне суктырам, дип әйтеп, халыкны куркытса да, билгеләнгән кешеләрнең соңгысын суктырганда, бинадан чыгып, «мин башкаларны кичерәм» дип белдергән. Чиновник 20–30 чыбык суктырырга кушса да, чынлыкта, гаепләнүчеләр 60–80 чыбык алганнар – җәзалаучылар 3–4 сугуны бергә санаганнар. Мондый тактика, җыелган халыкка ныграк тәэсир итсен өчен, махсус эшләнгән булуына шик юк.

Тексттан күренгәнчә, Түбән Ырга авылында җан исәбен алу йорттан-йортка йөреп түгел, ә волость кенәгәләреннән алынган исемлек буенча мулла өендә генә тутырылган. Күп авылларда шулай эшләнгәндер, чөнки 28 гыйнварга кадәр бу кадәр авылларны канунга туры китереп җан исәбен алу мөмкин булмаган.

### Таҗетдин Ибраһимовның 1897 елгы беренче халык санын алуга каршы күтәрелгән фетнә турындагы истәлекләреннән

...Первый всеобщий российский перепись 1897 нче ел ахырында башланып, 1898 нче елның башларында[6] тәмам булды. […]

[…] Первый всеобщий перепись 1897 хәбәрләре гәзитләрдә языла башлады. Элеккеге куркулары бетмәгән халык тагын чуала башладылар[7]. Авылдан авылга хатлар йөртә башладылар. Кайсылары укытырга чыгалар икән, укый белмәгән кеше урыс ягында кала икән. Башкалары шуның шикелле башка сүзләр сөйли башладылар. Перепись вакыты якынлаша башлады. Халык артыграк чуала башлады. Ничек итеп булса да переписька каршы тормакчы булдылар. Волостной старшиналар килеп, халыкны үгетли башладылар. Котырган халык, үгетне тыңлау кая, бәлки старшина вә писарьләрне кыйнарга тели башладылар. Шуларның берсе: безнең Җүзи волосте членнары бездән бер генә чакрым Югары Ыргага килгәннәр икән, кыйнарга теләүләрен белгәч, тизрәк кача башлаганнар. Халык артларыннан куа чыксалар да, җитә алмаганнар. Аларның юллары безнең аркылы иде, безнең авылдан да, куркытыр өчен булса да кирәк, берәр кеше куган булган. Шуннан соң алар бер авылга килеп, сез бу эшкә каршы килмәгез, миңа сезнең үз муллагыз язмакчы була, ул зыянлы нәрсә язмас дип үгетләп карадылар. Шуннан соң мин дә әйттем: Җәмәгать! Бу бит статистика, бөтен Руссиядә күпме халык тора һәм ничә төрле халык вә ни кәсеб белән терек кылалар. Баймы, ярлымы – шуларны белү өчен генә, монда һич дингә тию юк, дисәм дә, минем сүзләремне ишетәселәре килмәде. Халык: юк, без аңар яздырмыйбыз, урыныннан төшерәбез дә авылдан куабыз, диделәр. Шунда старшина

әйтте: аны сез генә куймадыгыз, аңар указны хөкүмәт бирде, сез аны куа алмассыз, диделәр дә киттеләр.

[…] Перепись бөтен Русиядә бер көнне булачак иде. Вакыты җитә башлагач, земский начальник, үз кул астындагы счетчикларны барлап, волостной правлениегә чакыртты да ничек итеп язу хакында тәгълимәт бирә башлады. Устав вә кирәкле кәгазьләрне электән үк биреп куйган иде. Мөселманнан без икәү генә идек, күбрәге руслар иде. Устав буенча мин аңар үзем әллә ни кадәр сораулар кылдым. Ул аларны, мин безнең җыелышыбызда мәсьәләгә куярмын, дип, билге ясап, алып китте. Ул вакыт рамазан ае һәм көннең бик кыска вакыты иде, шунда мин земскийга әйттем, безнең намаз укыган гыйбадәтебез бар, бер көндә бу эшне ничек бетерә алырмын, миңа туры килмәс ахры, дидем. Улустан авылыннан байтак кына кешеләр бар иде, алар бар да миңа, хәзрәт, яхшы диделәр, земский начальник бик күңелсезләнде дә әйтте: мин сине беренче счетчикларымнан саныйдыр идем, дип, җаныма сада шул кыяфәттәрәк китте. Ахры, бу үзе дә хилаф якта булып, халыкны котырта торгандыр, дип уйлады бугай. Мин дә соңыннан уйга төшеп, һич юк җирдә үземне үзем һәлак иттем бугай, дип, кабул итүем өчен заявление бирдем дә Лаешка[8] бардым. Ул вакыт земский начальник Яшин фамилияле бер урыс дежурный иде, мине күргәч, бик ачык чырай белән [каршы] алды да әйтте: татардан үзләре теләп алучылар бар иде, ләкин русча сөйләшә белсәләр дә язуларын дөрес яза белмиләр. Мин шуның өчен сине кылдым, диде. Перепись көннәре якынлашкач, тирә-якларда бунтлар ишетелә башлады. Шулай булса да, өскә алгач, эшне эшләми хәл юк бит. Көне җиткәнче берәр кешегә кереп, тәҗрибә кылып карамакчы булып, үземә дусрак вә каршы тормый торган кешенең бар гаиләсен яздым. Аннан соң икенчесенә кергән вакытта кич иде. Мин әле халыкка сиздермәстән генә эш кылып карамакчы булган идем, кайдадыр халык белгән дә, бик тиз бер берсенә хәбәр җитешеп, җыелышып, шул кешенең капкасы төбенә килгәннәр, йорт хуҗасы Фәхретдин агайны чыгарып, кая мулла сиңа язарга кергән икән, чыксын, дигәннәр. Фәхри агай: әйдә, мулла, сине чакыралар, диде. Мин әйттем: мин анда чыгарга куркам, алар мине кыйнарлар, син чыгып, аларга әйт, ул миңа чәй эчәргә генә килде, диген һәм капкаңны бикләп, монда кермәсеннәр, дидем, ул кеше, хатыны белән бергә чыгып, юк, ул чыкмый, мин сезне кертмим, дип, капканы бикләргә теләгәч, халык, котыра төшеп, кайбер кыюраклары икән бераз бәргәләп тә ташлаганнар. Шау-шу бик каты ишетелә башлады: мин әкрен генә өй алдына чыгып, ишекне аз гына ачып, тыңлый башладым. Кайсысы әйтә: мулланың кулын сындырыйк, азмасын дип, кайсысы әйтә: үтерик, ди. Шуннан соң мин, качу нияте белән, абзарларга таба карадым, ай яктысы бар иде, бара башласам, күренерлек булдым. Ничек тә бераз ышыкланып торырлык урын кирәк булгач, караңгыда кармалап югары туфраксага менә торган баскычны тап-

тым да менеп киттем. Баскычымны югары алырга хәтеремә килмәгән. Яңадан Фәхри агай керде дә, әйдә, мулла, чык, синең өчен мине кыйныйлар, диде. Ләкин ул вакыт мин өйдә юк идем инде. Фәхри агай чыкты да: җәмәгать, ул хәзер миндә юк, әллә кая киткән, диде. Халык: юк, ул әллә кая китмәгәндер, шунда гына, бер төшкә качкандыр, без кереп үзебез эзлибез, дип, капкасын ачтырдылар. Кергәч, иң элек ак өйгә кереп, өйдә тапмагач, идән астына төшкәндер, аннан карыйк, дигәч, бер кыюрагы кулына лампа тотып төшеп як-якка карангалагач, бер кеше дә күрмәгәч, ул монда юк, диде, алайса иске өйдәдер, дип, андан да карадылар, анда да тапмагач, туфраксага менгәндер дип, лампаны югары күтәреп карый башлагач, мин морҗа артына качтым. Аннан соң алар менеп карарга кирәк дип әйтсәләр дә берәү дә менәргә кыя алмый, алай да көчли торгач, бер Бикбулат атлы кешене лампаны тоттырып менгерделәр. Ул, менгәч, мине күрде, мин аңар бармак селкедем. Лампа тоткан кулны төртеп төшерүемнән куркып [...][9] монда юк ул, диде. Халык аның сүзенә ышанмадымы, бар әле син дә мин дип, тагы да Мөхәммәдҗан дигән кешене менгерделәр. Ул, бөтенләй үк менмичә, баскычта торган көе генә карады да, монда икән, диде. Шуннан соң мин морҗа артыннан тордым да лампа тоткан кеше янына барып бастым. Шунда миңа әйттеләр: син нишләп безне язарга чыктың, төш, ди башладылар. Мин әйттем, мин язарга чыкмадым, бу кешегә чәй эчәргә генә килдем, сез язарга кушмыйсыз икән, язмыйм, риза булсагыз гына язам, дидем. Мин һаман төшми торам, чөнки халык күп җыелган, бөтен өйләренә сыешмыйча, әллә никадәр ишек алдында калган, әгәр төшсәм кыйнап ташларлар дип шикләнәм. Шул арада сотник белән ике десятник килеп җитте. Сотник, баскычка менде дә: әйдә, мулла, төш, мин сине өйгә илтәм, диде. Мин аңар әйттем: син бер кеше, алар күп, син аларны тыя алмассың, дидем. Ул әйтте: мин менә медалемне тагып, ике десятник алып килдем, бер сиңа да тидермәм, әгәр төшми карышып торсаң, алар ничек тә алырлар. Мин китәм, диде. Мин әйттем: әгәр тидермәслек булсаң, төшәм, дип, әкрен генә төштем. Ул арада байтак вакытлар үтеп, халыкның гайрәте сүнгән иде. Мин төшкәч, сотник, халыкны янындан куып, урамга алып чыгып, ике ягыма ике десятникны куеп, өемә таба алып китте. Шулай да артымнан килеп берсе ике тапкыр төртте. Соңыннан беленде. Рамазан атлы муллага [...][10] бер тиен дә бирмәгән дошман кеше икән. Мине эзләгән кеше дә шундый кеше иде. Сотник мине өемнең эченә кадәр кертте. Арттан ияреп килгән халыкның кайсылары өйгә дә керде. Кайсылары өй алдында, кайсылары ишек алдында калды. Өйгә кергәннәре: кая, мулла, перепись кәгазьләреңне бир, дип сорагач, өстәл өстендә торган бар кәгазьләрне бөтенләй алып бирдем, язылганнарын күрсәтмәдем, берәр кешене өйдә генә язып, икенче төшкә куйган идем. Кәгазьләрнең берсен алгач, сотник Җәләл әйтте: юк, алмагыз, аның өчен мин гаепле булам. Мин булмасам, алсагыз алыр

идегез, диде. Шуннан соң бар да чыгып киттеләр. Алар чыккач, инде мин өйдә калып, нишләргә кирәк икән дип, идәндә әрле-бирле йөрим. Болар бит мине өйдән алып чыгып та кыйнарлар, дим. Бер-ике көн кая булса да китеп торырга кирәк дип, бер хәйлә табып, старостаны чакырттым да: кая, син миңа олау бир, елда бирә торган ике сум акча бир, мин бит әле метрика кенәгәләрен биргәнем юк, иртәгә становой пристав Карнауха авылындагы[11] урядникка килә икән, шуңа тапшырмакчы булам дидем. Минем морадым ул түгел иде, ләкин ишеткән идем: шул авылның помещигы, аракы заводы тотучы Макашинга земский начальник килә дип, аны күреп, булган вакыйганы әйтеп, аның фикерен белмәкче булдым. Олаучы белән урядникка туктадык. Кереп сораган булдым. Хатыны, алар команда белән бергә йөриләр, диде. Олаучыга әйттем: бар, инде син кайт, әле өйдә юк икән, бераздан кайтачак, мин аны көтеп торам, дидем. Шуннан соң ул кайтып китте, мин Макашин йортына барып, хуҗасын күреп сорадым: сезгә бүген земский начальник киләсе икән, килмәдеме, дидем. Ул әйтте: киләсе иде, әле килеп җитмәде, көтеп тор, диде. Бераз көткәч, ул да килде. Мине күргәч тә: здравствуй мулла, как дела, диде. Мин аңа: дела как сажа бела, дидем дә, вакыйганы сөйләп бирдем: менә инде миңа ни әйтәсең, язарга кушасыңмы, әллә юкмы, дидем. Ул әйтте: мулла, хәзергә язмый тор, менә бер-ике көннән Олуг Солтан[12] авылына команда килеп җитә. Алар белән вице-губернатор да килә. Команда килгәч, халык үзләре үк кушарлар, диде, мин әйттем: иң кирәкле сведенияне җыеп бирдем, үз авылыбызга өйдә генә җиттем, ничек булыр икән, барысын да йөреп язарга күп вакыт кирәк дидем. Ул әйтте: закон өй борынча кереп, үзләреннән сорап язарга, диде. Инде болай булгач, өйдә генә язсаң да ярар. Ләкин кешегә әйтмә, диде. Шуннан соң мин җәяүләп өйгә кайтырга чыктым, ләкин өйгә кайтмыйча, күрше авылдагы помещикка кердем дә, мин бүген кич households сездә кунам, иртәгә мине Әшнәккә илтерсез дидем. Ул, ярар, кун, диде. Шул көнне безнең авылда бер бала үлгән икән. Мөәзингә күмәргә кушканнар, мөәзин: юк, мин куркам, мулла мине гаепләр, дигән. Югары Ыргага менгәннәр, аның мулласы да төшмәгән. Берсенең күммәве, икенчесенең төшмәве бер дә куркудан түгел, бары аз булса да, минем өстемә гаеп өйү булган, чөнки алар, теге Зыямулланың[13] котыртуы буенча, минем мулла булуыма каршы халыкны котырткан кешедер.

Иртәсен мине Новоселки[14] авылыннан Олуг Әшнәккә[15] илттеләр. Мине илткән урыс ямщигын Әшнәк кешеләре юлда тотканнар да, син безнең авылга нинди кешене китердең, дип, бәйләнә башладылар. Ул әйткән, мин белмим, миңа барин илтергә кушкач, мин илттем, дип, көчкә генә котылган. Минем Әшнәктә үги атам бар иде. Шуңар төшкән[идем], дидем, дәррәү бер-ике кеше килеп керде дә, миңа бәйләнергә килә, диләр. Мин әйттем: мин инде ул эшне ташладым да, этиләргә кунакка килдем, дидем. Шуннан соң алар чыгып киттеләр. Әгәр мин: юк, мин ул эшне ташламадым,

әгәр бары авылыбызның халкыннан куркып качтым, дисәм, хәзер халык җыйдырып, шулар янына алып чыкмакчылар икән. Ул көн җомга көн иде. Мин җомгага мәчеткә бардым, мәчет халкы миңа бер зверьгә караган шикелле карый башладылар. Шуны белгәч, җомганың фарызын гына укыдым да тизрәк сыздым.

Шул көнне земский начальник безнең авылга барып, халыкны җыйдырып, арбасыннан төшмичә генә, атын китү уңаена каратып, вәгазьләргә тотынган. Петербургта перепись хакында Курганский матбагасында басылган бер рисалә тараткан иде, анда авылларда школалар бармы-юкмы, шуларны белү хакында да сүзләр бар иде. Бер Вафа исемле шул рисаләне алып килеп, земский алдында укый башлаган, аны бер Хисмәт исемле ак чәчле карт солдат земскийга тәрҗемә кылып торган. Ул инде рисаләдә язылган сүзләрдән дә арттырыбрак сөйләгән. Земский, я тебе седой волосада, дип, җанып киткән. Минем мулла булуым Николай падишаһның[16] яңарак тәхеткә утырган чакларында иде, земский начальник аңар ант иттерергә килгәндә, мөәзинебезнең өстендә сары тышлы тун иде. Рисалә укып торган Вафа исемле кешенең өстендә дә күксары тышлы тун иде. Шуннан аны мөәзин дип белгән. Әле халык: менә мулла әллә кайда йөри, бер үлек ята, күмәргә мулла юк, дип, донос та ясаганнар икән, земский игътибарга алмаган.

Команданың Лаеш уездына чыкканы ишетелгән иде. Кайлардан әйләнеп килүе булгандыр, Солтан авылына якынлаша башлагач, шул тирәдәге бар авылларга фәлән көнне, авылда ирләрдән һич кем калмасын, Солтанга килсеннәр, дип, һәм муллалар да калмасын, дип, һәм мөәзинне атап әйткәннәр. Мөәзин, моны ишеткәч, иртәнге намазда халыкка: җәмәгать, мине мулла күрсәткән, мине Солтанга чакырганнар, мине сугачаклар икән, мин моңар чыдый алачак түгел, үләрмен, дип елый башлады. Мин әйттем: сине күрсәткәнем юк, дидем. Чыкканда исемә төште дә, ә сине, сары тышлы тун сәбәпле, Вафаны син дип белгәннәр, дидем. Ул, минем сүземне чынга чыгармас өчендерме, белсә, минем авылымда бер Төхфәт атлы кеше Солтанга барып, земскийга: мулла гаепсез кешегә гаеп яккан, дип донос биргән. Земский: юк, миңа донос биргән юк, мин үзем замечать иттем, ул бит сходта халыкка кенәгә укып торды, дигән. Теге кеше юк, ул мөәзин түгел, Вафа исемле кеше иде, дигән. Земский: алайса ул мөәзинне миңа китереп күрсәт, мин танырмын, дигән. Шуннан, теге кеше кайтып, мөәзиннен илтеп күрсәткәч, хәер, бу түгел, бу карт икән, ул яшь кеше иде, дигән. Вафага әйткән икән, Вафа, сугылудан куркып, качып, Казанга киткән.

Билгеләнгән көнне Солтанга халык вә муллалар җыелды, мин дә бардым. Әле ул арада команда килеп җитмәгән иде. Авыл халкы: мулла безнең өстебездә торып суктырды, дип әйтерләр дип уйладым да, земскийга кереп киттем: минем монда торырга вакытым юк, миңа язып чыгарга вакыт, мин кайтам, дидем. Ул: бар кайт, алайса, дип җибәрде.

Командага сугылырга тиешле кешеләрне ияртеп килгәннәр,

мәсәлән: Савыштан Габделлатыйф исемле кешене, Солтанның үзеннән Әхмәдшәриф, безнең тәрҗеман Хисмәтне, [...][17] исемле кешене дәки мин белмәгән, әллә кемнәрне үз алдына аерып куйганнар. Аннан соң халыкны солдатларга чолгап алдырып, муллаларны алдагы сафка, мужикларны арттагы сафка тезләндереп, чиновниклар арасыннан кайсыдыр, менә сез патшага каршы киләсез, әгәр – риза булмасагыз, бу солдатлар барыгызны да атарлар дигән. Халык, курыкканлыктан, бер сүз дә әйтә алмаганнар. Шуннан соң билгеләп куйган кешеләрне мунчада пешекләп куйган чыбыклар белән сукканнар. Кайсысын утыз тапкыр, кайсысын илле тапкыр, ә тәрҗеман Хисмәтне йөз тапкыр сукканнар.

Перепись тәмам булганның соңында, земский бунтта башлап йөрүчеләрне кемнәрдәндер сорап алган да, аларны яңадан ничәшәр тапкырдыр сугарга хөкем иткән. Шул кешеләрне миннән сорап карады, мин белмим, качып тордым, кемнәр икәнен күрмәдем, дидем. Земский, Фәхри агайны кыйнаган кешеләрне судка бир, дигән. Фәхри агай миңа әйтте: мулла, мин сине кыйнаган кешеләрне судка бирәм, диде. Мин әйттем: Фәхри агай, юкка йөрмә, сиңа бер нәрсә дә булмаган, аны тагын миннән күрерләр, дидем. Мөәзин дә әйтте: Фәхри абзый, ташла, диде. Мин әйттем: син судка биргәч, бар да бер ташларсың, бары мине яман итеп калдырасың, дидем. Ул тыңламады – бирде. Суд вакытында шаһид итеп мине дә чакырдылар. Халык, судка мин барган дип, мулла, патша дип гозер итә башладылар. Мин әйттем: мин бирмәдем, әнә Фәхри агай тыңламады, ул биргән, аннан үтенегез, дидем. Аңар ялына башлагач, ул миңа карый башлады. Мин, теләсәң нишлә, бу синең эшең, мин кыйнаганын белмим, һәм шушы сүзне әйтермен, дидем. Ул, алайса, мин ташлыйм, дип, я простил, диде. Старшинаның бик ачуы килеп тора икән, ты простил, да я не простил, диде. Старшинаның шул сүзен ишеткәч, бәлки старшинадан курыккандыр, алайса я не простил, диде. Шуннан бер көнне чакырып җидесигез кешене, безнең авылдан Югары Ырга счетчигы менә шушы кешеләр безне кудылар, дип күрсәтеп, ничә кешенедер сукканнар.

Шушы эшләрдән соң халык тагын миңа дошманлыгын арттырды, хәтта бу турыда миндә бер гаеп булмаса да, сугылган кешеләр һәмишә миннән күреп, миңа һәм Фәхри агайга ут төртеп яндырмакчы булганнар, әгәр миңа ут төртсәләр, мөәзин яна, Фәхри агайга ут төртсәләр, аның күршесендәге агач өйләребез яна, дип кенә ташлаганнар. Шуннан соң халкыннан ярдәм дип әйткән нәрсәләр бөтенләй дип әйтерлек бетә язды. [...]

[...] Счетчиклык эшен тәмам иткәч, хөкүмәткә каршы бер нәрсә кылырга мөмкин булмаса да, муллага каршы мөмкин бит, халык гәбриһәле булып, мулла безнең балаларыбызны рус школага йөрергә язды, кирәксә без балаларыбызны аннан укытмыйбыз, дип, иттифак белән укытудан туктаттылар. Мөәзингә укытырга кушып карадылар. Ул бер кыш укыткач, мин өйдә генә укытам, дип, мәдрәсәгә керүне

ташлады. Мәдрәсә шулай хәлфәсез калды да, череп бетә башлагач, мәчеткә утынга турадылар. Шуннан соң мин бер нәрсә укытканым юк. Мин халыкка әйттем: инде сез миңа ярдәм биргәч, минем мулла булып торуымны яратмагач, минем һичбер китәргә урыным юк, мине иманага кертеп, җир бирегез дә, үзегезгә икенче мулла сайларбыз. Мин дә сезнең шикелле иген игеп торырмын, дидем. Алар миңа син бу авыл кешесе түгел, безнең үзебезгә дә җир аз, бирә алмыйбыз, диделәр. Бәлки миңа икенче авылга күчәргә булыр иде, әгәр тагы мәлсук Зыя мулла әтрафындагы муллаларны минем зыянга китертеп бетермәгән булса[18]. [...] (*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 80 нче фонд, 1 нче тасвирлама, 240 нчы эш берәмлеге, 11–12, 14–25 битләр*).

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] 80 нче фонд, 1 нче тасвирлама, 240 нчы эш берәмлеге.Текст гарәп имласында. 26,5x17 см юллы дәфтәргә язылган. Һәммәсе 42 бит. Битләрнең ике ягы да язылган һәм нумерланган. Укучылар игътибарына беренче халык исәбен алу вагыйларына кагылышлы өлешләре бирелә.

[2] Хәзер Татарстанның Балык Бистәсе районына керә.

[3] Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897 г. / под ред. Н.А. Тройницкого. Т. XIV. Казанская губерния. СПб. 1904. С. 106–135.

[4] Загидуллин И.К. Первая всеобщая перепись населения и татары Казанской губернии. Казань: Татар. кн. изд-во. 2000. С. 79.

[5] Загидуллин И.К. Күрсәтелгән хезмәт. С. 166–213.

[6] Автор ялгыша: җан исәбен алу 1896 елның декабрь азагында башланып, 1897 елның 28 гыйнварында, моңарчы җыелган мәгълүматларны тикшерү белән тәмамлана.

[7] Биредә сүз Казан губерна хакимиятенең 1878 елның 26 ноябрендә кабул иткән «Инструкция сельским обществам по выполнению возложенных на них законом обязанностей» исемле документта язылган маддәләр турында бара: барлык авылларда янгын куркынычсызлыгы максатында авыл уртасында чаң кую, мәктәпләрдә дин сабагын поплар укыту һ.б. карарлар. Моңа каршы Казан губернасында көчле каршылык хәрәкәте күтәрелә. Ахыр чиктә хакимият, ялгышын аңлап, «Инструкциягә» үзгәрешләр кертә.

[8] Татарстанның Лаеш шәһәре.

[9] Аңлашылмаган сүз.

[10] Аңлашылмаган ике сүз.

[11] Балык Бистәсе районының Корноухово авылы.

[12] Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылы.

[13] Түбән Ыргада туып үскән, соңрак Олы Елга авылында мулла булган, Таҗетдин Ибраһимовның туган авылына мулла булып билгеләнүен баштан ук яратмаган имам.

[14] Питрәч районының Новоселок авылы.

[15] Балык Бистәсе районының Олы Әшнәк авылы.

[16] Император Николай II 1894 елда тәхеткә утыра.

[17] Аңлашылмаган сүз.

[18] Соңгы абзац текстның 11–12 битләрендә, җан исәбен алу вакыйгаларын бәян итүдән алдарак язылган.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы***, тарих фәннәре докторы,
Ш. Мәрҗани исем. Тарих институтының
Урта гасырлар тарихы бүлеге җитәкчесе
e-mail: zagik63@mail.ru

УДК 930.3:091

# XIX–XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР КИТАП ТРАДИЦИЯСЕ: КУЛЬЯЗМА ҺӘМ БАСМА КИТАПЛАР

*Р.Р. Сафиуллина*

В статье рассматривается татарская книжная традиция XIX – начала XX в. Дается информация по особо распространенным экземплярам, специфике их оформления. Рассматриваются также вопросы сохранения, изучения и введения в научный оборот письменных памятников культуры.

**Ключевые слова:** арабографичные книги, рукописи, старые печатные книги, религиозная литература, письменные памятники, книгохранилища.

Язу, мәгълүмат тарату, фикер йөртүне теркәп кую һәм коммуникация чараларын камилләштерүнең аеруча уникаль чарасы буларак, мәдәният һәм цивилизация казанышларын бер буыннан икенче буынга тапшырып баруның бик мөһим ысулы булып тора. Кешеләрнең гыйлемлелеге язмаларны һәм китапларны сөю критерие белән үлчәнә.

Татар халкының характерлы үзенчәлеген, билгеле татар археограф-галиме, тарихчысы, академик М.Г. Госмановның бик төгәл билгеләп китүе буенча, «милли йөзне, татар халкының рухи кыяфәтен билгеләүче сыйфат» ны «бары тик бер сүзгә – китаплылык сүзенә сыйдырып бетерергә була». Ул татарларда китап, язма традицияләр булуын аңлата.

«Һәр халыкның үзенә генә хас бер сыйфаты була, диләр. Аның ерак һәм якын узганын, бүгенгесен, хәтта киләчәген дә билгели торган төп сыйфаты – милли сыйфаты.

Безнең халыкның шундый төп үзенчәлеге нәрсәдән гыйбарәт соң?

Мин... халкымның... милли йөзен, рухи кыяфәтен билгели торган төп үзенчәлеге дип, иң элек, бер сыйфатын әйтер идем. Ул бер сүзгә генә сыеп бетә:

Китаплылык.

Әйе, китаплы, ягъни язулы булу» [Госманов, 1994, б. 6].

Чынлап та, татар китап традициясе татар халкының күпгасырлык рухи тормышының аерып алгысыз бер өлеше булып тора. Ислам дөньясында киң таралган библиофильлек татарларда ислам кабул итү белән башлана. Ә ислам – дөньяның «китаплы диннәре»нең берсе, ул югары үсешкә ирешкән язма мәдәнияткә ия, ислам дине буенча, аның тарафдарлары гыйлемгә омтылырга тиешләр. Идел буеның мәгариф системасы гомуммөселман мәгарифе һәм мәдәнияте йогынтысында үскән, ә ул исә, халыкның төрле катлам вәкилләренә мөселман

цивилизациясе белән танышырга мөмкинлек биргән: гомер-гомергә Коръән һәм сөннәт, мөселман дин галимнәре, шагыйрьләре, философлары хезмәтләре белән яхшы таныш булганнар. Җирле авторлар үз әсәрләрен шәрык авторларына ияреп язганнар, шәрык авторларына шәрехнамәләр һәм субшәрехнамәләр төзегәннәр, аларның идеяләрен Идел–Урал регионында таратканнар. Ул заманнарның ислам дөньясында хезмәтләрне гарәп телендә язу кабул ителгән булган, шуның аркасында күп галимнәрнең һәм дин белгечләренең хезмәтләре Россиядән читтә дә билгеле булган.

Кызганычка каршы, иртә чор татар язма традиция ядкарьләре илебезнең кулъязмаларны саклау фондларында сакланып калмаганнар иярлек, ә Урта гасырлар әдәби чыганаклары аерым бер нөсхәләрдә генә сакланган. Казан ханнарының Казанны яулап алу вакытында Явыз Иван гаскәрләре юк иткән бик бай китапханәләре булуы турында мәгълүматлар бар. Монгол-татар явы вакытында да исәпсез сандагы матди һәм мәдәни ядкарьләр юкка чыккан, шул исәптән язма ядкарьләр дә. Аннан соңгы вакытларда да китаплар юк ителгән. Советлар чоры вакытында сугышчан дәһриләр гарәп язулы китапларны массакүләм яндырганнар. Шуннан куркып, меңнәрчә китапларны җиргә күмгән булганнар, димәк, алар да кире кайтарылмаслык итеп урнаштырылганнар.

Нәтиҗәдә, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларының халык хәтерендә сакланып калган дини-дидактик әдәби әсәрләре дә безгә соңгы исемлекләр буенча гына килеп җиткән. XVII гасырның хәтта кульязма исемлекләре дә сирәк кулъязмалардан исәпләнәләр. Шуңа да карамастан, XVII гасырдан башлап, татар авторлары язган хезмәтләрнең һәм татар катиплары (күчереп язучылары) эшләгән копияләрнең кулъязмалары күренә башлыйлар. Гасыр ахырына библиофильлек традицияләре торгызыла [Гараева]. Гарәп язулы кулъязмаларның күпсанлы каталогларында әл-Болгари, әл-Казани һ.б. кебек, нисбәсе[1] буенча татар-төрки булган күп санлы авторларны күрергә була. Алар нигездә XVII гасыр ахыры – XIX гасыр һәм XX гасыр башы татар дин белгечләренең (галимнәр яки голяма) хезмәтләре. Россиядә татарларга билгеле бер вакытка кадәр интеллектуаль эшчәнлекнең бары тик бер төре – дин белеме белән генә шөгыльләнергә рөхсәт ителгән, шуңа күрә татарларның бар рухи-иҗади потенциалы руханиларда гына тупланган булган.

Татар кулъязмаларының төп өлешен дини тематикадагы хезмәтләр тәшкил итәләр, алар – гарәп һәм фарсы телләрендәге популяр әсәрләрнең татарчага тәрҗемәләре, аларга шәрехнамәләр һәм шулай ук социаль-көнкүреш һәм дини-дидактик эчтәлекле әдәби әсәрләр.

Гомумән алган вакытта, ул әсәрләрнең репертуры универсаль, ул дини фәннәрне дә, астрономия, табигать белеме һәм тыйб, философия һәм логика, тарих һәм этнография, грамматика һәм лексикография кебек табигый һәм һуманитар фәннәрне дә колачлый. Татарлар

компактлы яшәгән урыннарда табылган кульязма мираслардан чыгып, шундый фикергә килергә була: татарларда әл-Фараби, ибне Сина, әл-Газали, ибне әл-Гарәби, Сәгъди, Хафиз кебек Шәрыкның күренекле фикер ияләренең хезмәтләре киң таралган булган. Бу кульязма мирасның билгеле бер өлешен татар авторлары хезмәтләре тәшкил итә, алар арасыннан Кадыйр-Гали-бәк (XVI гасыр ахыры – XVIII гасыр башы), Хисаметдин Мөслими һәм Таҗетдин Ялчыгол (XVIII гасыр ахыры –XIX гасыр башы), Габденнасыйр Курсави (1776–1812), Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) һәм башка бик күпләрне күрсәтергә була [Гараева].

Урта Азия суфыйлары Ясәви һәм Бакырганиның (XI–XII гасырлар) шигъри кыйссалары, Кече Азия суфый шагыйрьләре Җәләлетдин Руми (XIII гасыр), Мөхәммәд Чәләбинең (XV гасыр), Урта гасырлар авторлары Кол Гали (XII гасыр ахыры – XIII гасырның беренче яртысы), Мәхмүд Булгари, Хисам Кятибнең (XIV гасыр), Казан ханлыгы авторлары Кол Шәриф, Мөхәммәдьярның әсәрләре безгә билгеле. Кульязмаларның һәм басма текстларның иң күпләре Мәүла Колый (XVII гасыр), Габдерәхим Утыз-Имәни (1754–1834) һәм XIX–XX гасыр башы әдипләреннән Габделҗәббар Кандалый, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов һ.б. барларга туры килә.

Дини эчтәлекле китаплар арасында Коръән исемлекләре, тәфсирләр, Коръән экзегезалары билгеле бер урын алып торалар. Арада Урта гасыр авторларының канунлаштырылган хезмәтләре дә, татар авторлары тәфсирләре дә бар.

Мөселман татарлар арасында Коръәннең тулы булмаган нөсхәләре киң таралган булган. Кульязма җыентык һәм борынгы басма китапларда Коръәннең җидедән бере, ягъни, Һәфтияк-шәриф (Изге Һәфтияк, фарсы телендәге «һәфт-и як» – җидедән бер сүзеннән) еш очрый. Бу җыентык Коръәннең кереш өлеше – «Фатыйха» («Ачып җибәрүче») сүрәсе белән башланып китә, аннан соң Коръәннең икенче сүрәсе – «Бәкара» («Сыер”») сүрәсенең беренче биш аяте килә, ә аннан – 36 нчы сүрә – Йәсин, 48 нче сүрә һәм тәртип буенча башка сүрәләр. Татарларда шулай ук Коръәннең Гали бине Солтан Мөхәммәд әл-Кари (1014/1605) төзегән 1/60 – «Хизб әл-әгъзам әл-мөбәрәк» («Бөек мөбәрәк өлеш») тә киң таралган булган. Татарларда тагын Коръәннең аерым бер өлешләре – «Сувар мин әл-Коръән», «Әнгам», «Кәһаф (Тау тишеге)» дигән бүлекләре популяр булган. Таралышлары буенча Һәфтияктән кала икенче урында «Йәсин» сүрәсенең нөсхәләре һәм басмалары торган, аларны мәрхүмнәрне җирләгән һәм аларның өчләрен, җидесен, кырыгын һәм еллыкларын үткәргән вакытларда укыганнар. Шәкертләр мәктәпләрдә (инкыйлабка кадәр бары тик башлангыч мәктәпләргә генә булган, аннан югарырак белем мәдрәсәләрдә бирелгән) «Шараит әл-Иман»да («Иман шарты»нда) әлифба һәм диннең иң төп нигезләре белән танышканнан соң ук, шул сүрәне өйрәнергә керешкәннәр.

Җ.Вәлиди язуынча, укуның икенче елында «мөселман әлифбасын Коръәннең җидедән бере – Һәфтик дип аталучы өлеше алыштырган, ул үзе аерым бер китап булган. Ә укуның өченче һәм дүртенче елларында укучы үзе белән тулы Коръәнне йөрткән <...>» [Валиди, б. 6].

Коръәнне иң беренче булып татарчага тәрҗемә итә һәм Изге китапка шәрехнамәләр эшли башлаган кеше – реформатор галим Габденнасыйр әл-Курсави (1776–1812) булса кирәк. Бүгенге көндә Казан китапханәләрендә Коръән тәфсирләренең бу автор каләменә караган берничә кулъязмасы саклана. Бу хезмәтнең нигезенә Габдаллаһ бине Гомәр бине Мөхәммәд бине Гали әл-Байдавиның (691/1291 елда вафат) сөнни мөселманнар арасында популяр булган «Әнвәр әт-тәнзил вә хакагик әт тәгъвил» («Ачышлар яктысы һәм шәрехләү сере») тәфсире алына. Курсавиның вафатыннан соң ярты гасыр вакыт үткәч, 1861 елда, аның «Һәфтияк тәфсире» хезмәте басылып чыга. Коръәннең җидедән беренә шуңа аналогик тәфсирне Таҗетдин Ялчыгол (1768–1838) эшли. Бу тәфсир 1876 елда басылып чыга. 1915 елда Габденнасыйр Курсавиның «Тәфсир бәйан» хезмәте басыла [Курсави, 1915].

Тулы тәфсирләр бары тик XIX гасыр ахырында гына очрый башлый. Алар – Хөсәен Әмирхановның (1814–1893) ике томлы «Фәваид» («Файдалы әйберләр») исемле һәм Габденнасыйр Курсавиның шәкерте мулла Ногманның тәфсирләре [Ахунов] булганнар. Хөсәен Әмирхановның «Фәваид»е – Хөсәен Кәшифи (1504 елны вафат) тәфсиренең Мөхәммәд-Садыйк Иманколый (1870–1932) эшләгән «Тәсһил әл-бәйан фи-т-тәфсир әл-Коръән» («Коръән шәрехенә җиңеләйтелгән аңлатулар») исемле фарсы теленә күчерелмәсенең татар теленә аударылышы булган.

Татар борынгы басма китаплары һәм кулъязмалары арасында гарәп филологиясе, грамматика, лексикология, риторика буенча хезмәтләр зур урын алып торалар. Аларны ике төркемгә бүлеп карарга була: Урта гасырлар авторларының грамматика буенча хезмәтләре – XIX гасыр ахыры–XX гасыр башы татар авторлары төзегән гарәп теле дәреслекләре.

Кульязма мирасның шактый өлешен догалыклар тәшкил итәләр, алар татарлар арасында таралыш алган дини әдәбиятынең бик бай катламы булып торалар. Алар – төрле зикерләр, вирдлар, хизблар, пәйгамбәр өчен догалар, аерым-аерым яки бергәләп укый торган, йола, бәйрәм, ниндидер бер вакыйга уңаеннан яки ниндидер бер эшләрне башкарган вакытта укыла торган һ.б. догалар җыентыклары. Китап традициясенең бу төре мөселман дөньясында борынгы вакытлардан ук булган.

Әл-Газали (1111 елда вафат), әл-Килани (561/1165 елда вафат), эн-Нәвави (676/1278 елда вафат), әл-Җәзари, әл-Биркави (981/1573 елда вафат), әл-Аскалани (852/1449 елда вафат), әл-Кари әл-Хуруви (1014/1605 елда вафат) кебек авторларның дога җыентыклары һәм аларның догаларга шәрехләре киң таралган булуы мәгълүм [Арабские..., 1986, б. 167–180].

Татарлар арасында Мир Сәййид Гали бине Шиһаб әл-Хәмәдәни (714/1314–786/1384 еллар) авторлыгындагы «Далагел әл-хәйрәт», «Әврәд фәтхийә» («Җиңүчән вирдлар»), Зәйнеддин Әбү Хәмид Мөхәммәд әл-Газали авторлыгындагы «Дога җәннәт әл-әсмаг» («Исемнәр Җәннәте догасы») исемнәрендәге һ.б. догалар җыентыклары популяр була.

Язма чыганакларның шул ук типларына суфыйларның шөкер итү догаларын, вирдларын һәм зикерләрен кертергә була. Нәҗип Думави үзенең «Рус татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» дигән хезмәтендә: татарлар арасында туган телдә түгел, ә үзбәк-төркестән шивәсендә язылган мистик эчтәлекле поэма һәм җырлар киң таралган иде, – дип яза [Думави, 1999, б. 8]. Үзбәк шивәсе, шулай итеп, гарәп теле – дин теле булып кулланылган кебек, мистик әдәбият теле булып китә.

Төрле җыентыклар тупланган кече форматлы китаплар киң таралыш алалар. Алар арасында гарәп һәм татар-төрки телләрдә язылган догалар, Коръәннең аерым сүрә һәм аятьләре тупланмалары, дини йолаларны, төш күрүләрне аңлатулары һәм шулай ук төрле авыруларны дәвалау ысуллары күрсәтелгән җыентыклар була. Күз тиюләрдән һәм башка төрле бәла-казалардан саклау чаралары буларак, бөтиләрнең дә әһәмияте зур була.

Урта Идел һәм Урал алды татарларында шамаилләр дә (гарәп телендә – «саклаучы» сүзен, ә фарсы телендә – «портрет», «сурәт» дигәнне аңлата) бик популяр булганнар. Аларда символик сурәт, каллиграфик текст-комментарий белән бергә бирелгән. Шамаилләр сайланып алынган Коръән сүрәләре яки догалар язылган, зур булмаган форматтагы кульязмалар рәвешендә булганнар. Төркиядә андый кулъязмаларны Коръәннең алтынчы сүрәсе исеме белән, «Әнгам Шәриф» дип атап йөртәләр [Титовец]. Шамаилләрдә саклаучы-ритуаль эчтәлекле сүзләр орнаменталь-сәнгати фон белән бергә эшләнгәннәр. Коръән сүрәләре язылган шамаилләрдән тыш, фәлсәфи сүзләр, афоризмнар, Шәрык поэзиясенең шигъри текстларыннан өзекләр, Урта гасырлар татар шагыйрьләре Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьярларның шигъри юлларыннан өзекләр язылган шамаилләр дә булган. Фольклор әсәрләре фрагментлары булган шамаилләр җыр юлларын, тормыш мәгънәсе, гүзәллек, гыйлем нуры турында сөйләүче мәкаль-әйтемнәрне, ә кайвакыт тулы бер кыйссаларны үз эченә алганнар [Шагеева, 1990].

Татар кулъязмаларын төзегән вакытта Шәрык мөселман традицияләренең йогынтысы сизелә. Типик форматлары, тышларының бизәлеше, алардагы язу рәвеше, җирле ингридиентлардан әзерләнгән каралар, текстларны бизәүнең үзенчәлекләре, Россиядә эшләнгән кәгазьгә Идел буе регионында эшләнгән кульязма нөсхәләрне башкалардан аерып танырга була. Бу кулъязмалардагы гарәп һәм фарсы хезмәтләренең тематикасы дини хезмәтләрнең мәдрәсәләрдә шәкертләргә укытылган стандарт бер даирәсен тәшкил итә. Мәдрәсәләрдә укыту методикасының һәм басма

китапларның кыйммәт торуы шәкертләр үзләштерергә тиеш булган хезмәтләрнең копияләрен эшләргә мәҗбүр иткән [Гараева].

Татар кулъязмаларының тышкы бизәлеше үзенең тыйнаклыгы һәм кырыслыгы белән аерылып тора. Кулъязмаларга бизәкләр төшерү дә аларның баш өлешендә ешрак очрый. Кайбер китапларның битләре төрле каралар (кара һәм кызыл) белән язылганнар.

Коръәннең беренче һәм икенче сүрәсенең башы урнаштырылган рамнар төрлечә бизәлгәннәр, аларда мәгъмүрият мотивлары (мәчет гөмбәзләре), кызыл һәм кара өчпочмаклар белән каймап алулар һәм символик характердагы геометрик орнаментлар кулланылган. Хезмәтләр «Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән» («бисмил-ләһир-рахмәнир-рәхим») сүзләрен орнаментлаштырылган яки гади формада язу белән башланып китәләр. Ул кыскартылган формада «бисмилла» дип йөртелә.

Кулъязмаларда битләрнең номерлары гадәттә юк, битләрнең тәртибен хафизлар контрольдә тоталар. Хафизлар – битләрнең тәртипләрен «саклаучылар». Европа традицияләре буенча кустодлар дип аталучы бу хафизлар икенче битнең беренче сүзенең яки беренче иҗегенең аннан алдагы биткә туры килүен, ягъни, аның азагындагыга туры килүен тикшереп торганнар. Ләкин, кайбер кульязмаларда гарәп (ягъни Европа) цифрлары белән номерлау яки шәрык пагинациясе булырга мөмкин.

Китапларның күп өлеше популяр гарәп язуы «нәсх»нең җирле төре белән язылган. Бу язу нәсх язуының горизонталь кырыслыгын «тәгаллллекъ» белән тиз башкаруга нигезләнгән, шуның нәтиҗәсендә тиз языла торган һәм киң таралган «насталик» барлыкка килә.

Мөселман Шәрыгында руханилар гасырлар буе килгән күчереп язу традициясен яклаганнар, изге текстларга карата матбага ысулын куллануны мөртәтлек дип исәпләгәннәр. XIX гасырның уртасына кадәр гарәп Шәрыгында, Иранда һәм Төркиядә китапларны күчереп язганнар. Европада гарәп шрифты белән китап басу мөселман илләрендә басма китаплар күренгәнче күпкә алда башланган [Вахид, 1996, б. 109–121]. Гәрчә 1729 ел беренче басма төрек китабы – гарәп-төрек сүзлегенең дөньяга чыгу елы булып исәпләнсә дә, дини китапларны матбагада басуны тыю фәкать XIX гасыр башында гына алына. Ул вакытларда инде Казанда гарәп телендәге китапларны да, гарәп шрифты кулланып язылган татар телендәге китапларны да бастыра торган матбага эшли. Татарларда басма китаплар кулъязма китапларны тиз арада алмаштырып бетерәләр. Моның сәбәпләренең берсен тикшерүчеләр фабрикаларда эшләнгән, очсыз, сыйфатлы кәгазьнең Россиядә күп булуында, шуның аркасында китап бастыручыларның аны сатып алу өчен мөмкинлекләре булуында күрәләр. Ә Шәрыкта һөнәрчелек кярханәләрендә эшләнгән кыйммәтле кәгазьләр киң таралган булган. Аннан тыш, китап продукциясенең киң таралуына ул вакыт татарларында сәвәтлелекнең (уку-яза белүлекнең) алга китүе дә ярдәм

иткән. Сәвәтлелекнең андый зур күрсәткечләре өчен кульязма китаплар гына инде җитеп бетмәгән.

Россиядә гарәп шрифты белән китап баса башлау елы булып 1787 ел исәпләнә, ул елда, Россия мөселманнарының күпсанлы үтенечләрен исәпкә алып һәм кайбер сәяси мәнфәгатьләрдән чыгып, Екатерина II Санкт-Петербургта Әл-Коръәнне бастырып чыгару турында указ чыгара. 1789, 1790, 1793, 1796, 1798 елларда И.Шнорның «Азия матбагасы»нда (Крачковский аны Россия Империясе фәннәр Академиясе матбагасы дип атый) ул кабатлап бастырыла. Бары тик 1799 елда гына, күп сандагы мөрәҗәгать һәм үтенечләрдән соң гына, татарлар Павел I дән Казанда матбага ачуга рөхсәт алалар. Казан шуннан соң ук мөселман китаплары бастыруның провинцияләрдәге иң зур үзәкләренең берсенә әйләнә.

XIX гасырның уртасында нигездә дини эчтәлектә булган татар китабы халыкара базарга үтеп чыга, ул Урта Азия, Якын һәм Урта Көнчыгышның кайбер илләрендә сату-алу объектына әйләнә. Татар китабының, иң беренче чиратта Казанда бастырылган татар китапларының, конкурентлылыгы аның полиграфик үзенчәлекләре белән тәэмин ителә. Казан китап продукциясе чыга башлау һәм аның үсеше ике полиграфик мәктәп – көнчыгыш һәм көнбатыш мәктәпләре йогынтысында бара. Моңа Казанның «Европа белән Азия тоташкан» географик урыны һәм шуның нәтиҗәсендә анда туган тарихи-мәдәни вазгыять ярдәм итә. Шуңа күрә, татар басма китапларының тышкы башкарылу үзенчәлекләрендә традицион көнчыгыш һәм типик көнбатыш полиграфик традицияләрне дә күрергә була. Казан китап басучылары аеруча җиңел укыла торган «нәсх» язуы нигезендә, үзләренең аларга гына хас бик нәфис шрифтларын булдыруга ирешәләр, шәрыкта ул шрифт «Казан шрифты» исемен ала [Госманов, б. 29].

Татар китабы үсешенә, шулай ук, татар кулъязма китаплары традицияләре йогынты ясый, ул китап тышларын орнаментлаштыруда, куелма бизәкләү элементларында, китап ахырын бизәкләүдә, текстларны төрле сызыклар, орнаменталь бизәкләр белән каймап алуларда чагылыш ала.

Китаплар, аларның фрагментлары, аерым бер өзекләре турында сүз барган вакытта китапның, андагы сүзләрнең аеруча кыйммәтлелеге приоритетын ассызыклау күзәтелә. Китап ул – илаһи иҗат җимеше, Аллаһ сүзләрен аңлату, кеше күңеленә ирештерү һәм мөселман дөньясының олуг акыл ияләренең зирәк сүзләре. Китап сүзләренә карата сөю хисе, аны хөрмәт итү хисе һәр кулъязмада һәм һәр басмада бар, аларның титул битендә, кереш һәм йомгаклау өлешләрендә бу кульязма яки басманы зурлап язган юллар урнаштырылган.

Китапка, китап сүзенә аеруча зур бер хөрмәт белән карау борынгы вакытлардан ук татарларга хас күренеш булган. Татарларның бу сыйфаты, тулысынча ук булмаса да, татар язма мирасының зур өлешен саклап алып калырга ярдәм иткән.

Китапларны анда булырга мөмкин булган янгыннардан саклау

өчен, агач өйләрдә еш кына махсус таш келәтләр эшли торган булганнар. Апанаевлар, Таһир Ильясов, Мөхәммәдрәхим Юнысов, кенәз Заманов, Аитовлар, Иманкуловлар һәм башка билгеле кешеләрнең йортларында бай китапханәләр булган. Казанның «Мәрҗания», «Мөхәммәдия», «Касыймия» һәм, шулай ук, Түнтәр, Бәйрәкә, Чистай, Тымытык, Иж-Бубый, Стәрлебаш һ.б. мәдрәсәләр китапларның бай коллекциясенә ия булганнар.

Гарәп телендәге татар басмаларын[2] тикшереп, шәхси мин үзем җыелма каталог һәм компьютер белешмәләр базасы (Microsoft Access программасы ярдәмендә) төзүгә ирештем. Алардан күренгәнчә, гарәп шрифты белән китап басудан башлап 1917 елга кадәр, татар нәширләре гарәп телле басмаларны гына да 4000гә якын чыгарганнар [Сафиуллина, 2001]. Иң беренче чиратта алар кануни текстларны (Коръән, хәдисләр, тәфсирләр), ислам фәннәренең аерым бер өлешләрен (фикъһе (ислам хокукы), гакыйдә (ислам илаһияте), әхлак (ислам этикасы), мантыйк (ислам логикасы) һ.б.), гарәп филологиясен, суфыйчылык характерындагы басмаларны, догалыклар һ.б.ны бастырганнар [Сафиуллина, 2003, б. 19]. Шулай да аларда билгеле бер урынны җирле темалар буенча дини, социаль полемика алып тора. Алардан дини мәсьәләләр буенча Ш. Мәрҗани һәм аның оппонентларының дискуссияләрен, кадимчеләр һәм җәдидчеләрнең педагогика, илаһият мәсьәләләре буенча бәхәсләрен күрсәтеп китәргә була.

Әгәр дә татар басмалары буенча соңгы вакытта ачыкланган саннарны үзенең гомерен татар басма китабы тарихын торгызуга багышлаган китап белгече, академик Ә.Г. Кәримуллин китергән саннар белән чагыштырып карасаң, шуны әйтергә була: алар бик күпкә кимрәк күрсәтелгәннәр. Мәсәлән, ул китергән саннар буенча, Казан университеты матбагасында 1830 елдан 1850 елга кадәр аралыкта гарәп шрифты белән 193 татар басмасы нәшер ителгән [Каримуллин, 1992, б. 141]. Ә без ачыклаган мәгълүматлар буенча, ул вакыт аралыгында (ягъни 1830–1850 елларда) гарәп телендә генә дә татар авторларының 187 китабы бастырып чыгарылган [Сафиуллина, б. 29–30]. Гарәп телендә булмаган татар китаплары ул вакытта нибары алты гына исемдә бастырылган булып чыга.

Шулай итеп, гомуми татар басмаларының саны турында фикер йөртү авыр. Шуңа да карамастан, хәтта якынча исәпләүләр дә шуны күрсәтә: XIX гасырларда провинцияләрдә басылган һәр дүртенче китап, ә аның кайбер вакытларында – һәр өченче китап – татар китабы булган[3].

Гарәп графикалы китапларны XX гасырның 30нчы елларына кадәр нәшер иткәннәр, татар телле укучыларда XX гасырның икенче яртысыннан соң да андый китапларга ихтыяҗ булган.

Гарәп графикасындагы китаплар, кулъязмалар, вакытлы басмалар татар китап культурасы тарихын чагыштыралар, аларның басма вариантлары да, кулъязма формасын-

да булганнары да төрле фондларда тупланганнар. Татар кульъязмалары Казан, Санкт-Петербург, Мәскәү, Уфа, Ташкент, Баку, Истанбул, Ереван, Каһирә, Тәһран, Лондон, Париж һәм дөньяның башка шәһәрләре китапханәләрендә саклана. Бу язма мирасны саклау, өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертү – һуманитар фәннең иң актуаль мәсьәләләренең берсе булып тора һәм ул алга таба да шулай булып калачак. Татар кульъязмаларын фәнни тасвирлау һәм аларга кодикологик анализ эшләү – озакка сузыла һәм күп хезмәт сорый торган процесс, ә аны тәмамлауга әле бик ерак. Төрле китап саклау фондлары: Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегенең Көнчыгыш секторы, ТР Милли китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге, ТР фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать Институтының Кульъязмалар һәм музыкаль мирас үзәге, ТР Милли музее һәм Милли архивы фондлары белгечләренең тырышлыгы белән бу өлкәдә җентекле эш алып барыла: сакланып калган кульъязмалар буенча мәгълүматлар җыела, тупланмалардагы кульъязмаларны каталоглаштыру һәм фәнни тасвирлау эшләре башкарыла.

Ибраһим Хәлфин, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхретдин, Нигъмәтулла Кармышев, Сәет Вахиди, Вәли Зәбиров, Гали Рәхим, ә соңгырак чорларда Зәйнәп Максудова, Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Шакир Абилов, Раиф Мәрдәнов, Марсель Әхмәтҗанов һәм башка татар галимнәренең, мәгърифәтчеләренең, педагогларының татар китапларын җыю, саклау буенча керткән өлешләрен, археографик эшчәнлекләрен билгеләп китәргә кирәк. М. Әхмәтҗанов Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИнең Кульъязмалар һәм музыкаль мирас үзәге фондларының китап тупланмаларының зур өлешен булдырды, анда 6000 нән артык кульъязма китап һәм меңнән артык документ тупланган. Аның 30 елдан артык эшчәнлеге нәтиҗәсе булып, «Татар кульъязма китабы» исемле монографиясе чыкты [400 лет..., 1964].

Казан федераль университетының гарәп графикалы текстлары фонды Казанның башка шундый коллекцияләре арасында иң зурысы гына түгел, ә Россия Федерациясендәге аналогик дәүләт тупланмалары арасында да иң зурларының берсе булып исәпләнә. Аның гомуми фондында 13 меңнән артык кодекс бар, шул исәптән алты меңнән артык татар телендәге (госманлы төрки телдәгеләрен дә кертеп) хезмәтләр, алты меңгә якын – гарәп телендәге һәм меңнән азрак – фарсы телендәге хезмәтләр [Гараева].

Татарстан Республикасының көнчыгыш кульязмалары үзенең билгеле бер өлешендә, бик нигезле рәвештә, аның үз тарихи казанышы булып танылу алган. Россия, БДБ, Европа һәм Шәрык илләренең китапханә фондларында татар чыгышлы күренекле фән һәм мәдәният эшлекләре язган гарәп графикалы шактый күп сандагы кульъязмалар һәм басмалар саклана. Аларның күпләре бүгенге көнгә кадәр өйрәнелми кала бирә. Соңгы вакытларга

илебез фәнендә гарәп графикалы кульязмаларны өйрәнү буенча шактый зур тәҗрибә тупланса да, күп мәсьәләләр бүгенге көнгә кадәр ахырына кадәр хәл ителмәгән. Республикада һәм аннан читтә булган гарәп телендәге татар кульязмаларын исәпкә алу һәм каталоглаштыру эшләнеп бетмәгән, шәрык кульязмалары һәм кульязма традицияләре буенча ил масштабларында гомумиләштерелгән хезмәтләр җитешми. Шәрыкны өйрәнү буенча хезмәтләрнең һаман да киңрәк колач һәм гамәли характер алу шартларында бу җитешсезлекләр ныграк сизелә баралар. Тарихи-мәдәни, кодикологик һәм китап тарихын өйрәнү характерындагы конкрет тикшерүләр һәм фәнни нәтиҗәләр аерым бер хезмәтләр битләре буенча таралып бетәләр. Тар белгечлеккә таба тенденция кульязмаларны археографик, текстологик, тарихи, лингвистик, теологик, сәнгатьне өйрәнү һ.б. позицияләрдән өйрәнергә мәҗбүр итә. Кульязмаларны өйрәнүнең аерым бер шәһәр, хәтта аерым бер республика кысаларында гына алып барылуы, гәрчә алар җентекләп өйрәнелсәләр дә, ышанычлы гомуми нәтиҗәләр бирә алмыйлар. Татар кульязма мирасын өйрәнгән вакытта гомумроссия тәҗрибәсен дә, дөнья тәҗрибәсен дә исәпкә алу зарур. Бүгенге көндә гарәп дөньясы һуманитар фәннәрнең төп мәсьәләләренең берсе итеп мирасны өйрәнү, аңлату һәм популярлаштыру игълан ителә. Ә ул, билгеле булуынча, нигездә кульязмаларда чагылыш алган. Бу мирас мөселман мәдәнияте белән тарихи бәйлелеге булган бар илләрдә дә гаять зур кызыксыну уята [Халидов, 1985, б. 8].

Бүгенге көн реалияләре бу өлкәдә төрлеяклы күп мәсьәләләрне кичектергесез чишүне таләп итәләр. Бу – шәрык тикшерүләренең мәгълүмат-китапханә тәэмин ителешен, сирәк китапларны, кульязмаларны һәм документларны саклау өчен оптималь шартлар, аларның реставрацияләү һәм консервацияләүнең эффектлы системасын, мәгълүматны тикшерүчеләргә, кызыксынган башка кулланучыларга җиткерүнең камилләштерелгән ысулларын һ.б.ны булдыруны күз алдында тота.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Нисбә – гарәп (мөселман) исемнәренең этник, дини, сәяси, социаль чыгышын, аның тууын яки яшәвен һ.б. ны аңлата торган өлеше.

[2] Җыелма каталог һәм белешмәләр базасын төзегән вакытта төп ресурс булып библиографик чыганаклар (исемлекләр, күрсәткечләр, каталоглар) һәм архив документлары (ведомостьлар, отчетлар, Казан цензоры, цензура комитеты юлламалары, шулай ук китапханәләрнең каталоглары) хезмәт итте. 2001 елда, *de visu* басмалары белән танышкач, китап саклау урыннарында шул кадәр сандагы гарәп телле татар китапларының булуы ачыкланды: Казан университетының Н. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә – 1000 нән артык гарәп телендәге татар басмалары, Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә – 300 дән артык, КФТИ КФҮ РФА Фәнни Китапханәсендә – 250дән артык, ә РФ ФА Шәрык Институтының Санкт-Петербург филиалы Фәнни китапханәсендә – саны ачыкланмаган күләмдә.

[3] «Рус басма китабына 400 ел...» юбилей басмасы материаллары күрсәтүе буенча, Россиянең бар губерналарында 1801–1855 еллар аралыгында 1463 китап бастырылган [400 лет..., 1964, с. 291].

ӘДӘБИЯТ

Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары. Казан: Татар кит. нәшр., 1994. 288 б.

Гараева Н.Г. Арабографические рукописи. URL: http://www.vatanym.ru/?an= vs112_book1 (дата обращения: 11.03.2013).

Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар до революции 1917 года (фрагменты книги) // Библиотека журнала «Казань». № 6. Казань, 1992. 48 с.

Курсави Г. Тәфсир бәйан. Казан: Домбровский матбагасы, 1915. 79 б.

Ахунов А. Коран по-татарски. URL: http://kitap.net.ru/azatahunov.php (дата обращения: 11.03.2013).

Арабские рукописи Института востоковедения АН СССР: краткий каталог / под ред. А.Б. Халидова. В 2 ч. М., 1986. Ч. 1. 527 с.

Думави Н. Пробуждение русских татар и их литература / ред. Н.К. Гарипов, пер. Г. Свердлова. Казань: Иман, 1999. 20 с.

Титовец Е.И. На стыке двух культур: рукописные книги белорусских татар. URL: http://knizhkult.narod.ru/Titivetc.htm#_ftn1 (дата обращения: 11.03.2013).

Шагеева Р.Г. Каллиграфия // Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М.: Советский художник, 1990. 216 с.

Вахид Кудура. Начало арабской печати в Турции и странах «Шам» // Материалы симпозиума «История арабской печати». Дубай, 1996.

Сафиуллина Р.Р. Арабская книга в духовной культуре татарского народа. Казань: Алма-Лит, 2001. 212 с.

Сафиуллина Р.Р. История книгопечатания на арабском языке в России у мусульман Поволжья. Казань, 2003. 113 с.

Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. Казань. 1992, 208 с.

Ахметзянов М.И. Татарская рукописная книга. Казань: Таткнигоиздат, 2000. 270 с.

Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция. М.: Наука, 1985. 301 с.

400 лет русского книгопечатания. 1564–1964. В 2 т. М.: Наука, 1964. Т. 1. 664 с.

***Сафиуллина Резеда Риф кызы,*** филология фәннәре кандидаты,
Россия ислам институтының һуманитар дисциплиналар кафедрасы мөдире.
e-mail: rezeda.saf@mail.ru

УДК 2-335

# XX ГАСЫРДА ДИН ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ ЧИГЕНДӘ КЕШЕ ЯШӘЕШЕ

*Д.Р. Гыйльметдинов*

В статье рассматривается понимание феномена «традиция» для татар на разных территориях и в разное время с точки зрения исламского богословия. Прослеживается эволюция значения национальных традиций (в форме мазхаба, языка, религиозных обычаев и мировоззрений) видными деятелями татарского духовенства в знаковые для татарского народа периоды (досоветский, советский, постсоветский).

**Ключевые слова:** резонанс, обычай, традиция, иджтихад, иджма, ‘урф, ‘адат.

XX гасыр татарларны бик зур сынауларга дучар итте. Йөз ел эчендә татар милләте танымаслык булып үзгәрде. XX йөз башында татарлардан рус телен белүчеләр саны 5%тан артмаган булса, гасыр ахырына бу күрсәткеч тамырдан үзгәрде. Ул – зур фаҗигаләр, миләренә сеңдергән сәяси идеология һәм башка факторлар нәтиҗәсе, әлбәттә. Шулай да халкыбыз, атеистик модернизация чорын кичерүгә карамастан, үз иманын саклап кала алган. Монысы инде үз иманын «сатмаган» татар дин әһелләренең, дингә тугры калып, чынбарлыкка карата үз фикерен әйтә алуларыннан, заманына карап нәтиҗә ясый белүләреннән килә. Халыкның зур күпчелеге аларны дәүләт сәясәтен берсүзсез яклаучылар дип кабул итсә дә, кеше карашларын бәяләү өчен без һәрвакыт тарихтагы гомум вазгыятьне өйрәнергә тиеш. Вертикаль бәйләнештә – вакыт белән кешене, һәм горизонталь яссылыкта – кеше белән кеше бәйләнешен күрә белү мөһим. Татар иҗтимагый фикеренә килгәндә, төрле вакытта яшәгән, төрле позициядә торган дин әһелләренең фикерләре берберсен тулылындыра, бер теманың төрле якларын яктырта. Бер вакытта яшәгән рус һәм татар тарихчылары арасында, мәсәлән, андый резонанс күзәтелми. Ник дигәндә, биек булу – үзенчәлекле, туры сүзле, гадел фикер йөртү ул. Бу мәкаләнең геройлары – Хәлим Сабит, Ризаэддин Фәхретдин һәм Вәлиулла Ягъкуб. Аларның тормышларын яшәгән чорларыннан аерып булмый. Аларга карап, татар хокукый фикеренең эволюциясен күзәтергә мөмкин. Алар чынбарлык белән, аның идеологиясе белән килешмичә күтәргән проблемаларны фәнни дәрәҗәдә тикшерүгә ирешкән шәхесләр.

Шуңа күрә аларны руханилар дип кенә түгел, ә татар гуманитар фәненә зур өлеш керткән галимнәр, үз милләтенең бөек уллары дип атарга була.

Бүген без күп төрле гадәтләр, кыйммәтләр, системалар буенча яшибез. Минемчә, иң ныклы һәм дәвамлы совет кузаллавы – интернационализмга, рус теленең өстенлек итүенә һәм прогрессив карашларга корылган. Дини һәм милли традицияләр совет чорыннан калганына буйсына.

Хәлим Сабитның тормышын өйрәнгән төрек галиме Мустафа Кюкчек кызыклы нәтиҗәгә килгән: көчле дәүләт структуралары зур шәхесләрне тудыра, ягъни милли идеология аша халкының рухына богаулар кидерми торган дәүләттә гореф-гадәтләргә ихтирам хисе уяна, аларны яшәтү-саклау омтылышы тудыра икән. Мәсәлән, Хәлим Сабит, үзенең госманлы-төрек коллегаларына караганда, дингә ныграк бирелгән мөселман [Gökçek, 25]. Ул исламга тугры булып калган. Госманлы империясенең соңгы чорында «панисламизм» дәүләт системасын тәшкил иткән. Мәгәр үз фикеренә ия булган руханилар да авыр заманда чишелмәгән мөһим проблемаларны күтәргәннәр һәм аларга изге текстлардан дәлилләр китергәннәр. Ләкин авыр мәсьәләләрне зур галимнәр күтәргән булсалар да, гади халыкка, күпчелеккә андый мәгълүмат барып ирешмәгән. Ул актуальлеге ягыннан кешеләрдә кызыксыну тудырмаган. Бездә дә Совет чоры ахырына бөтенләй башка, милли тамырлары белән бернинди бәйләнеше булмаган гореф-гадәтләр генә калды. Табигый ки, яшьләрдә алар белән кызыксыну дәрәҗәсе аз иде. Без хәзер дә шундый хәлдә.

Сембер өлкәсендә туган Хәлим Сабит (1883–1946) ислам социологиясенең чишмә башында тора. Госманлы-төрек җәмәгать эшлеклесе Зыя Күкалп белән ул исламга Европадагы социологиянең методларын кертергә омтылган. Кайбер галимнәр, Х. Сабит төрек милләтчелегенең дин ягыннан дәлилләү системасын уйлап чыгарган, дип әйтәләр. Аның уйлавынча, гореф-гадәтләр, «иҗтимагый вөҗдан» төшенчәсе ислам диненең изге текстлары белән янәшә ислам чыганагын тәшкил итә. Беренче бөтен дөнья сугышы алдыннан Х. Сабит Истанбулда айга ике тапкыр «Ислам мәҗмугасы»н чыгарган. Анда гореф-гадәтләргә багышланган мәкаләләр сериясе ачып җибәргән. «Фикыһ ысулы» дигән дини гыйлем урынына ул «Иҗтимагый фикыһ ысулы» фәнен тәкъдим итә. Шулай итеп ул, Европа социологлары методларына һәм госманлы дәүләте җирлегенә карамастан, үзенең уникаль ислам концепциясен төзи.

Ислам фикһы ике өлештән тора: Аллаһ тарафыннан иңдерелгән текстлардан һәм иҗтимагый кагыйдәләрдән (гореф-гадәтләрдән). Текстлар өйрәнелә барган саен, җәмгыятьтә яңа проблемалар калка тора. Аерым территорияләрдә төрле мәзһәб мәктәпләре барлыкка килү – шуның белән бәйле. Х. Сабит фикһы хөкемнәренең бер өлеше – тексттан, бер өлеше гореф-ләрдән алынган. З. Күкалп, мәзһәбләр мөселманнар саны күбәюеннән

барлыкка килгән, дип санаган. «Кыяс» (чагыштыру) һәм «иҗмаг» (җыелышып мәсьәләне чишү) методлары дәгъват вакытында кулланылган. Имам Әбу Хәнифә гурефне аеруча мөһим санаган, «кыяс» методына караганда, «истихсан»ны (иң яхшы фикерне сайлауны) артыграк күргән. Әбу Йосыф, Әбу Хәнифәнең укытучысы, аның фикерен дәвам итеп: «Текст гурефтән чыккан, текстка буйсынырга тиешле, гуреф-гадәтләр текстның чыганагы булса, гадәткә күбрәк игътибар бирәбез», – дигән.

З. Күкалп «иҗтимагыять фәне»н төгәл фәннәр рәтенә керткән. Ул, Э. Дюркһейм идеясенә таянып, җәмгыять – аерым үз законнары буенча эшли торган фәнни объект, ди. Х. Сабит гуреф-гадәтне «иҗтимагый вөҗдан» дип атаган. Бүгенге «фикһы фәне» традицияләрдән арыну юлында. Икенче мәкаләдә Х. Сабит гурефнең гареб телендәге этимологик мәгънәләрен тикшерә. Аларның беренчесе – җәмәгать тарафыннан яхшы дип танылган әйберләр. Икенчесе – булышу; өченчесе – «гадәт» мәгънәләре («махсус гадәтләр», «гомуми гадәтләр», «телдәге гадәтләр», «сөйләмдә гадәтләр», «эштә гадәтләр» һ.б.). Бу мәгънәләрнең өченчесе җәмгыятьнең үсә бару процессында барлыкка килә. Элекке кешеләргә күмәк фикергә караганда төрле өлешкә бүленү, тармакларга аерылу хас була. Сабит алардан арынуны яклый. Гарәпләрдә гуреф кәлимәсе бүген дә үз көчендә яши, дияргә була.

Өченче мәкаләдә Х. Сабит изге текст һәм гурефләр беренчелеген тикшерә. Мәгъруф изге тексттан алда килергә тиеш түгел. Мәсәлән, җомга намазына бару әмер ителгән һәм изге («мәгъруф») гамәл. Чит кешеләр белән сату итү – заман кагыйдәләренә карый. Шуңа күрә, әмер ителгән әйберләр – махсус сферага кагыла, ә «мәгъруф» булганы – гомуми. Текстта күрсәтелмәсә дә, ул барыбер таләп ителергә мөмкин. Текст билгеле маддәләрдән төзелгән. Хәтта сәхабәләр вакытында бик күп вакытта текстка түгел, ә фикергә сылтый торган булганнар. Әмма соңгы вакытларда изге текст хөкемнәреннән ерагаймау йөзеннән алар ата-бабаларның фикерләрен өстен күрә башлыйлар. Вакыт узу белән «ихтиляфлар» (каршылыклар) барлыкка килде. Х. Сабит уйлавынча, әгәр без текстта дәлил эзлибез икән, яшәешебезнең нинди бөек икәнлеген аңламыйбыз. Шуңа хакыйкатькә ирешергә телибез икән, без карарлар чылбырының беренче буынына барып җитәргә тиеш.

«Гуреф» изге тексттан элек барлыкка килгән булса, китап аны төзәтә, һәм кешеләр күбрәк дингә дә, гадәткә дә ышана башлыйлар: «Гуреф тормыш көндәлегенә кереп киткәнче, анарга муафикъ буларак текстта гына калыр. Фәкать бу үзеңне белдермәү, гасыр сәгадәттән соң онытылганга күрә, Пәйгамбәр тарафыннан яки дәлилләр аркасында бетерелмәгән. Текстта булганны шулай яшерү – яхшылыкны яшерү ул. *Нинди дә булса гамәлгә вөҗданың игътибарсыз калса, тексттан бу кыланыш сызып ташланыр.* Кеше вөҗданы шушы хөкемгә игътибар бирми башлый. Изге текстка үзенә бер кем карамаячак. Беркем

аны таләп тә итмәс» [Сабит; № 14]. Гыйбадәт тәртипләре тулысынча иңдерелгән, без аны төзәтә алмыйбыз. Әмма көндәлек мәсьәләләр буенча алай түгел. Әбу Бәкер вакытында бурыч алу – начар, ул рибага (процентлар алуга) якын гамәл булып саналган. Шуңа күрә килешүләр төзү гарәпләр арасында таралмаган була. Ир кешеләргә ефәк киюдән тыелу – зөһед (тормышта гадилек) һәм тәкъвалык (Аллаһтан курку хисе) күрсәткече – соңгы вакытларда киң таралган Гомум фикыһта ул начар булып саналмый. Исламнан башка диндәге кешеләр башкаларның кигән баш киеменә зур дикъкать белән карыйлар. Музыка һәм рәсемдә шундый ук хәлләр күзәтелә. Садака Пәйгамбәр һәм Әбу Бәкер вакытында мәҗбүри булган, ә Гомәр мәҗбүрилекне бетергән.

Х. Сабит алдагы мәкаләсендә гореф-гадәткә тугрылыкны тәкъвалыгы белән бәйли һәм төрле хәдисләр китерә. «Гореф-гадәткә» багышланган соңгы мәкаләсендә автор тагын да тирәнгә китә. Гореф-гадәт шәригатьне җанландыра, дип яза. Шуларга иң мөһим булган шәригать хөкемнәре керә («горф мөҗәммал»). Гореф-гадәтнең тагын бер мөһим функциясе – шәригать хөкемнәре җәмгыятьтә һәркемгә аңлашылырлык итеп җиткерелергә тиеш. Шунсыз алар гаҗиз сүзләр булып, китапта гына ятачаклар. Гомумиләштерү функциясе аятьләрдәге туры мәгънәне гомум мәгънәсенә алыштыра. Мәсәлән, кешенең аякларын һәм кулларын искә төшергән аятьләр шушы әгъзалары булмаган кешеләр өчен дә мәҗбүри.

1913 елның ахырында ул «иҗмаг» һәм «иҗтиһад»ларның «гореф-гадәт» терминына мөнәсәбәтен тикшерә. «Иҗмагны» ул гореф-гадәтнең бер юлы итеп кабул итә, ягъни бер җәмгыятьнең мөгътабәр затлары киңәшеп ниндидер хокукый, йә дини мәсьәләне хәл итәр өчен җыелу. Төрле өлкәгә караган мәсәләләрне төрле төркемнәр чишәргә тиешле, чөнки халифәләр вакытында дини һәм дөньяви тормыш бергә алып бару гадәте булган, ә хәзер гадәт икенче. «Фәтва дәвере» урынына «канун дәвере» килде.

«Гореф-гадәтләрнең» һәм шул ук вакытта «шаригатьнең» тагын бер мөһим коралы – «иҗтиһад» мәсьәләсе. Милли гадәтләргә вакыт узу белән чит горефләр дә кушыла. Әмма аларны кабул итмәү чарасы – мөҗтаһид эше. Шуңа галимнәр белән мөҗтиһидләр тигезлек билгесен куярга ярамый. Ул халыкка, аның тарихына таяна, һәм халык та аны таный, ихтирам итә: «Милли вөҗданына гакес (көзге) улмак та иҗтиһадның шартларындандер» [Сабит, № 21]. Җәмгыятьтә андый вазифаны абруйлы кешеләрдән җыелган төркем даими рәвештә үтәргә тиеш. Иҗтиһад «заман» һәм «мөхит»кә карап төрлечә алып барыла. Мәсәлән, башта гарәбләр күчмә халык иде. Әбу Хәнифә вакытында мөселманнар составына күп шәһәрдәге («мәдинәле») кешеләр кергән. Шуңа хәтта фикыһта аларга аерым – «кул кадим» һәм «кул җәдит» – дип исем биргәннәр. Аннан соң Х. Сабит фикер алышу методикасына күчә. Аның уйлавынча «занни (рациональ) дәлил» җәмгыятьне үзе тирәсендә туплый алмый. Бу

нәтиҗәгә мондый мантыйк китерде: карарлар өч төрле була – кискен катгый, катгый һәм киңәш; беренче икесе иҗмагның мәгънәсен җуя, чөнки бер кешенең фикере җәмгыятьнең фикере белән бертигез булырга тиешле, алар ике вариантлы. Шуңа «гореф-гадәтләр» феноменына киңәш, фикерне тәкъдим итү күбрәк якын.

Х. Сабит, шәригать хөкемнәренең мөһимлеген гореф-гадәтләр тәэмин итә, дип саный. Кайбер галимнәр татарларның гадәтләре, башка мөселман халыклар белән чагыштырганда, изге текстның хөкемнәренә якынрак. Ләкин совет заманында андый гадәтләргә ихтирам белән карамаганнар. Хәтта СССР мөфтие Р. Фәхретдин 1926 елда Мөселманнарның үзәк дини идарәсе тарафыннан чыгарыла торган «Ислам мәҗәлләсе» журналында «хакыйкать» юлыннан биздерә торган әйберләр исемлеген төзи. Башта ул скепсис һәм пессимизмга (мәгънәсезлеккә) каршы сүзләрне атый. Аларны ул саташу һәм саташтыру дип бәяли. Хакыйкатькә ирешер өчен аны каплый торган 7 пәрдә аша узарга кирәклеген искәртә. Алар: өстән карау белән кәнәгатьләнү, мәслихәт (шәхси мәнфәгатьләр) артыннан бару, гадәт ташлый алмау вә дәүләттән («җөмһүрдән») курку, хисләргә ияру, бозык тәрбияле булу, сөйләүчегә артык игътибар бирү һәм тикшермәү (үз әһаленә яки белемле кешеләргә мөрәҗәгать итмәү). Гадәтләр турында Р. Фәхретдин болай ди: «Адәм баласы өчен гадәтне ташлау читен эш». Күп вакытта картлар гадәтне ташлый алмыйлар һәм яңалыкларга каршы торалар. Шуның аркасында картлар җөмһүргә («күпчелеккә») каршылык күрсәтмиләр, «шуңа каршы барырга батырчылык итә алмыйлар». Картлар вәкил ролен үтиләр, әмма бөтен халыкның фикерен белдермиләр. Р. Фәхретдиновның нәтиҗәсе шундый: «Фикер итми һәм тикшерми торган җәмгыятьтә, бәлки, акыл да азрак кулланыла. Иҗмаг үз ролен үтәми. Җөмһүрнең «иҗмагы» күпчелек җөмһүр фикере вә аңа иярченнәре бер нәрсәне кабул итү вә аның белән гамәл кылу хакыйкатькә ирешергә бирми» [Фәхретдин, 516 б.].

Җөмһүр сүзе белән гамәл кылмау зарарлы түгел. Динле кешеләр җәмгыятьтән аерылыбрак яшәгән. Кешеләрнең күпчелеге мәҗүси һәм христианнар булганлыктан, аларга ияреrгә ярамый. Кешеләргә ияру ярамаганын исбатлар өчен Р. Фәхретдинов мондый аятьне китерә: «Әй, Мөхәммәд! Әгәр дә җир йөзендә булган халыклардан күпләрнең сүзләрене кабул итсәң, анлар сине Аллаһ юлындан читкә чыкарырлар (үзләренә ияртерләр). Чөнки анлар үзләрнең вә вәһемләрнең хыялларына ияреп йөрүче халыклардыр һәм дә үз вәһемләренә бина итеп Аллаһ Тәгаләгә ифтира кылучылар, игътикат мәсләк вә мәзһәп төзүчеләрдер» («Әнгам» сүрәсе, 11 нче аять). Күрәбез ки, бу Х. Сабитка капма-каршы позиция – гадәтне ул хөкүмәткә буйсыну дип атый.

XX гасырның туксанынчы елларында Совет системасы җимерелде. Әмма ул калдырган бушлыкны безнең әлегә кадәр тутыра алганыбыз юк. Асылы, фундаменты булма-

ган чакта вазгыятьне аңлаган һәм ислам инфраструктурасын торгызуга зур көч куйган, дөрес, фикер йөртә белгән кешеләр арасында иң лаеклысы – Вәлиулла-хәзрәт Ягъкуб. Үзенең «Татарларда илаһны эзләү һәм ислам “нубуви” (“пророческий”)» мәкаләсендә ул татар җәмәгатьчелеген ике төркемгә бүлә: зыялылар һәм руханилар катламнарына. Әмма алар бер-берсен тыңламыйлар һәм аңламыйлар. Милли интеллигенция исламны аңламый, «вульгар социологик» методларны куллана. Совет чорыннан дин белгечләрен реформаторлар, мәгърифәтчеләр дип атау калган. Дини гадәтләр күбесе тулысынча юкка чыккан. Бүген дә ТР мөселманнарының дини идарәсе тарафыннан алып барылган эшне реформаторлык эшен дәвам итү белән бәйлиләр.

Габденнасыйр Курсави мөҗтәһидлек шартларын төзегән, ләкин үзен мөҗтәһид дип санамаган. Бу фикер Х. Сабитның «иҗтимагый вөҗдан» теориясенә каршы килми, бәлки, киресенчә, куәтли генә. Курсавиның төп идеясе – хәнәфиләр мәзһәбен хуплау һәм күтәрү иде. Вәлиулла хәзрәт: «Безнең гореф-гадәтләр традицион (мәзһәбтәге) исламның чаткысы. Ул либераль идеологиягә каршы килми – шәхси карашның мөһимлеген ассызыклый һәм чагыштыру (рациональ) методын ихтирам итә. <...> Мәзһәбтәге исламда гына «гореф-гадәт» термины, ягъни милли, халык гадәтләре күренеше бар. Мәзһәбтәге ислам милли гадәтләрне шәригатьнең бер чыганагы дип кабул итә. Моның белән реформаланган ислам («ваххабизм» һәм «сәяси» ислам) килешми». Безнең зыялыларыбыз «милли» ислам эзли, әмма безнең ата-бабаларыбыз ул турыда инде кайгырткан – хәнәфиләр мәзһәбен сайлаганнар. Чын ислам – безнең кул астыбызда. Якындагы мәчеткә, бабаларыбыз юлына әйләнеп кайтырга гына кирәк. Аннан соң Вәлиулла хәзрәт ислам белеменең дифференциацияләнүеннән зарлана (калам, тасаувыф, фикһы...). Аны туктатсак кына динебезнең тулы, камил сурәтенә ирешә алабыз, ди ул. Бу сурәттә Коръән, хәдис гыйлеме, тышкы торыш (фикыһ), эчке тәкъвалык (тәсаувыф), иман нигезләре (калам – гакыйда) бер-берсен тулыландырып, гармониядә торалар. Күрәбез ки, бу фикер Х. Сабитның күмәкләшүгә юл торткан фикерләре идеясенә бик якын. Татарларның интеллектуаль активлыгы сыйфатларыннан мантыйкка нигезләнеп уйлауны, абстракцияләшүнең тирәнлеге һәм киңлеген, интеллектуаль процессларның тизлеген атап үтәргә мөмкин. Шуңа күрә безне күбрәк гакыйдә һәм калям кызыксындырган. Татарлардан чыккан зур галимнәрдән Тафтазани һәм Даваниның зур фәлсәфи-игътикадый әсәрләр язуы шул турында сөйли. Бүгенге татарлар хәрефне мәгънәгә караганда күбрәк яраталар – анда хәдисләр коллыгы чире чагыла һәм ул татар менталитетына туры килми. Мәсәлән, татарлар инкыйлабка кадәр хәдисләрне бөтенләй басстырмаганнар (чөнки алар бер-берсенә каршы килә), тәфсирләр бастыру эше, киресенчә, җәелгән булган. Күбрәк фикыһта кулланылган, сайланган хадисләрне өйрәнгәннәр.

Шуңа ислам хакыйкатьне текст әмерләре аша гына түгел, ә күзаллау, дөньяга караш аша җиткерүне максат итә. Татарларда суфыйчылык һәрвакыт мантыйк белән чикләндерелгән була һәм ул тулы рәвештә, мөстәкыйль дәрәҗәгә җитмәгән хәлдә яши. Милли гореф-гадәтләрнең дошманнары – бәдәви гарәпләр (Х. Сабит та хәдисләрне кабул итмәскә кирәк дип санаган) һәм динсез европалылар. Татар горефләрен тәнкыйть иткәндә алар чит милләтләрнең гадәтләрен өстен куялар (Х. Сабит уйлаганча: «Гореф текстка ышанудан барлыкка килмәгән, аны фәсех (бозыклык) дип атап булмый. Фәсех булсын өчен икенче текст булынмасы тиешле. Шуңа фәсех (икенче текстны изге санау) да булырга мөмкин» [Сабит, № 14]. Үз табигатен белмәү (исламга кадәр булган гадәтләрне) матди һәм матди булмаган бәйләнешләрне аңламау нигилизмга китерә.

Китерелгән фикерләр диалектик эволюция турында сөйли (дөньяви – дини – катнаш). Х. Сабитнең «иҗтимагый вөҗданы» совет замандагы материализм теориясен хәтерләтә. Р. Фәхретдиннең картларны һәм дәүләтне сүгүе дини кешеләрнең рәсми өлкәдән ераклашуы һәм совет интеллигенциясе катламы барлыкка килү турында сөйли. Нәкъ шушы проблемаларны В. Ягъкуп тә күтәргән. Ул, олыларны ихтирам итү йөзеннән, тәкълидне кайтарырга өнди. «Бабайлык» Коръән хикмәтләрен һәм аларны белгән һәм укыган кешеләр белән тигезсезлегеккә китерә. Вәлиулла хәзрәт уйлавынча, текстка таяну гына тулы (камил) ислам цивилизациясе туугa җирлек бирә. Чөнки исламда прогресс дигән нәрсә юк, ә дөнья прогресска нигезләнә.

Х. Сабит шәригатьне заманча ясау йөзеннән горефкә күбрәк игътибар бирергә чакыра. Бүгенге көндә бу фикер хокукый плюрализмга китерә. Хокукчыларның бер өлеше шәригатьне һәм дөньяви канун системасын гореф-гадәтләр баетырга тиеш, дип саный, әмма икенчеләр гореф-гадәтләрне, кануннар кысаларыннан чыгарып, шәхси мөнәсәбәтләр дәрәҗәсендә калдыру яклы.

Х. Сабит уйлавынча, дәүләттәге кануннар исламны боза: «Хөкүмәт кануннары – динебездә булмаган бидгатьләр» [Karabacak, s. 32]. Шуңа аларны аеру мөселман җәмгыяви фикер үсешенең киләсе адымына юл ача, дип фараз кылырга була!

## ӘДӘБИЯТ


Gökçek M. A Kazan Tatar Contribution to the Late Ottoman Debates on Nationalism and Islam: The Life and Works of Halim Sabit Şibay. The University of Wisconsin. Madison, 2008. 305 p.

Karabacak M. Halim Sabit Şibay'da Din Sosyolojisi (1883–1946). Isparta: SDÜ Sosyal Bilimler Enstitüsü, 2001. 145 s.

Сабит Х. «Иҗтимагый фукаһа»ның тәгърифы вә изахлар // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 23. Б. 4–8 (566–570).

Сабит Х. Горф – мәгъруф (Иҗтимагый ысул фикыһ мәсьәләсе мөнәсәбәтеилә) // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 10. Б. 16–23 (204–211).

Сабит Х. Горф – мәгъруф (Иҗтимагый ысул фикыһ мәсьәләсе мөнәсәбәте илә)

// Ислам мәҗмугасы. 1914. № 11. Б. 2–5 (222–225).

Сабит Х. Горф – мәгъруф (Иҗтимагый ысул фикыһ мәсьәләсе мөнәсәбәтеилә) // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 12. Б. 2–5 (254–207).

Сабит Х. Горф – мәгъруф (Иҗтимагый ысул фикыһ мәсьәләсе мөнәсәбәтеилә) // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 14. Б. 2–9 (318–225).

Сабит Х. Иҗмаг (Иҗтимагый ысул фикыһ мәсьәләсе мөнәсәбәтеилә) // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 18. Б. 5–7 (487–489).

Сабит Х. Иҗмаг (Иҗтиһад, мөҗтаһид) // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 19. Б. 4–7 (502–505).

Сабит Х. Иҗтимагый әнмузаҗләрә күрә иҗтиһад замирәләре, иҗмаг фукаһа // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 22. Б. 2–6 (548–552).

Сабит Х. Иҗтимагый ысул фикыһ // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 5. Б. 17–22 (155–161).

Сабит Х. Мөҗтаһид, иҗтиһад // Ислам мәҗмугасы. 1914. № 21. Б. 2–5 (532–535).

Сабит Х. Тәкъва вә горф //Ислам мәҗмугасы. 1914. № 13. Б. 2–5 (286–289).

Фәхретдин Р. Дини мәсьәләләр хакында // Ислам мәҗәлләсе. 1926. № 1. Б. 514–519.

Якупов В. Татарское «богоискательство» и пророческий ислам. Казань. 2003. 52 с. URL: http://naqshband.narod.ru/tatar.html (дата обращения 04.06.2014).

*Тикшерү ТР хөкүмәте фәнни грантлар кысаларында («Османская империя как “окно в Умму” для татар-мусульман к. XIX – н. XX вв.», проект номеры 15-60 т/Г 2014) финанс ярдәме белән эшләнде*

***Гыйльметдинов Данияр Рөстәм улы,*** тарих фәннәре кандидаты,
Татарстан Фәннәр академиясе Исламны өйрәнү үзәгенең
чыганаклар бүлеге җитәкчесе
e-mail: ascoldan@gmail.com

# ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

УДК 398:93

## ХӘМИТ ХӨСНЕТДИН УЛЫ ЯРМӨХӘММӘТЕВ – БЕРЕНЧЕ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЧЫ ГАЛИМЕ

*Х.Ч. Алишина*

В статье освещаются жизнь и деятельность Хамида Ярми – уникального специалиста в области татарской фольклористики, в течение сорока лет последовательно занимавшегося изучением татарского устного народного творчества.

**Ключевые слова:** татарское устное народное творчество, фольклор.

Әле дә булса иске мәчет бинасында эшләп килгән Казарово мәктәбендә үзләренең бөек якташлары турында онытмыйлар. 2014 елның 18 апрелендә Хәмит Ярминең тууына 110 ел тулуга багышланган ачык дәрес (Х.Х. Кирамова, филол. ф.к.), әдәби-музыкаль композиция (Г.Р. Хөсәенова), мәктәп буйлап экскурсия (А.З. Манкаева мәктәп директоры), Төмән шәһәр депутатлары катнашында Түгәрәк өстәл артында сөйләшү (Р.С. Җиһашин, Д.М. Абукин) уздырылды. Бу чаралар мәктәп җитәкчелеге, Себер һәм Төмән өлкәсе татарларының Милли-мәдәни автономиясе көче белән оештырылды. Безнең горурлыгыбыз, танылган якташыбызның туган көненә минем тарафтан махсус язылган «Жизнь замечательных людей. Хамит Ярми» дигән китапны тәкъдим итү булды. Ул Төмән өлкәсе хөкүмәтенең матди ярдәме белән басылып чыккан иде.

Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтов (1904–1981) – фольклорчы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1964), филология фәннәре докторы (1969).

1939 елда Казанда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты оештырылган көннән башлап, 1972 елгача ул шушы Институтта: 1942–44 елларда аның директоры, 1944–71 елларда халык иҗаты секторы мөдире. Аның фәнни эшләре татар халык иҗатының шигъри-сөйләм жанрын колачлый. Хәмит Хөснетдин улы хәзер Төмән шәһәре биләмәсенә кергән Казарово (Кырынкүл) тирмәләренең берсендә дөньяга килә. Хәмитнең бабасы Ярмөхәммәт, чыгышы белән, Төмән өязенең Андрей (Интрәй) тирмәсеннән. Аның өч улы (Гайнетдин, Сәгадәтдин һәм Хөснетдин) була. Кечесе – Хөснетдин 1858 елда туа, ул 8 яшьлек чагында ук ятим кала. Язмышының әнә шул катлаулы, авыр дәверендә аның киләчәгенә юнәлеш бирүдә Себернең мәгълүм сәүдәгәрләре нәселенең бер вәкиле, мәгърифәтче Сәйдуков Нигъматул-

ла хаҗи мөһим роль уйный. Ул – 1628 елларда Бохара якларыннан беренче булып Төмән төбәгенә килеп урнашкан кеше. Ул Хөснетдинне Ямбай (Улуг Манчел) тирмәсенә үз тәрбиясенә ала. Риваятьләргә караганда, Ямбай Бохарадан Тоболь, Тару һәм Себернең башка шәһәрләренә юл тотучы кәрваннарның тукталу урыны була. Хөснетдин билгеле бер дәрәҗәдә белем алгач, укытучы-мулла вазифасын үти. Әмма, ялган әләк нәтиҗәсендә, репрессиягә дучар ителә, Уват районына сөрелә, аннан әйләнеп кайта алмый.

Хөснетдин мулланың балалары – Сәйфи, Хәмит, Рәшит, Гайшә башлангыч белемне әтиләреннән алалар. Аннан соң Хәмит Ямбайдагы затлы-зыялы иганәче (меценат) Нигъмәтулла Кармышак улы Сәйдуков тарафыннан нигезләнгән Бохара (ысулы җәдит) мәдрәсәсенә укырга керә.

Төмән педагогия техникумын тәмамлагач, Хәмит – Яркәй (Ярковский) районында. Башта ул – Нердинск волостеның Варвара (Варваринский), Кречетинский волостеның Карбан (Карбанский) тирмәләрендә уку өе мөдире булып эшли. Аннан, авыл Советы рәисе урынбасары вазифасында намус белән тырышып хезмәт итә. Яшь белгеч, бер үк вакытта, Свердловск шәһәрендә чыга торган «Сабан-чүкеч» газетасының штаттан тыш хәбәрчесе дә була.

Безнең талантлы якташыбыз аннан соң медтехникумда укыта, партия эшләрен алып бара. 1930 елда квалификациясен күтәрергә Казанга китә, һәм Казан педагогия институтына укырга керә. Фәнгә көчле омтылышы аңа, югары уку йортыннан соң, аспирантурада белем алу мөмкинлеге бирә.

Матбугат сүзенә һәм журналист һөнәренә булган ихтирамы аны башта Баулы район газетасы редакциясенә, аннан Республика газетасы «Кызыл Татарстан»га алып килә. Телләрне яхшы белгәнгә аңа В.И. Ленин, К.Маркс хезмәтләрен русчадан татарчага тәрҗемә итү бурычын йөклиләр. Хәмит Ярминең фикердәше, якын дусты күренекле язучы Шәйхи Маннур (1905–1980) була. Бу гаҗәеп сәләтле ике шәхеснең үзара дуслыгы ярты гасырны колачлый, ә аның нигезен Себернең татар дөньясына тирән мәхәббәт тәшкил итә.

Татар фәненә, татар фольклористикасын барлауга, туплауга чиксез өлеш керткән абруйлы шәхесләр саны аз түгел.

Галим-мәгърифәтче, тарихчы-этнограф, тел белгече, язучы Каюм Насыйри (1825–1902) туган якны, татар халкын, аның фольклорын һәм этнографик мирасын өйрәнүгә зур игътибар биргән. Ул татар авылларында үзе турыдан-туры материаллар туплаган, аларны жанрлар буенча классификацияләгән, татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарган.

Тел белгече, фольклорчы, профессор Хуҗа Бәдигый (1887–1940) 1914–18 елларда әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, бәетләрдән фольклор җыентыгы төзегән.

Шагыйрь Габдулла Тукай, язучылардан Галимҗан Ибраһимов белән Гали Рәхим дә фольклористикага теоритик яктан билгеле бер өлеш кертәләр.

Халык язучысы, фольклорчы-галим, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәкый Исәнбәт (1889–1992) 30 лап пьеса (шул исәптән фольклор персонажы Хуҗа Насретдин, тарихи персонаж Идегәй турында да) авторы. «Татар халык мәкальләре»нең өч томлыгы өчен ул 1968 елда ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 1984 елда «Балалар фольклоры» дигән китабын бастырып чыгарды.

Халык язучысы Гомәр Бәширов (1901–1999) та татар халкының рухи-әхлакый тәҗрибәсе белән тирәннән кызыксынган шәхес. Аның милли фольклорны туплау һәм өйрәнү өлкәсендәге күпьеллык эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Язучының халык юморын туплап, 1963 елда бастырып чыгарган, 1989 елда русчага тәрҗемә ителгән «Мең дә бер мәзәк» җыентыгы аңа аеруча зур популярлык китерә.

Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтев – татар фольклористикасы өлкәсендә, беренче булып, фәннәр кандидаты, аннан докторы дәрәҗәсенә ирешкән профессиональ рухтагы уникаль белгеч. Ул – кырык ел дәвамында татар халык авыз иҗатын эзлекле өйрәнү белән шөгыльләнгән галим.

Хәмит Ярмигә кадәр нигездә Казан татарлары фольклоры гына өйрәнелә. Ярми исә бу өлкәдә географик чикләрне киңәйтә, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдәге этнотөркемнәрнең авыз иҗатын барлап, аларны өйрәнүгә алына.

Хәмит Хөснетдин улы үзенең шәкертләре, хезмәттәшләре белән биш йөздән артык торак пунктка оештырылган утызлап фольклор экспедициясен җитәкли. Ул Татарстандагы һәр авылда диярлек була, СССРны аркылыга-буйга иңли, Рязаньга Касыйм татарлары янына бара, Нократ елгасы бассейнында яшәүче һәм Новосибирск, Омск, Төмәннең себер өлешендәге татарлар белән очраша, Идел буйлап Түбән Новгород, Самара, Ульяновск, Әстерхан якларына барып чыга, Мордовия, Удмуртия, Мари Эл татарлары яшәгән төбәкләрдә булып кайта.

Хәмит Ярми фольклористика тарихын борынгы чорыннан башлап өйрәнә. Россиядә һәм чит илләрдә XVIII–XIX гасырда басылып чыккан тарихи, этнографик, лингвистик хезмәтләрдән, хрестоматия, кульязмалар, юл язмаларыннан татар фольклорына кагылышлы уникаль текстлар, мәгълүматлар таба. Казан университеты, Фәннәр академиясе, фольклор өлкәсе белән шөгыльләнүче фәнни үзәкләр, җәмгыятьләр эшчәнлеген фәнни бәян итеп хезмәтләр яза. Ул, бигрәк тә, Каюм Насыйриның халык авыз иҗатына багышланган әсәрләрен югары бәяли.

Хәмит Ярминең иң яраткан жанрларының берсе – бәетләр була. КДУ доценты, язучы М. Мәһдиев бу хакта болай дип яза: «При упоминании специфического, присущего татарскому творчеству жанра “баит” перед глазами встает образ Хамита Ярми. Хамит Ярми, единственный из татарских ученых, кто так увлеченно уже тридцать лет собирает, изучает, преподносит нам народные баиты. В 1960 г. он выпустил книгу “Бэетлэр”, <...> буквально сме-

ло с книжных прилавков. У Ярми есть очень оригинальные суждения о жанре “баит”.

Ученый много труда вложил в теорию и историю изучения сказок, песен, пословиц, поговорок, загадок. Но научный мир ожидал от этого многогранного исследователя фундаментальный труд, обобщающую работу о жанровом своеобразии народного творчества. В 1967 г. такая работа появилась. Это была объемная монография “Поэтическое творчество татарского народа”, состоящая из 7 частей: “История сбора и изучения татарского фольклора”, “Сказки”, “Баиты”, “Пословицы и поговорки”, “Загадки”, “Песни”, “Татарский фольклор советского периода”».

М. Мәһдиев билгеләп үткән хезмәт нигезендә Х.Х. Ярми Алма-Атада үзенең докторлык диссертациясен яклый[1]. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, докторлык диссертациясенә кушымта рәвешендә ул халык авыз иҗатының иң яхшы үрнәкләрен дә китерә. Утырышны ачып җибәрүче диссертацион совет рәисе С.К. Кенесбаев: «Мондый зур галимнең безнең советта яклавы – безнең өчен зур горурлык», – дигән иде. Бу сүзләр Хәмит Ярминең төрки телле республикаларда гаять зур абруйлы булуы хакында сөйли.

Галимнең шәкертләре һәм аның фәнни мирасын өйрәнеп тикшерүчеләр, 1950 елларда ук инде Хәмит Ярминең тупланган фольклор хәзинәләреннән, һич югы, алты китап чыгарырга хыялलануын искә төшереп сөйлиләр. «Татар халык авыз иҗаты» сериясеннән, алты гына түгел, ә унике томлык басманың дөнья күрүе шушы титаник хезмәтнең башлап йөрүчесе, аның нигезен салучы, бик күпләрне шушы эшләргә рухландыручы галимгә зур дәрәҗә китерә – вафатыннан соң ул ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүлегенә лаек була. Бу серия әле дә дәвам итә: 13 нче том булып – «Балалар фольклоры, 14 нчесе – «Идегәй» дастанының академик басмасы нәшер ителә. Инде 15 нче том өстендә эш алып барыла, анда Г. Балинт, П. Паасонен, И. Кунош, В. Радлов, Х. Ярми кебек исеме дөньякүләм танылган галимнәрнең Себер, Уфа татарларыннан, мишәрләрдән төрле елларда язып алынган халык авыз иҗаты хәзинәләре урын алырга тиеш.

1932–1979 еллар арасында Хәмит Ярми йөзгә якын публицистик һәм фәнни мәкаләләрен бастыра. Ул күп кенә хезмәтләрен Г. Бәширов, А. Шамов, А. Әхмәтов, Х. Гатина, З.Сәйдәшева белән бергә, автордаш буларак иҗат итә. Аның өлеше кергән «Татар халык иҗаты» антологиясе, «Татар халык әкиятләре», «Халык җырлары», «Бәетләр», «Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре», «Татар-мишәр җырлары», татар фольклорының 12 томлык тупламасына кертелгән җәнлекләр турында әкиятләр һәм тылсымлы әкиятләр аеруча югары бәяләнәләр. Барлык томнарга да диярлек, кереш сүзне, искәрмәләрне, ноталы кушымталарны Хәмит Ярми үзе эшләгән. Галимнең китаплары рус, кытай, болгар, словен, венгр (маҗар), монгол, үзбәк, казакъ, төркмән, молдова телләренә тәрҗемә ителгән.

Фольклорда Г. Тукайның җитди ролен киңкырлы итеп яктырткан

хезмәт тә Хәмит Ярми каләме аша узган. Галим Г. Тукайның фольклорга карата булган теоретик карашларын, аның табигатен, тирәнтен мәгънәсен системага салган, аларны шәрехләгән, шагыйрьнең фольклор әсәрләрен үз иҗатында файдалану осталыгын аерым мисаллар белән дәлилләгән.

Хәмит Хөснетдин улы яшь галимнәр, фәнни оештыручылар әзерләүгә дә зур көч куя. 1939 елда Татар теле һәм әдәбияты фәннитикшеренү институты (1941 елдан – Татар тел, әдәбият һәм тарих институты) оештырылган көннән башлап, 1972 елда үзе лаеклы ялга киткәнчегә кадәр, Х. Ярми шушы Институтта. Институтның академик дәрәҗәгә күтәрелүе, СССР Фәннәр академиясе системасына кертелүе аның да гаять зур эшчәнлеге белән бәйле.

Казан дәүләт университетында татар бүлеге оештырылу да турыдан-туры күренекле галим Х.Х. Ярми катнашы белән тормышка аша. Ул анда күп еллар дәвамында халык авыз иҗаты буенча лекцияләр укый. Дистә меңләгән студентлар һәм мәктәп укучылары үз эшенең остасы булып танылган галим Х.Ярми тарафыннан язылган дәреслекләр аша татар халкының тылсымлы экият дөньясы белән танышалар. Х.Х. Ярминең биш аспиранты филологик фәннәр кандидаты дәрәҗәсен яулыйлар, шулардан икесе докторлык диссертациясе яклый.

Хәмит Ярми фәнне иң яхшы оештыручыларның берсе була. Ул, яшьләр үз коллегаларының эш тәҗрибәсе белән танышсын, материалларны ничек тупларга, дифференциацияләргә, сакларга икәнлекне алардан өйрәнсен өчен, үз дәреслекләрен Балтыйк буе республикаларына, Украинага, Санкт-Петербургка, Уфага җибәрә. Фольклорчыларны халыкның рухи байлыгын күз карасы кебек сакларга өйрәтә.

Хәмит Ярми иҗатын яктыртуга кырыктан артык мәкалә һәм рецензияләр язылган. Аларның авторлары – Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Нурихан Фәттах, Әбрар Кәримуллин, Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Илбарис Надиров һ.б. Бу авторларның һәркайсы галим эшчәнлегенә югары бәя бирәләр. Тик әле аларның берсе дә эшчән галим хезмәтләренең күләмен күренекле фольклорчының иң тырыш шәкерте Флора Ваһап кызы Әхмәтова-Урманче кебек үк күз алдына китерә алмагандыр.

Ф.В. Әхмәтова-Урманче раслаганча, Хәмит Ярми архивында аның өйрәнелмәгән рухи хәзинәләре, ачыклауны, өйрәнүне көткән иксезчиксез иҗади сәхифәләре саклана. Анда Х.Х. Ярминең эпистоляр язмалары: Б.Д. Греков, В.М. Жирмунский, А.Н. Кононов кебек академиклар, наширләр, мөхәррирләр, тәрҗемәчеләр, рецензентлар язган хатлар гына да ике меңнән артык берәмлекне эченә ала.

Хәмит Ярми – татар фольклорының алтын фондына зур өлеш керткән шәхес. Төмән дәүләт университеты галимнәре бөек якташларыбыз истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләсен күтәргәннәр иде. 2002 елда топонимика буенча шәһәр советы утырышында Төмән составына кушылган Казарово авылы тирәсендә барлыкка килгән яңа урамнар-

га исем бирү турындагы мәсьәлә күтәрелде. Анда Төмән шәһәре башлыгы С.М. Киричукның 2002 елның 26 июле 2490 нчы номерлы боерыгы белән татар фольклорының телпоэтик жанрын, фольклористика тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән (әйтеп үтелгәнчә, 1904 елда Казарово авылында туган) ТАССРның атказанган фән эшлеклесе хөрмәтенә «Хәмит Ярми урамы» дигән исем бирүне гамәлгә кертү бурычы куелды.

Төмәндә якташыбыз, фольклорчы галим Хәмит Ярми музей-кабинетын булдыру хакында галимнәр, музей хезмәткәрләре, туган якны өйрәнүчеләр әллә ничә мәртәбәләр үз фикерләрен җиткерделәр. Хәмит Ярминең тууына 100 ел тулган елны Төмәннең «Төзүче» мәдәният сараенда музей-кабинетны ачу тантанасы уздырылды.

Андагы материаллар нигезендә төбәгебездәге татарлар тормышын да өйрәнергә була. Үзенең биографиясендә Хәмит Ярми болай дип яза: «Рухани (дин әһеле) гаиләсендә тудым...» Музейда «1917 елга Казарово тирмәләренең метрика кенәгәләре» күчермәсе дә бар, аны галимнең әтисе – Хөснетдин хәзрәт үз кулы белән тутырган булган.

«Төзүче» мәдәният сарае экспозициясендә Төмән төбәгендә Совет хакимияте урнаштыру чорын чагылдырган төрле фотографияләр, документлар саклана. Гарәп, латин, аннан соң кирилл хәрефләре белән язылган мәкаләләр (1925–30 елларда Х. Ярми төрле мәгълүмәт чаралары белән хезмәттәшлек иткән) 1928, 1930 елларда алфавит алмашынуны раслый.

«Төзүче» мәдәният йорты экспедициясе уңышлы эшли: фольклорчы Х.Х. Ярмөхәммәтевкә багышлап экскурсияләр, дәресләр һәм башка чаралар уздырыла. Әмма галимнең тол калган хатыны Халидә Хәнәфи кызы Гатина-Ярмөхәммәтева коллекциянең музей таләпләренә җавап бирмәгән шартларда саклануына һәм күрсәтелүенә каршы килә, ул ябыла, ә андагы документлар өлкәнең крайны өйрәнү музеена тапшырыла. Халидә Гатина Төмәндә Хәмит Ярми музей-кабинеты ачылган очракта гына, музейга барлык биографик документларны бирәчәге турында белдерә. Төмән өлкәсендәге Татар конгрессы ярдәме белән Х. Гатинаның таләпләре үтәлә. Төмән өлкәсендәге крайны өйрәнү музее Хәмит Ярминең бөтен һәм тулы мемориаль коллекциясенә ия була. Хәзер мемориаль коллекцияне, шулай ук галимнең тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнү бара. Төмән өлкәсе Крайны өйрәнү музееның яңа комплексы – Бердәм край экспозициясен төзү проектлаштырыла, аның составында Х. Ярмигә багышланган кабинет-музей да булачак.

Әлеге музей экспозициясендә галимнең Казан чорына киң урын бирелгән. Аның документлары һәм фотографияләре, мәкаләләре һәм фәнни хезмәтләре сакланган. Алар белән танышканда гомерен татар фольклорына багышланган зур галимнең тормыш юлы күз алдыннан үтә сыман. Экспедицияләр оештырганы, аларда үзе дә катнашуы, материалларны эшкәртү белән шөгыльләнүе өчен, Хәмит Ярмине «ару-талуны белмәс галим» диләр. Беренче мәртәбә оештырылган

фольклор экспедициясе хакында Халидә Гатина болай дип искә ала: 1945 елда Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми һәм мин Буа районына фольклор экспедициясенә юнәлдек. Карлы (Мещеряково) авылында Гарифҗан исемле халык әкиятчесе, чичән абзый яшәве турында ишеткән идек инде. Без аны эзләп таптык. Сәламләшеп, хәл-әхвәлләрне сорашканнан соң, Ярми болай дип сүз башлады:

– Гарифҗан абзый, без Казаннан килдек, халык теленнән әкиятләр, бәетләр, җырлар җыябыз. Сезне бу өлкәдә иң оста кеше диләр...

Гарифҗан абзый аның фикерен бик тиз тотып алды һәм катгый итеп:

Мин бернинди дә әкият белмим, – диде.

Ярми, әйтерсең, аның бу сүзләрен ишетмәде, яңадан тегеләр-болар турында, уллары сугышта түгелме, дип сораштыруын дәвам итте... Сүз җайлы гына итеп тагын әкиятләргә күчте. Карт, киреләнүеннән туктамыйча, мин бернинди дә әкият белмим, башкалардан сорагыз, ди... Ярми үзе әкият сөйли башлады. Гарифҗан абзый башта чыраен сытып, тыныч кына тыңлап торды да, түзмәде, Ярмине бүлеп, әкиятне үзенчә сөйләргә тотынды ... Ярми миңа ым какты, һәм мин ул сөйләгәннәрне дәфтәремә терки башладым...

Хәмит Ярми бик күп бүләкләр һәм дәрәҗәләргә ия булган галим. Шулар арасында иң югарысы – Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге.

ИСКӘРМӘ

[1] Ярмухаметов Х.Х. Поэтическое творчество татарского народа: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Алма-Ата. 1969.

ӘДӘБИЯТ

Алишина Х.Ч. Объекты историко-культурного наследия сибирских татар Тюменской области // Словцовские чтения: материалы докл. и сообщ. XVI Всерос. науч.-практ. краевед. конф. Тюмень, 2004. Ч. 1. С. 68–70.

Әхмәтова-Урманче Ф.В. Заман һәм галим // Фән һәм тел. Казан. 2003. № 3.

Галиуллин Т. Себер мәгърифәтчесе // Мирас. 2004. № 4.

Гарифуллин И.Б. Личность Х. Ярми в контексте трансформации исламской культуры в Сибири // Сулеймановские чтения – 2004: материалы VII межрегион. науч.-практ. конф. / Тюм. гос. ун-т. Тюмень: Экспресс, 2004. С. 18–21.

Гатина Х. Истәлекләр китабыннан // Фән һәм тел. Казан. 2003. № 3.

Жизнь замечательных людей. Хамит Ярми (Күренекле шәхесләр. Хәмит Ярми). автор-составитель Х.Ч. Алишина. Тюмень: Печатник, 2014. 64 с.

Мәхмутов Х.Ш. Фольклорчыларның олуг остазы // Фән һәм тел. Казан. 2003. № 3.

Надиров И. Халык күңеленнән энҗе җыючы // Мәдәни җомга. Казан. 2004. 30 апрель, № 17.

Уразова Н.М. Хамит Ярми о влиянии фольклора на формирование татарской литературы: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск, 2008. 24 с.

Хамит Ярми. Ученый и личность: Статьи, воспоминания, письма. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 224 с.

***Алишина Хәнисә Чавдат кызы***, филология фәннәре докторы,
Төмән дәүләт университеты профессоры
e-mail: kaf_tatarlit@utmn.ru

УДК 811.512.145:93

# РЕПРЕССИЯ КОРБАНЫ, ТЕЛ ГАЛИМЕ АБДУЛЛА ШӘРИФОВ

*Али Хөсәен углы Шамил*
*(төрекчәдән Ф.И. Таһирова тәрҗемәсе)*

Статья посвящена краткому анализу биографии татарского языковеда Абдуллы Шерифова, внесшего серьёзный вклад в азербайджанскую науку и просвещение. Более подробно раскрывается период его жизни в Баку. Рассматриваются также некоторые обстоятельства трагической судьбы, связанные с его репрессией и смертью, приводятся некоторые исторические документы.

**Ключевые слова:** Абдулла Шарифов, грамматика тюрко-татарского языка, учебное пособие.

## Кереш

XX йөз башларына таба әсирлектә калган төрки халыклар Госманлы дәүләтенә коткаручыга караган кебек карый башлыйлар, зыялылар анда туплана, котылу юллары эзли. Беренче бөтендөнья сугышында Госманлы дәүләтенең җиңелүе һәм таркалуы бу вазгыятьне үзгәртә. Төрки халыкларның зыялылары, сәясәт һәм җәмәгать эшлекләре, бу әсирлектән котылу өчен, элекке Россия эчендә яңа үзәк булдырырга тырышалар.

Шундый мәркәзләренең берсе булып Баку үсә башлый. Аның мондый үзәккә әйләнүенең сәбәпләре дә була. Бай нефть чыганаклары, икътисади үсеш, патша Россиясе заманында шундый мәдәни мәркәзләр барлыкка килү, күпсанлы газета-журналлар басылу, Азәрбайҗан Республикасы чорында төрек теленең дәүләт теле дип игълан ителүе, бу телдә укыта торган мәктәпләр ачылу, яңа гына оешкан Төркия Республикасы белән тыгыз элемтәләр һ.б. сәбәпләр зыялылар, сәясәт һәм җәмәгать эшлекләре игътибарыннан читтә калмый. 1920 нче елларда элекке Россиядәге – большевиклар тарафыннан Советлар Союзы дип атаган илдәге төрки зыялыларның шактый өлеше Бакуга җыела һәм алар анда эшли, милли азатлык хәрәкәте оештыра башлыйлар.

Шул елларда Бакуга килүчеләр арасында татар зыялысы Абдулла Шәрифов та була.

### 1.1. Абдулла Шәрифовның нәселе һәм яшьлек еллары

Абдулла Шәрифовның тууына караган ике документ саклангaн:

Азәрбайҗан Милли Фәннәр академиясенең Президиумы архивындагы 39 фондта А.М. Шәрифовның шәхси эше (эшкә алуны сорап язган гаризасы, 1933 елның 15 февралендә

язган үтенече, берничә автобиографиясе, хезмәтләренең исемлеге һәм эш анкетасы) бар (АР МФА ПА, фонд 39);

Азәрбайҗан Республикасы Милли Куркынычсызлык комитеты архивындагы А.М. Шәрифовтан сорау алу беркетмәсе (АР МККА, № 10497).

Документларның икесендә дә аның 1893 елның ноябрендә Россиянең Оренбург губернасы, Троицк шәһәрендә дөньяга килүе әйтелә. Кызганычка каршы, туган көне берсендә дә күрсәтелми.

Беренче документтан билгеле булганча, чыгышы белән ул – Идел буе татарларыннан. Бабаларының яки әтисенең Уралга күчеп килүенең сәбәбен ачыклый алмадык. Абдулла, кечкенәрәк чагында, әтисе Мөхәммәд укыткан мәхәллә мәдрәсәсендә укыган. Соңрак, шәһәрдә җәдитчеләр ачкан рус-татар мәктәбенә керә. Беренче сыйныфны тәмамлагач, ягъни 1908 елда аны укырга Истанбулга җибәрәләр. Истанбулда кайда укыганын тәгаенли алмадык. Автобиографиясеннән аңлашылганча, Истанбулда җирле мөселман хәйрия җәмгыяте исәбенә урта мәктәптә укый һәм 1914 елда туган ягына кайта (АР МФА ПА, фонд 39).

### 1.2 Укытучы һәм журналист буларак беренче тәҗрибәләре

Үз иленә кайткан яшь Абдулла Троицкида укыта башлый. 1919 елның сентябреннән Анжерка бистәсендәге музыка мәктәбендә һәм Төмән шәһәрендәге беренче татар мәктәбендә укыта. Кыска гына вакыт эчендә бу төбәктә авторитет казана, газета-журналларга мәкаләләр яза. Большевикларның халыкларга – азатлык, крестьяннарга җир бирү, сугышны туктату, бердәмлек, 8 сәгатьлек эш көне турындагы лозунгларына бик ышана. Россия Коммунистлар (большевиклар) партиясенә керә.

Хәтта бу яктан күтәрелә дә. 1921 елның мартында Төмән губерна секретаренең милли мәсьәләләр буенча урынбасары итеп билгеләнә. Бу урында эшләгәндә Коммунистлар партиясе оештырган профсоюз курсларында укыта. Абдулла Шәрифов үзенең автобиографиясендә Коммунистлар партиясенә чын күңелдән бирелгән булуын яза (АР МФА ПА, фонд 39).

Кызганыч, бу хәзерге тикшерүчеләрне ышандырмый. Шулай да, коммунистларның Абдулла Шәрифов кебек яшь, белемле, энергияле кадрларга зур ихтыяҗы була торып, аны эш урыныннан Томск университетына укырга җибәрәләр. 1921 елның көзендә Томск университетының иҗтимагый белемнәр факультетына кабул ителә.

### 1.3. Абдулла Шәрифовның Бакуга китүенең сәбәпләре

Баку нефть үзәге булганга күрә, XIX йөздән үк дөньяның үсеш алган илләре бу төбәккә зур кызыксыну белән карыйлар. Яшь Советлар Союзы да Баку нефтеннән башка тора алмый. Монда эшчеләргә һәм квалификацияле белгечләргә ихтыяҗ зур була. Хөкүмәт Россиянең төрле якларыннан кадрлар җибәрә. Ул гына түгел, ачлыктан качып һәм эш эзләп килүчеләр дә күп була.

Абдулла Шәрифов 1923 елның июнендә Бакуга килә. Бу аның

беренче мәртәбә килүе буламы, яки элек тә килгәне булганмы – бу сорауларга документларда җавап таба алмадык. 1938 елда кулга алынганнан соң НКВД тикшерүчесенә биргән җавабында һәм автобиографиясендә Бакуга килүен Томскида университетның ябылуы белән аңлата. Кызганыч, аның бу җавабы да бик үк ышандырмый.

1. Ни өчен Абдулла Шәрифов Мәскәүдә, Ленинградта, Казанда һ.б. шәһәрләрдәге данлыклы университетларга түгел, ә яңа гына оешкан Азәрбайҗан Республикасының 1919 елда ачылган Азәрбайҗан дәүләт университетына килә?

2. Советлар Союзында мәктәп һәм университетларда уку сентябрьдә башлана. Абдулла Шәрифов исә Бакуга июнь аенда килә (Hüseyin oğlu, 2005, б. 462).

Абдулла Шәрифовның Бакудагы эшчәнлеген шул чордагы вакыйгалар белән чагыштырганнан соң түбәндәге фикергә килергә мөмкин: ул эзәрлекләүдән, җәзадан котылу өчен Томскидан һәм Оренбургтан ерак булган һәм игътибарны җәлеп итми торган бер җиргә китәргә карар кылган булса кирәк. КПСС тарихы белән якыннан таныш булган һәр галимгә билгеле булганча, Үзәк Комитетның күрсәтмәсе буенча партия сафларында берничә кат «чистарту» дигән исем астында үз фикере булган, халкының, милләтенең язмышы турында борчылган, хаксызлыкка ризасызлык белдергән шәхесләргә җәза бирү кампаниясе узды (Hüseyin oğlu, 2005, б. 463).

Абдулла Шәрифовның Бакудагы эшчәнлеге безгә шунлай фикерләргә нигез бирә: 1914–1919 елларда ул газета-журналларда милләтенең хокукларын яклап мәкаләләр язган, Төмәндә эшләү чорында анда яшәгән милли азчылыкларның хокукларын чикләүгә ризасызлык белдерүен әйтә алган. Абдулла Шәрифовның Бакуны сайлавы 1922–1923 еллардагы «чистарту»дан котылу өчен булырга тиеш.

Кызганыч, Абдулла Шәрифов НКВД игътибарыннан котыла алмый. 1928 елда Азәрбайҗанда ВКП(б) сафларында алып барылган «чистарту» нәтиҗәсендә, элекке эшчәнлеге өчен, ул партиядән чыгарыла. Яңадан партия әгъзасы була алмый (Hüseyin oğlu, 2005: 462 ).

## 2. Абдулла Шәрифов Бакуда

Абдулла Шәрифов 1923 елдан Азәрбайҗан дәүләт университетының Көнчыгыш факультетында укый башлый. Шул ук вакытта Коммунистлар партиясенең Азәрбайҗан Үзәк комитетының басма органы булган «Коммунист» газетасында эшли. Аның Бакуга килүе Азәрбайҗанда милли рухлы кешеләрне күпләп кулга алып, Соловки, Суздаль, Ярославль лагерьларына озату вакытына туры килә. Монда барлыкка килгән милли-иҗтимагый бушлыкны Кырымнан Бәкир Чобанзадә, Казаннан Газиз Гобәйдуллин (документларда исеме Азиз, фамилиясе Убайдуллин, Обайдуллин дип тә язылган – автор искәрмәсе), Ташкенттан Халид Сәид Хоҗаев, Томскидан Абдулла Шәрифов һәм башкаларның килүе берникадәр тутыра. Шундый милли җанлы зыялыларның һәм галимнәрнең җыелуы кыска вакыт эчендә Бакуны тюркологиянең көчле бер мәркәзенә әйләндерә.

Күп кенә милли рухлы, хаксызлыкка түзмәгән, изелгән халыкларны әсирлектән коткарырга теләгән кешеләр кебек үк, Абдулла Шәрифов та яшерен оешма әгъзасы була. Бу оешманың җитәкче үзәге итеп 1925 елда Сәмәрканд билгеләнә. Оешманың активистлары арасында РСФСРның Халык комиссарлары Советы рәисе урынбасары Рыскулов, РСФСРның Үзәк Башкарма Комитеты секретаре Шугу Әмирәсән, ВКП(б)ның Үзбәкстан Үзәк Комитеты секретаре Рәхимбаев, РСФСРның Халык мәгарифе комиссариаты комиссары Юманкулов, Дагстан АССРның Халык мәгарифе комиссариаты комиссары Тахо Годин, Карачай-Черкас АССРның Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Өмәр Алиев, Азәрбайҗан Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Солтанмәҗид Әфәндиев, ЗСФСР (Закавказье Совет Федератив Республикалары – автор искәрмәсе) Җир эшләре халык комиссариаты комиссары Дадаш Бүньядзадә, Азәрбайҗан Халык мәгарифе комиссариаты комиссары Мустафа Кулиев һәм башка тагын дистәләгән исемнәр атала. Россиянең колониясе булудан котылып, Бердәм Төрки-татар дәүләте төзергә теләгән бу оешмага Газиз Гобәйдуллин Абдулла Шәрифовны да җәлеп итә (Бүньядов, 1993, б. 92–94).

10–11 нче сыйныфлар өчен әзерләнгән «Азәрбайҗан теле» дәреслегендә аның турында болай язылган: «30 нчы елларда гомуми белем һәм урта профессиональ белем бирү мәктәпләре өчен берничә төрки телләр дәреслеге язылa. А. Шәрифовның төрки диалектологиягә һәм грамматика теориясенә караган кыйммәтле хезмәтләре бар» (Хаҗиев, Җәфәров, 2001: 57).

## 2.1. Абдулла Шәрифовның фәнни эшчәнлеге

Яшерен сәяси эшчәнлеккә кереп киткән Абдулла Шәрифов 1928 елда университетны тәмамлый һәм 1929 елның февралендә аспирантурага кабул ителә. Аспирантурада уку белән беррәттән, редактор булып һәм Азәрбайҗан педагогия институтының тел һәм әдәбият бүлегендә ассистент булып эшли. Үткен каләме, тирән белеме һәм эш сөючәнлеге белән кыска вакыт эчендә фән дөньясында таныла. 1932 елның сентябреннән югары уку йортында укыта башлый. 1933 елның 15 февралендә исә аны СССР Фәннәр академиясенең Азәрбайҗан филиалына эшкә чакыралар. Филиалның тарих, әдәбият һәм тел белеме бүлегендә эшләгәндә Азәрбайҗанның төрле районнарында экспедицияләрдә була. Экспедицияләр белән бергә, яшь белгечләр әзерләүгә зур игътибар бирә. Аның үз авторлыгында һәм Идрис Хәсәнов, Гуләм Багиров белән берлектә язган грамматикалары кабат-кабат басылып чыга һәм бу китаплар мәктәпләрдә һәм техникумнарда дәреслек буларак кулланылалар.

Шәхси эшендә Абдулла Шәрифовның түбәндәге фәнни хезмәтләре булуы күрсәтелә:

1. Төрки-татар телләренең сингармонизмы турында. «Азәрбайҗанны өйрәнү юлы» журналы. Баку, 1931, № 1–3

2. Төрек теленең грамматик категорияләрен классификацияләү принциплары турында. СССР ФА

Азәрбайҗан филиалы хезмәтләре. Тел һәм әдәбият сериясе. «Лингвист», 1936, № 1

3. Азәрбайҗан теленең Шамахы диалекты (Шамахы районына ике еллык экспедиция материаллары). Баку, 1935

4. Техникумнар өчен грамматика (Г. Багиров һәм И. Хәсәнов белән берлектә). I һәм II бүлек. Баку: «Азәрнәшр», 1932

5. Урта мәктәпләр өчен төрек теле грамматикасы (Идрис Хәсәнов белән берлектә). I һәм II бүлек. Баку: «Азәрнәшр», 1933

6. Төрек мәктәпләрендә рус телен укыту грамматикасы (чагыштыру методының нигезләре). Мәскәү: «Просвещение национальностей», 1935, № 1.

Абдулла Шәрифов «Төрек грамматикасының практик курсы» китабының тиз арада чыгачагын яза. Ул М.И. Меньшиковның «Яфетидология һәм марксизм», академик Маррның «Яфетидология һәм марксизм турында Баку бәхәсләре» китапларын азәрбайҗан теленә тәрҗемә итеп, редакцияләп, 1932 елда Бакуда бастыра.

1938 елда НКВД тикшерүчесенә Абдулла Шәрифов 22 китап авторы булуын әйтә (АР МККА, №10497). Кызганыч, бу китапларның бер өлеше 1937 ел репрессияләре дулкынында баткан. Аларны хәзер табып бастыру мөмкин түгел, дип санала.

### 2.2. Репрессияләнү сәбәпләре

Абдулла Шәрифовның яшь чагында Азәрбайҗан Педагогия Институтының тел һәм әдәбият бүлеге мөдире, Фәнни тикшеренү институтында бүлек мөдире булуы аны 1937 ел репрессияләреннән коткармый.

Хәтта 1932 елдан бирле эшләп килгән Институтта Азәрбайҗан Эчке эшләр Халык комиссариаты вәкиле булуы да кулга алынудан коткармый. 1937 елның 20 декабрендә, «Совет хөкүмәтенә каршы коралллы көрәш яклы булуда һәм фәнни фронтта корткычлык эше алып баруда» гаепләнеп, кулга алына (Бүньядов, 1993, б. 92).

1937 елның башларында ул эшләгән Тарих, тел һәм әдәбият институтының хезмәткәрләре Али Назим, Абдулла Мөхәммәт улы Тагызадә, Абдуләзәл Демирчизадә һ.б.лар, эштән чыгарылып, кулга алынгач, директор Альфред Рудольф улы Зифельд-Сумилягянның 1937 елның 20 мартындагы 21 нче номерлы боерыгы белән А.М. Шәрифов вакытлыча «Сүзлек-терминология бүлеге»нә билгеләнә һәм яртылаш төзелми калган «Азәрбайҗан теленең орфографик сүзлеге»н тәмамларга тиеш була. Өч айдан соң аның якын дусты, бергә китап язган Идрис Хәсәнов түбәндәге боерыкка кул куярга мәҗбүр була:

Боерык № 52

СССР Фәннәр академиясенең Азәрбайҗан филиалының Тарих, тел һәм әдәбият институты буенча

21 июнь, 1937 ел.

Бүгенге көннән Тарих, тел һәм әдәбият институтының баш гыйльми хезмәткәре А.М. Шәрифовны тел белеме секторының эшен бозуы, даими рәвештә эш планын үтәмәве, азәрбайҗан теленә китергән зыяны, халык дошманнарына (Чобанзадә, Хулуфлу, Сами Камальләргә һәм

аларның дәвамчылары Мөххәррәм Камильгә, Гуләм Багировка һ.б.га) ярдәм итүе өчен эштән чыгарырга.

Нигез: СССР Фәннәр академиясенең Азәрбайҗан филиалының 1937 елның 20 июненнән карары.

Имза: И. Хәсәнов,
СССР Фәннәр академиясенең
Азәрбайҗан филиалының Тарих,
тел һәм әдәбият институты
директоры.
(АР МФА ПА, фонд 39).

Күзгә ташланганы шул: өч ел элек ярым көчләп, ярым ялынып шул эшкә куелган кешене «тел белеме секторының эшен бозуда, даими рәвештә эш планын үтәмәүдә, азәрбайҗан теленә зыян китерүдә» гаеплиләр. НКВД тикшерүчесенең гаепләве дә шул боерыктагы кебек үк.

Бөтен тармакларны җитди күзәтү астында тоткан махсус органнар югары уку йортларына, фәнни-тикшеренү үзәкләренә, газета-журналларга аеруча игътибарлы булалар. Мондый урыннарда, җитәкчеләрне билгеләүне күзәтү белән бергә, үзара бер-берсен белмәгән берничә хәбәр итеп торучы вәкил дә эшләгән.

НКВД тикшерүчеләренең иң нык ачуын китергән нәрсә шул була: Абдулла Шәрифов үзе эшләгән институтта Азәрбайҗан Эчке эшләр комиссариаты вәкиле була торып, эшен җиренә җиткереп үтәмәгән. 1937 елның 20 декабрендә кулга алынганда аңа иптәшләренең гаепләре дә өстәлә: «Азәрбайҗан Совет Социалистик Республикасы Эчке эшләр комиссариаты вәкиле була торып, контрреволюцион оешма әгъзасы булган» (Буньядов, 1993, б. 92).

Күзгә ташланганы шул: А. Шәрифов үзе әгъза булган оешмага матур тормыш, җиңел яшәеш вәгъдә итеп түгел, йөрәге кушканга, иртәгәгә өмет баглап, яшерен эшчәнлек алып барган милләтче оешмага әгъзалар җәлеп итә. 1938 елның 13–14 февралендә үткәрелгән икенче сорау алу вакытында тикшерүчегә болай җавап бирә: «1934–1936 елларда контрреволюцион милләтче оешмага мин шундый кешеләрне җәлеп иттем: 1933 елның апрелендә Тарих, тел һәм әдәбият институтының директоры вазифаларын башкарган Идрис Хәсәнов һәм 1934 елда СССР Фәннәр академиясенең азәрбайҗан филиалының аспиранты Алекбер Бабазадәне. Аларга шундый эшләр йөкләдем:

1. Үзләренең фәнни-теоретик һәм практик эшчәнлегендә, әсәрләрендә һәм дәреслекләрендә пантюркизм һәм милләтчелек идеяләрен үткәрергә.

2. Студентлар арасында буржуаз-милләтчел әдәбият тарату, аларны пантюркизм рухында һәм Совет хөкүмәтенә каршы рухта тәрбияләү» (Буньядов, 1993, б. 93).

Озак еллар дәвамында тикшеренүчеләр «1937 елда кулга алынган кешеләр, авыр шартларда, үзләре теләгәнне түгел, тикшерүчеләр кушканнарны сөйләгәннәр» дип яздылар. Минем фикеремчә, барлык күрсәтмәләрне дә мондый шик астына алу өчен нигез юк. Тикшерүченең «милли көрәш оешмасына якын булган танышларыгызның фамилияләрен атагыз» дигән таләбенә җавапта Абдулла Шәрифов Бәкир Чобанзадә, Газиз Гобәйдуллин, Абдулла Тагызадә, Хәнәфи

Зәйналлы, Гуләм Багиров, Идрис Хәсәнов, Давут Кулиев, Халид Сәид Хоҗаев, Альфред Зифельд, Зиннәт Закиров фамилияләрен китерә. Тикшерүче аннан кемнәрне үзе җәлеп итү турында сорагач, якын дусты Идрис Хәсәновны һәм Алекбер Бабазадәне атый (Hüseyin oğlu, 2005, б. 463).

Исемнәре аталган кешеләр бернинди яшерен оешма әгъзалары булмаганнар, кулга алынган кешеләрне аларга күрсәтергә мәҗбүр иткәннәр, дигән фикергә ышансак, мондый бер сорау туа: «Ни өчен Абдулла Шәрифов үзе белән бергә дәреслек язган Гуләм Багиров исемен түгел, ә дусты Идрис Хәсәновның исемен атый? Гуләм Багиров белән аларны тыгызрак хезмәттәшлек берләштерә бит. Аның фамилиясен атау ышандыра төшәр иде.

Икенчедән, тикшерүче ничә мәртәбә аны шпионлыкта гаепләсә дә, ул моны танымый.

Без кулга алынучыларның авыр шартларда яшәвен, аларга карата мөмкин булмаган җәзалар кулланылуын, төрле әхлакый һәм психологик басым ясалуын бөтенләй танымыйбыз түгел. Шул ук вакытта сөйләнгәннәрнең барысын да шик астына алу белән дә килешә алмыйбыз. Башка чыганаклар да кулга алынучыларның күп кенә күрсәтмәләрен раслый.

1936–38 елларда кулга алынган һәм атылганнар бер нинди дә эш алып бармаганнар, гаепсез булганнар, дип язган галимнәр, чынлыкта милләте һәм ватаны өчен көрәшкән кешеләрнең якты истәлегенә күләгә төшерәләр. Моны Абдулла Шәрифовның 1938 елның 19 февралендәге сорау алуда биргән җаваплары да ачык күрсәтә. Ул, бу авыр тоткынлык аны юкка чыгарачагын белә торып, шуңа карамастан, кыю рәвештә шуларны әйтә:

«1. 1918 елдан кулга алынган көнгә кадәр контрреволюцион милләтчел пантюркизм тарафдары булдым.

2. 1920 елдан 1938 елга кадәр ВКП(б) сафларында булып та үземнең контрреволюцион карашларымны партиядән яшерә килдем.

3. 1928 елның сентябреннән пантюркистик милләтчел оешма әгъзасы Гобәйдуллин белән тыгыз бәйләнештә булдым.

4. Совет хөкүмәтенә каршы кораллы чыгыш әзерләү һәм Бәйсез Төрки-Татар дәүләте төзү турындагы контрреволюцион пантюркистик оешма идеяләре белән тулысынча килешә идем.

5. 1930 елдан башлап, Гобәйдуллин күрсәтүе белән югары уку йортлары студентлары һәм СССР Фәннәр академиясенең Азәрбайҗан филиалының фәнни хезмәткәрләре арасында контрреволюцион пантюркистик пропаганда җәелдердем.

6. 1933–34 елларда контрреволюцион оешмага җәлеп иткән кешеләр арасында институт галимнәре Идрис Хәсәнов һәм Алекбер Бабазадә була.

7. 1932 елдан башлап кулга алынган көнгә кадәр, Азәрбайҗан ССРның Эчке эшләр комиссариаты вәкиле булганым хәлдә, контрреволюцион пантюркистик оешмага кердем. Моны Азәрбайҗан ССРның НКВД органнарыннан яшердем» (Бүньядов, 1993, б. 93, Бабаев, 2003, б. 179).

НКВД тикшерүчеләре бу күрсәтүләр белән генә канәгатьләнми. А. Шәрифовны шпионлыкта да гаеплиләр. 1938 елның 8 мартындагы дүртенче сорау алу вакытында аны ни кадәр җәзаласалар да, ул шпионлыктагы гаебен танымый. Контрреволюцион милләтчел оешма әгъзасы булуын тикшергәндә сорауларга җавап биргән, ләкин шпионлыкта гаепләүне танымаган Абдулла Шәрифовның эше буенча сорау алулар 9 мартта тәмамланган санала һәм аны, Азербайҗан ССРның 64, 69 һәм 70, 73 маддәләрендә каралган җинаятьләрдә гаепле, дигән карар чыгарыла (Бүньядов, 1993, б. 94, Бабаев, 2003, б. 180).

Азәрбайҗан ССРның Югары Суды хәрби коллегиясенең 1938 елның 3 июлендә 18.15 сәгатьтә башланган ябык утырышы 18 сәгать 25 минутта тәмамлана да (10 минут эчендә галимнең язмышы хәл ителә) һәм Абдулла Мөхәммәд улы Шәрифов иң авыр җәзага – атып үтерүгә хөкем ителә. 10497 номерлы тикшерү эшенә хөкемнең шунда ук үтәлүе – 1938 елның 3 июлендә атылуы турындагы документ өстәлгән (Бүньядов, 1993, б. 94, Бабаев, 2003, б. 180).

**Нәтиҗә**

Абдулла Шәрифовны атканнан соң хатыны Фатыйма Зиннур кызы Шәрифова халык дошманының гаилә әгъзасы буларак 8 елга төрмәгә ябыла (Бабаев, 2003, б. 181). Аның хатынының, балаларының язмышы турында бернинди мәгълүмат таба алмадык. Хәлбуки Азәрбайҗан Республикасы Милли Фәннәр академиясенең Президиумы архивында сакланган шәхси эшендә А.М. Шәрифовның җаваплылыгында биш гаилә әгъзасы булуы язылган.

Милли хокукларны яклау идеяләре өчен көрәш алып барган һәм бу юлда җанын кызганмаган шәхесләр ихтирамга лаеклы. Заман үзенең хөкемен чыгара. Халык, соң булса да, дөреслекне белә, каһарман балаларын ярата, аларның истәлекләрен хөрмәт итә. СССРның таралуы, халыкларның үз үткәнен белергә теләве, милләтләрнең үз хакларын даулавы Абдулла Шәрифовның һәм мәсләктәшләренең хаклы булуын күрсәтә.

1938 елның 3 июлендә Бакуда атылган А.М. Шәрифовның хатыны Фатыйма Зиннур кызы Шәрифованың СССРның баш судьясы Руденкога язылган үтеначе СССР Югары Судының хәрби коллегиясендә карала. Ул шуның нигезендә 1957 елның 30 маенда аклана (Бабаев, 2003, б. 181).

КПССның хөкүмәтнең бөтен кимчелекләре И.В. Сталин исеме белән бәйләнгән XX съездыннан соң төрмәгә ябылган, сөргенгә җибәрелгән һәм атылган меңләгән кешеләр реабилитацияләнә. Асылында бу – үтерелгән яки үлем хәленә җиткерелгән кешеләрне физик яктан гына аклау була. Аларның көрәш максаты, идеяләре, бу юлдагы хезмәтләре акланмый кала. Шуңа күрә бик күпләрнең иҗади эшчәнлекләре, җитди тикшерелеп, халыкка җиткерелмәде, әсәрләре кыскартылмалар белән басыла килде. Аларның идеяләре һәм әсәрләре чынлап аклауны Советлар Союзы таркалганнан соң гына күрде.

## ӘДӘБИЯТ

А.М. Шәрифовның шәхси эше //Азәрбайҗан Республикасы Милли Фәннәр академиясенең Президиумы архивы, фонд 39.

Абдулла Мөхәммәд улы Шәрифовның 10497 номерлы эше // Азәрбайҗан Республикасы Милли Куркынычсызлык комитеты архивы.

Азәрбайҗанны өйрәнү юлы. 1931. №1–3.

Бабаев Адил Мөхәммәд углы. Илебез һәм фәнебез геноциды. Баку: Баку университеты нәшрияты, 2003. Беренче китап.

Бүньядов З. Кызыл террор. Баку: Азәрбайҗан дәүләт нәшрияты, 1993.

СССР ФА Азәрбайҗан филиалы хезмәтләре. Тел һәм әдәбият сериясе // Лингвист. 1936. № 1.

Хаҗиев Т., Җәфәров Н. Азәрбайҗан теле. Икенче басма. Баку: Tahsil, 2001.

Hüseyin oğlu Ali Şamil. Dilci araştırıcı Abdulla Şərifovun mubariz ömrü // Урал–Алтай: через века в будущее: материалы Всероссийской научной конференции, г. Уфа, 1–5 июня 2005 г. Уфа: Gilem, 2005.

Техникумнар өчен грамматика (Г. Багиров һәм И. Хәсәнов белән берлектә). I һәм II бүлек. Баку: Азәрнәшр, 1932.

Шәрифов А. Азәрбайҗан теленең Шамахы диалекты (Шамахы районына ике еллык экспедиция материаллары). Баку. 1935.

Шәрифов А. Урта мәктәпләр өчен төрек теле грамматикасы. I һәм II бүлек. Баку: Азәрнәшр, 1933.

***Али Хөсәен углы Шамил***, Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясе Фольклор институтының халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире

УДК 811.512.145'282

# ЕРАКТАГЫ ЯКЫН КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ
## Әстерхан якларына галимнәр сәфәре

*М.Р. Булатова*

В статье дана краткая этнолингвистическая характеристика говору татар Астраханской области в сравнении с другими говорами татарского языка и татарским литературным языком. Прилагаются образцы речи по данному говору, содержащие языковые особенности и лексические материалы (названия одежды, пищи, обрядов и т.д.).

**Ключевые слова:** комплексная экспедиция, диалектология, астраханский говор, юртовский подговор, грамматические и лексические особенности.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, дөньяда татарларның телен, әдәбиятын, халык иҗатын, музыкаль һәм тасвирый сәнгатен югары фән дәрәҗәсендә өйрәнә торган гыйльми-тикшерену үзәге буларак, милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә диалектология, фольклор, сәнгать, археография, эпиграфияне өйрәнүче берләштерелгән экспедицияләр оештыра. 75 еллык эшчәнлеге дәвамында Институт татар халкының рухи һәм милли-мәдәни мирасын туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирә. Соңгы вакытларда ел саен татарлар яши торган 2–3 төбәккә шундый экспедицияләр уздыру традициягә әйләнеп китте. Актаныш (2009), Түбән Новгород, Курган, Апас, Стәрлебаш (Башкортстан), Оренбург (2010), Кукмара, Бәрәңге (Мари Эл) (2011), Чүпрәле, Удмуртия Республикасы (2012), Мамадыш, Барда (Пермь крае) (2013) төбәкләренә оештырылган гыйльми сәфәр материаллары «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә аерым китаплар булып басыла килә.

2013 елның 10–21 июнендә без Институтның бер төркем галимнәре белән Әстерхан өлкәсендә – Идел буе районындагы Киләче (Килинчи), Җәмәле (Три Протока), Ярлы Түбә (Осыпной Бугор), Кызан (Татарская Башмаковка), Мәйле Күл (Яксатово), Каргалык (Карагали) һәм Нариман районындагы Каңга (Кучергановка) авылларында булдык. Бу комплекслы экспедицияләрдә милләттәшләребезнең көнкүреш йолаларын, җирле сөйләш һ.б. үзенчәлекләрен өйрәнеп, анализлау максаты куелган иде.

Татар тел белемендә әстерхан татарлары сөйләше узган гасырның 70нче елларында Л.Ш. Арсланов тарафыннан өйрәнелгән, аның күпсанлы мәкаләләре һәм монографиясе дөнья

күргән. Л.Ш. Арсланов юрт урынчылыгын әстерхан сөйләшенең үзәк урынчылыгы дип саный, аларның башка урынчылыкларга йогынтысын өйрәнүгә зур урын бирә [Арсланов, 1976; Арсланов 1978, б. 107–109].

Әстерхан сөйләшенең гореф-гадәт үзенчәлекләрен, йолаларын Ф.С. Баязитова да өйрәнә, аның 2002 елда «Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор» исемле китабы дөнья күрде.

Әстерханлылар безне милли киемнәрен киеп, җырлап-биеп каршы алдылар, тамаша да күрсәттеләр. Алар безгә үз җирләренә хас булган йолаларны, гореф-гадәтләрен, авыллары тарихын, яшәешен сөйләделәр, шул чакта без аларның тел үзенчәлекләренә дә игътибар иттек. Эш барышында информантларыбыздан күп кенә җырлар, такмаклар, бәетләр җыйналды. Бик үзенчәлекле ике туй күренешен дә карадык. Әйтеп узган авыллар буенча тупланган материал әстерхан татарларының халык авыз иҗатына бай булуын, аларның сөйләше урта диалектка (әстерхан сөйләшенең юрт урынчылыгына) каравын тагын бер кабат раслады.

Төп фонетик үзенчәлекләргә мисал итеп түбәндәгеләрне әйтеп китү мөһим: ***а*** – иренләшмәгән ачык аваз: *канат* – әд. ка°нат; авазлар тәңгәллеге: кайбер сүзләрдә [ә] сузыгы әдәби телдәге [а] авазы урынына әйтелә (***ә~а):*** *әрзән* – әд. арзан, *йәүче* – йаучы; ***и~ә***: *тирәзә* – тәрәзә, *йөрә* – йөри; ***әй//ай~ и//ый:*** *әпәй* – ипи, *атай* – эти, *бармай* – бармый; ***ый~и:*** *мый* – ми (баш мие); ***о~у:*** *олы* – улы, *орлый* – урлый; ***ү~ө:*** *үлкүн/өлкүн* – өлкән, *сүлим* – сөйлим; ***ы~о:*** *мырын* – борын; ***й~җ:*** *йете* – җиде, *йебәр* – җибәр; ***ш~ч:*** *шитән* – читән, *шығару* – чыгару, *ошут* (<очередь) – чират; ***п~б:*** *йапалаķ* – ябалак; ***м~б:*** *мәлеш* – бәлеш, *киләмез* – киләбез һ.б.

Грамматик аерымлыклардан *й, м, л, р, з* тартыкларына тәмамланган сүзләрнең иялек, төшем килешләрендә, тартым кушымчаларындагы үзенчәлекләрен күрсәтеп үтәргә була. Мәсәлән, *-ды/-де* ~ *-ны/-не* (*өйемде* – әд. өйемне), *-дын/-ден* ~ *-ның/-нең* (*ķыздын* – кызның), *-дан/-дән* ~ *-нан/-нән* (*ķахамдан* – кахамнан); *с, ш, т, к, п* тартыкларына беткән сүзләргә *-тын/-тен, -тан/-тән, -ты/-те* (*ķабаķты* – кабакны) кушымчалары ялгана.

Җыю саннарында *-ны/-не* кушымчасы төшеп калу очраклары: *Икәү* (икене) *эчәргә кирәк, улым берәү* (берне) *эчте.*

*-нчы/-нче* кушымчаларының кайбер сүзләрдә әйтелмәве*: Сәгәт алты* (алтынчы) *йарты, бер йарты* (беренче ярты).

*-дый/-дий* кушымчалы чагыштыру рәвешләре очрый: *Монда сез бездийләр* (безнең кебекләр) *белән утырсағыз, иртәнгә дә ķалырсыз.*

Сөйләштә *-лай/-ләй, -лый/-лий* кушымчалар ярдәмендә ясалган рәвешләр дә бик актив: *Эсселәй* (<эссе көе – әд. кайнар көе) *чәй эчеңез. Эссе көе* мәгънәсендә куллану Башкортстан һәм Себер ягы татар сөйләшләренә дә хас.

Алмашлыкларның составы һәм әйтелеше ягыннан әстерхан сөйләше татар әдәби теленнән аз аерыла. Юнәлеш килешендәге I, II, III зат алмашлыкларының күп төрле

вариантлары күзәтелә: *мага / миган / маған / миңан* – миңа; *саға / саған / сиған / синга* – сиңа; *уға / уғар/ уган / унаған / анарга*: Мәсәлән: 1. *Маға* (миңа) *әйем* (дәү әни, әби) *йаулық бирде*. 2. *Шықма, қайда барасын, нәрсә бар сиған* (сиңа) *анда?* 3. *Әйтәләрде өй ийәсенә қайада торма кирәк, шуға уға* (аңа) *шарлақ кирәк, мансарда.*

Сөйләмдә *зат* сүзе еш кулланыла: *Ни зат ул?* – әд. Нәрсә йә кем ул. *Ни зат итә? Ни зат итәде?* – Нәрсә эшли? *Уға бер зат* (кеше) *килә. Халаттай булған зат* (кием) *ул. Әтисе бикләп қуйған бер затқа* (урынга). *Затларын* (әйберләрен) *салып йибәрткән ағызып. Йортларда бер зат* (нәрсә) *та йуғ иде, сәке, булса инде, әзерәк түшәкләр.*

Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат күплек сан формасы *-мес/-мыз* варианттагы кушымча ярдәмендә ясала: *Қоранға* (Коръән ашына) *барамызмы* (әд. барабызмы)? *Бәйетләр сөйләймес* (сөйлибез).

III зат берлек сандагы фигыльләргә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчасы ялгану очраклары күп: *Внучқамыз йома көнне последний экзамен бирәде* (әд. бирә), *юридическийда уқыйды* (укый), *кийәүгә шықты, уқуwын да бетерәде* (бетерә), *Алла бирса. Аурады* (авырый), *йөрә бирде* (йөри бирә) *ақсап.*

Боерык фигыльнең II зат күплек саны *-ң//-ныз//-ңыз* (әд. *-гыз*) кушымчалары ярдәмендә ясала: *Кеше йазғанда туқтап торыныз* (торыгыз), *сули бирмәнез* (сөйләмәгез). *Ойалып утырмаңыз. Сөйләң* (сөйләгез).

Хикәя һәм теләк фигыльләрдә *-ай/-әй* кушымчасы әдәби вариант белән параллель кулланыла: *-ай//-әй ~ -ый//-и/ий, -айым//-әйем ~ -ыйм// -им: Башын савуға бару йоласында ақчаны қағызға салалар да өстәлгә қуйалар, қулға бирергә йарамай* (ярамый). *Бер зат* (беркем) *та қалмай* (калмый). *Нәсел ағачларын сөйләйем* (сөйлим әле). *Қунсымды* (күршемне) *кереп күрәйем* (күрим).

Фигыльләрдә *-ай//-әй* аффиксы урта диалектның касыйм, нократ, эчкен, минзәлә сөйләшләрендә, бигрәк тә Башкортстандагы бәләбәй урынчылыгында, кормантау, тепекәй, златоуст, бөре һәм учалы сөйләшләрендә киң таралган. Билгеле булганча, ул шулай ук көнчыгыш диалектка да хас күренеш.

Инфинитивның *-ма/-мә, -мага/ -мәгә* формалары кулланыла: *Қоран* (коръән) *ашынын ризығын көттермә* (көттерергә) *йарамыйды. Йыл да уқымаға* (укырга) *ақча бирә торған идек.*

Тезмә сыйфат фигыльләрдә кыскартылган вариант куллану (*-а, -ә* кушымчалы хәл фигыльгә *торган* ярдәмче фигыле кушылып ясалу) үзенчәлегә хас: *Қойынадан* (әд. коена < юына торган) *җирем* (урыным) *бар.*

Сирәк булса да *қу//қуй* (әд. ич, бит) кисәкчәләре очрый*: йуқ қу* – юк бит.

Л е к с и к үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне атап үтәргә була: т о р м ы ш - к ө н к ү р е ш б е л ә н б ә й л е с ү з л ә р : *ағач* – әд. утын, койма, *ашар* – ачкыч, *атқушар* – исем туе, *әпәй* – икмәк, *әүлә* – ишек алды, *бабай түбә* – зират, *бағай* – келәшчә, *балға* – чүкеч, *бидрә* – чиләк, *бирчәчкә* – агач тәлинкә, *дәрмән* – дару, *зыпын / запун* – алъяпкыч, *ишек* һәм *тәрәзә йөзлөкләре* –

тәрәзә пәрдәләре һәм ишек шаршаулары, *йаглау* – чүмеч, *йастық* – мендәр, *қайық* – көймә, *көйәз / кийәз* – сый, сыйлы, *қанжага* – ат ияре, *керт / қыпыл* – йозак, *кийит / кийет* – бүләк, *қыйқым* – чүп, *қуймалақ* – кечкенә бидрә, бидон, *күрпә* – матрац, *күсәнкә* – кисәү, агачы *қырққабат* – кырыккарта, *ләлмик / ләлм(б)әк* – чынаяк тәлинкәсе, *манит* – акча санау берәмлеге, сум, тәңкә, *матқап* – каргаборын (рус. плоскогубцы), *нәлмәк* – тәлинкә, *пийала* – күзге, *спичкә* – шырпы, *суй* – нәсел, *суwагаш* – көянтә, *сырдақ* – урындык өстенә куя торган җәймә, *тақтамбит* – сәке, *тәрәтқанә* – бәдрәф, *тастархан* – ашъяулык, *типкер / кипкер* – тишекле кашык, *тирәк* – агач, *төнәген* – кичә, *тустақай* – чүмеч, *ушақ* – кечкенә мич, *чапрач / шапраш* – баскыч, *чилтәк* – тишекле чүмеч, сөзгеч, *шешә* – пыяла, *ширәкә* – чынаяк, *шиққарын* – малның эчәк-бавыры.

Аш-су: *дура(ж)ш* (< дрожжи) – эд. чүпрә, *қабақ бүрәк* – кабак эчле бөккән, *қазан бүрәк* – казанда майда пешерелгән бөккән, *қамыраш* – токмач, *лаксалба* – баллы бавырсак, чәкчәк, *пәхлава* – баллы, чикләвекле бөккән, *шурпа* – аш.

Кием-салым һәм бизәнү әйберләре: *бәрек* – бияләй, *сырга* – алка, *сенәпит* – җиңсез җылы сырган кофта душегрейка), *күләк* – күлмәк, *мата* (< материал) – тукыма.

Үсемлек, хайван һәм кош-корт атамалары: *алматирәк* – әд. алмагач, *байтирәк* – тополь, *батраш / патраш* – бөтнек, *бәлдүгән* – шөпшә, *картуф / кәртуп* (< картофель) – бәрәңге, *мадур* – помидор, *мәркү* (< морковь) – кишер, *шыбыт* – укроп, *кәчек / кәшек* – көчек, эт, *қураз* – әтәч, *мышық* – мәче, *тәwә* – дөя, *қасқыр* – бүре.

Эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр: *имбәкләү* – әд. мүкәләү, *утны йагу* – утны кабызу, *утны тымызу* – сүндерү, (*телевизор) салу* – карау, кабызу, *чәпәнәй қагу* – әд. кул чабу, *қул алу* – көрешү, *қыйрау* – җимерелү, сыну, *күмәг иту* – ярдәмләшү, *қыдырмага* – йөрергә, *утерек сөйләү* – ялган, алдап сөйләү, *сукешу* – әрләшү, *анап утыру* – саклап утыру, *ыстау* – тоту, *азарлау* – тиргәп сөйләү, *суга төшу* – су коену, *мучага төшу* – мунча керү, *чигу* – (тәмәке) тарту.

Затларны белдерә торган сүзләр: Әстерхан татарларында гадәттә үзеннән бер яшькә зур булган апа, абыйга үз исемен әйтергә ярамый. Ир белән хатын да бер-берсенә исемнәре белән түгел, ә *әтисе*, *әнисе* дип кенә эндәшкәннәр.

Әтисенең әнисенә – *әйем*, әтисенең әтисенә – *атам*, әтисенең агасына – *муллам*, әтисенең апасына – *атайбикәм*, әтисенең сеңлесенә *апақтәтәм* дип әйтәләр.

Әнисенең әтисенә – *бабам*, әнисенең әнисенә – *мамам*, әнисенең энесенә – *кахам*, әнисенең сеңлесенә – *тәтәм*, әнисенең апасына *қайтим* дип эндәшәләр. Алар икәү булсалар *өлкән*, *кечкенә* сүзе кушыла. Аларның дусларына *дус* сүзе өстәп әйтелә: *дус әйем*, *дус атам*, *дус қахам*, *дус тәтәм*. Әнисенең ике-өч абыйсы булса: *өлкән қахам, кечкенә қахам, биби қахам* дияләр.

Ир кешесенең абыйсы – *қайнага*, хатыны – *абсын*, килене – *кешәк / кишәк.*

Әгәр гаиләдә балалар күп булса, *ак, бал, шикәр, өлкән, кечкенә, биби* сүзләре кушыла: *актәтәм, балтәтәм* һ.б.

Килен кеше иренең туганнарына ире ничек эндәшсә, шулай эндәшергә тиеш. Зурлар үзеннән бер яшькә генә кечкенә булса да, сеңлесенә – *сәулим*, энесенә *мырзам* дип дәшә. Өйдә ике килен булса, кечкенәсе зурысын *тәтәм* дип йөртә; икесе бер яшьтә булсалар – *ахирәт, сөйәрем, сөйеклем, кадерлем, гүзәлем, аппагым*. Мондый сүзләр белән эндәшкәндә беркайчан да талашырга ярамаган.

Күршеләргә дә исемен әйтмиләр: *кунсы // күрше // куншы*. Балалар өчен алар – *куншы атам, куншы әйем, куншы тәтәм* һ.б. Әгәр капкалары кара-каршы булса, *кап-калач* дип әйтелә. Ә балалар *капкалач* сүзен кушып эндәшкән.

Туганнарга, күршеләргә исеме белән әйтү әдәпсезлек саналган.

Үзеңнән бер яшькә олырак кешегә исемен әйтеп җибәрсәң, ул «тәрбиясез, син туганда мин куанган идем, ә син исемне әйтәсең», – дип кисәтү ясаган.

Дус кызлар бер-берсенә *айырылмас, былбылым, туганым, кардәшем, дусым, күбәләгем, күгәрченем, сандугачым, алтыным, ахирәт* дип дәшкәннәр һәм чәнти бармакларын бөгеп чалмаштырып ахирәт дуслыгына кушылганнар. Элек, хәтта XX гасыр башында да дус туен ясап «дус кушылдырганнар». Бер-берсенә истәлеккә зур затлы әйберләр бүләк иткәннәр. Дус, ахирәт булып кушылганнар, алар ахирәткәчә аерылырга тиеш булмаганнар.

Кешене тасвирлый торган һ.б. сүзләр: *ататут* – эд. әрсез, үткен, *асау* – усал, *байгыш// кәреп* – мескен, ярлы, *исле* – карт, *йатсыз//битсез* – оятсыз, *җисер* – тол хатын, *зылым* – усал, явыз, *кыйшык* – кыек, *кыркылдак* – тәртипсезлек, *маштак//кечкентәй* – кыска буйлы, бәләкәй, кечкенә, *спайы// күркәм* – матур, *сыпат* – кыяфәт, *суатак* – сукбай, *супак* – озын, *улкүн//өлкүн* – зур (предметка карата да әйтелә), *утерекче* – ялганчы; *алыс* – ерак, *бит* – як (< сторона), *йаз башы* – яз, *йаз* – җәй (< лето), *сәрен* – салкынча.

Әстерхан татарларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б.лар сөйләү үрнәкләрендә аеруча тәэсирле яңгырый.

***Пылау пешерү.*** Сәгәт дүрттән чыгам, казанга ут йагып җибәрәм. Сәгәттән артык су кайнайды. Бүwертеп аласын дөгөде, аны табакларга салып, аннан сон инде казанды киредән йуwып, май койоп. Бер кило дөгөгә өч йөз грамм сармай (эд. *атланмай*) китәде. 20 кило дөгө булса, 5 кило суган – туралган, киселгән – и биш кило мәркү, ике кило дубйа (*фасоль*) саласын. Дубйаны пешерәсен, бүрткән сайын йарт кила, йарт кила саласын. Пешереп йаткан зат – дөгөнән – саласын да, шунын белән бергә зайтып аласын. Аннан сон шул 20 килога кабак саламыз казан эченә – казан төбенә төзөп, саламыз. Аннан кабакты салып өстенә биш кило бүрткән дөгөдән сала бирәсен, өстенә майын койоп бераз болгап-болгап, потом тагын саласын, пока ана шул 18 кило саласын, бер-ике килосы

инде чилтәктә (*тишекле чүмеч*) калады. Ул монадый да булады, ручкалы зур да булады. Шул майды қойоп-қойоп, болғап-болғап бераз зат итеп, последнийын чилтәккә бушатасын да, җәйеп-җәйеп, уқлау мынан тишеп-тишеп шығасын өстөнән. Анисы өстөнә қағыз йабасын сулап, қағыз қапчықлар бар бит, шуны сулап, бер ике қабатын алып, пылаудын өстенә йабасын. Малированный табақты өстөнә йабасын да, өстөнә йурқанмы анда, түшәкме шуны йабасын. Үәт шул пылау бастырылған була.

Бастырылғаннан сон өч сәғәт торадын ул. Өч-өч сәғәт йарым торады. 20 килоға бер өч сәғәт торады. Потом шығам суны пылауды. Ә ул аудару була инде – өстенән җыйып аласын барын да қабақның өстенән, мәркубын, суғанын бутап бергә, табақларға салып-салып, потом қабағын шығарасын. Қабақты шығарып уны башқа табаққа саласын. Қазанды йахшы итеп йуwып, тәтле қабақтын таты-балы қазанға қара булып йабылады. Шуны қазанды йахшы ышқып йуwып, алған дөгөдө, пылауды киредән саласын қазанға. Қабағын алмыйсын, қабағы айырым торады. Ә дөгөдө киредән қазан эшенә (*эченә*) салып, асларын төзәтәсен дә инде, йуwып ташлыйсын.

***Пылау пешерү өчен кирәк-ярак.*** Пылаудын утынын хуҗалар үзләре китерәләр. Кем заказыбайыт – шул китерә. Утын булмаға тийеш қаты ағач – слива, тут (*тут агачы*), алматирәк (*алмагач*). Улар көчлө. Ул қазанды суwытмаға бирмиде. Уты көчлө, ә простой, без җөнке дип әйтәбез, простой тирәкләр (*агачлар*) йылға буйында үсеп утыра, ул тепло бирмиде. Ә слива, алма, тут – улар қаты тирәкләр. Өч сәғәт торматға тийеш. Өч сәғәт утыра бастырғаннан сон өстен йаwып (*ябып*). 8 сәғәт бара бөтөн пылау пешерү wақыты: 4тә торасын, сәғәт 12 йартыларға әзер була ул. Қоранға 2 гә, сәғәт 4 тә йағып җибәрәсен, су қайнатасын. Қысқасы, төнө буйы йоқо йуғ инде ул пылау пешергәндә. Миған (*миңа*) алдан әйтеп қуйалар заказайтеп. Бу казан өй (*җәйге кухня*) – көне буйы шушында, пешерәм, кеше киләде көнө буйына. Пылау пиче, нугай пичем бар минем. Әүләдә (*өй алдында*) өлкүн (*зур*) өй.

*Идел буе районы Киләче авылында яшәүче Мулләминова Гөлҗиһан Харис кызыннан (1940 елгы) язып алынды.*

***Кием-салым, бизәнү әйберләре.*** Бездә шәл-мәл туқымағаннар. Қарағач йақлары туқыған. Безнен биттә (*якта*) сарық мамықтан наски туқығаннар айаққа кимәгә, қулға кимәгә бәрекләр (*бияләйләр*). Йәш қызларға перчатка. Шәлде, шарфны Красноярски, Нуримански битләре туқыйдылар. Сарық мамығыннан чөлкә (<*чулки*) кигәннәр, тақыйа (*башлык*) кигәннәр. Кәләпуш, йатақ (*бүрек*) мехтан тегелгән. Күләкләрде (*күлмәкләрне*) пешә (*кисеп тегә*) белгән үзе пешеп кийә бирде инде.

Борын озатқаннар, сондық, түшәк булған. Кийемнәре сондықта булған, пәрәзәләре (*битләрен каплар өчен*) булған. Приданны озын арбаларға, сиганский арбаларға салып китергәннәр. Аннары машин белән китергәннәр. Придан итеп йастық, түшәген әзерләгәннәр, башына бәйләргә йаулығын дигәндәй. Тастымал, сөлге, бит сөртә торғаны тәритйаулық (*сөлге*), аларны

сандыкка салганнар. Үлкүн (*зур*) сандыкларды калада йасаганнар.

Җир түшәге – сырдак җиргә җәйә торган, мамыктан йасайлар утыра торган итеп озон-озон. Борын заманды йастык, түшәк булган идәнгә җәйгәннәр, и шунда утырганнар. Тәсхан/тәстерхан (*ашъяулык*) җәйгәнннәр.

Килен булып төшкәндә кайнатам, кайнанам бар иде. Башта шәл, айакта чөлкә, йылы көн булса йаулык, озон җиңле күләк кийеп йөрдем.

*Идел буе районы Ярлы Түбә авылында яшәүче Бикбулатова Асия Абдразак кызыннан (1937 елгы) язып алынды.*

***Йорт салу.*** Монә мондый өйләр йуг иде ул wакытта, саманнан йасалган өйләр иде. Кызыл балчыктан йасыйлар дүрткел зур-зур кирпечләр, шуннан салынган йортлар. Безнен өйөбез бик кечки иде. Әти, зур кахам (*абыем*) сугышка китте. Йортларда бер зат (*нәрсә*) та йуг иде, сәке, булса инде, әзерәк түшәкләр. Ш(ч)итәне тал чыбыкларыннан үрәләр. Камыш йабабыз, агач йук. Аннан үзебезгә тагын камыштан өй салдык. Камышны бәйлиләр, пучок дип әйтәмез. Ул камышны тезәләр. Пучокны тезәмез, и ике йактан рейка белән кысамыз, тыгыз-тыгыз итеп куйамыз. Аннары аны сылыймыз балчык мән (*белән*). Әл дә ул өйләр бик күп. Хәзер камыштан салынган өйләр обшитый, шуңа камыштан икәне күренми. Ул кышын йылы, йазын (*җәй көне*) сәрен (*салкынча*) була. Ул wакытта без салган өйне йылын да (*ел саен*) сылый идек. Балчык белән көздә сылыйбыз. Ул кышын куба йаңыр мән, йазын шулай үткезәмез, көзен купкан җирләрен сылыймыз. Аннары халык әзерәк хәлләнә башлагач, такта, таш белән обшивайтә башладылар. Бу йак пластин бездәйе. Күп кешеләр, шулай өйләре бозолгач калада, алып шулайтеп салдылар. Пластин калын. Ул инде бороңгы менә безнен өйләрне әйттеләр байлар булган ул wакытта. Тәрәзләре кечкенә, дөрес салынмаган, стеналары да кыйшык (*кыек*). Бу калын бороңгы пластин. Болар чын агачтан киселгән, агачнын хәзер бит майын алалар. Ә монын майы үзендә, и ул череми. Бер-берләп тараттык, аннан аны осталар җыйдылар. Теге йагымызны камыштан йасадык йартысын пучоктан. Анарга хәтле камыштан түгел, саманнан салганнар. Хәзер инде ак таштан салалар, обшивайтәләр дә, ни заттан салынганы беленми дә инде. Камыштан салган өйләрне эчен дә, тышын да кайсылары эклиләр (*агартала*р) иде әк (*акбур*) мән.

*Идел буе районы Ярлы Түбә авылында яшәүче Бердиева Гөлфәридә Дуллаян кызыннан (1939 елгы) язып алынды.*

***Никах.*** Йегеткә киткәнче, кыз биттә *(ягында)* нихак *(никах)* укылады. Нихак булады туйда, әйттергәннән сон кодагыйларны кыз бит алады. Кемдә иртән сәгәт 8 дә булады. Аннан йегет киләде машина менән, кызды алып китәде йазлышмага. Нихакка киләде ике wәкил, берсе эни биттән, берсе эти биттән, как свидетел'ләр. Бер табак баwырсак пешереп алып барадылар, 12 табак алып бардык кызга. Аннан өстөнә сала бер косынка йаулык булса да баш бәйләмәгә кызга, тарак, пийала (*көзге*), кызга карамага. Потом бер айданмы йегет биттә була. Борон рисур арбага уты-

рып киләде. Ол биттә (*егет ягында*) дә шундый туй булады. Кийет бирде, ақча чәчте. Қыз биттен қодағыйлары киләдер хәзер монда. Йегет менән қыз көндез регистрацийәгә барып киләделәр, аннан сон көндөз қатыннар туйы, иртәнге якта булады.

***Ризалык алу, тел бүләге***. Бит күрем (*яшь киленнең битен ачу*). Қул алып (*күрешеп*) чыға килен. Ул қашып (*качып*) киткән қыздыкы, әйттерелгән қыздықы түгел. Қашып китә – қызды о(ы)рлый диләр, сагласийы була да, менә шуға бит күрем – қызды күрсәтәделәр. Ә әйттереп алғанды туй көндө күрсәтәделәр, қыз килгән көндө. Қызнын битен күрсәтәделәр, аннан әниләренә кийет (*бүләк*) бирә. Без беребез дә қашып бармадық, әйттереп бардық. Бездә әwәлдә әйттереп барады, аннан барғанда пербуй сүләшәде, йисли (< *если*) ул риза булса, чәй эчәде. Риза булмаса әйттереп барған кешеде, чәй эчмийде, ризалық итеп бер зат (*бернәрсә*) та нәрсә дә бирмиде. *Тел бүләге* дип берәз затмы (*әйбер*), кәмпитме (*кәнфит*) алып барадылар. Матамы (*тукыма* < *материал*), коробка кәмпитме – ни зат булса да салына. Кәмпит болай халыққа салына. Безнен wақытта берәз ғына инде тел бүләге итеп. Хәзер кийет һ.б. затлар күбрәк салып барадылар, тел бүләге дип әйтәделәр. Алып қашқан ул – йөрәделәр дә, сүләшәләр, туй йасасылары килмәсә, тизрәк өйләнешәселәре килсә, шул көннө үк әниләре әйтеп китәде, қода киләм диде. Утырыш йасыймыз. Несагласийы йасый инде кергәндәме. Кергәндә әлегә хәтлем дә бар обычаи, кергәнемнен ишек алдына ақ йаулық җәйәделәр, эчерәделәр, тәтле булып торсын дип бал қаптырадылар, йуллары ақ булсын дип сөт эчерәделәр. Дус-ишләре мән шул көнне үк берәз ғына утырадылар, аннан инде икенче көн әниләре-этиләре үзләре сүләшәделәр. Қул алмаға киләделәр. Йегет биттә бит күрем булады. Икенче көннө утырыш була – вечер – йәшләрнен. Һәр кеше үзенен wақытына қарап әзерләнеп, бер атнадан сон, хатыннарға утырадылар. Унда қоры (*фәкать*) қатыннар – әниләре, туғаннары, дуслары. Қыз қул алып шығады, йегет биттән бер җиңгәде, қыз биттән бер җиңгәде қызды қатыннарның қулын алып шыға (*күрешә*). Қызды, анын битен күрсәтәделәр. Аннан туй була йәшләрнең, аннан қыз биттә пирбым (< *сперва*) кийәү сыйлыйлар. Беген қыз қашып килде ди, қартларнын туйы була. Аннан күпмедер wақыт узғач, қул алма барып килә, аннан қыз биттә кийәү сыйлыйлар. Ул ғәдәтләр әле дә бездә бар.

***Хатыннар-кодағыйлар туе һәм кияү сые***. Мамай туйы қартлардықы. Аннары әзерләнәләр кийәү сыйға. Қыз биттә қодағыйлар аладылар. Хатыннар туйы булады башта. Анда қодағый бер йегермеутыз кеше алып барады үзенен йағыннан. Кодағыйлар туйы көндез була, иртәрәк, байанды (*ак яулык, чите кызыл лента белән сугылган*) бастырады. Аны бер туғаны зур кеше баса инде. Или ирнен тәтәсе, кийәwенен. Или үзенен тәтәсе, йә җиңгәсе. Безнен балаларымызға да йуш булсын дип тезелеп утырған қунақлардын маңғыйларын сыйпау, тидереп алу була ул байанды бас-

тыру. Әwәлдә кич була торған иде. Байанды бастырып булғаннан сон инде, кийет (*бүләк*) бирәде, шикәр бирәделәр айақтан (*касәдән*), кешегә бүләккә китәде подноста. Қыз биттә кийәү сый булғанда подноста шикәр китәделәр. Йегет биттән зур поднос белән шикәр, конфет, җимешләр әкитә. Бу қодағыйлар туйы. Кийет бирәде, шушы подноста килгән шикәрде бүләделәр шатырдағы (*чатырдагы*) халыққа, айақларға бүлеп-бүлеп кечкенә пакетларға салып бирәделәр. Анары кийет бирәде – мата, тастамал, башйаwлық – кем ничек инде. Кийетне җиңгәсе, әнисе, апалары бирәде. Шатырдағы бөтөн халыққа бирәделәр. Аннан сон манит (*акча*) чәчәделәр, кийетләремез хәйерле булсын дип салалар, әйтәделәр. Башта қыз бит чәчәде, шуннан сон қодағыйлар чәчәде. Хәзер инде қыз бит кийет биргәннән сон чәчәде. Анда балалар да буладылар, алар манит җийадылар, җийып йөрәделәр. Кийәү сый бетте. Ашадылар, эчәделәр, пылау бастырадылар, пахлаwа, лақсалба, чәкчәк ... Әwәлдә бөтөн туғаннар җийылып шул затларны үзләре пешерә иде. Хәзер заказывайтәделәр, ризык төрләрен пешерә торған хатыннар бар. Ақшанды түлисен дә аласын.

Бер ике-сәғәттән кийәү сый башланады. Кичке 9–10 нарда шул қыз биттә. Пирбуй кийәү килеп керәде шаторға, керми тора башта, уны күтәрәләр дә кергезәләр. Әwәлдә, безнен wақытта қаwаллар (*уен коралы*), саратский саз (*гармун*), скрипка иде. Сазды тартадылар. Хәзер музыка.

Аннан шатырға кийәү керәде. Кийәwде күтәреп кергезәделәр. Ул wақытта қыз өйдә була. Хәзер бергә утырадылар. Ул безнен боронғо wақытта без бергә утырмадык. Хәзер кийәү сыйда бергә утырадылар. Өстәлләр әзер, арақыды қойадылар, сыйларға тотоналар барсын да. Кийәүгә кийет бирәләр. Безнен wақытта костүм, брүкә (*чалбар*), соңыннан велосипит бирәделәр иде. Хәзер баштанайақ кийендерәләр, кийәүнен әнисенен алдына саладылар кийетләрне. Қызға да шулай. Уға туғыз бирәделәр: күлмәкләр, шуба, итеге дә, пәлтәсе дә. Бар да бар. Бирәделәр дә туй башлана. Ашап-эчеп утырымыз (*утырабыз*) инде.

*Идел буе районы Кызан авылында яшәүче Бикбулатова Хәдичә Даир кызы (1942 елгы) белән Ильясова Халидә Фәрит кызыннан (1938 елгы) язып алынды.*

## ӘДӘБИЯТ

Арсланов Л.Ш. Язык юртовских татар // Материалы по татарской диалектологии. Казань. 1976.

Арсланов Л.Ш. О влиянии языка юртовских татар (ногайцев) на язык татар Наримановского района Астраханской области // Вопросы татарского языкознания. Казань. 1978. С. 107–119.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы***, филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикология һәм диалектология бүлегенең фәнни хезмәткәре
e-mail: m.r.bulatova@mail.ru

УДК 091:930.27

# СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ОЕШТЫРЫЛГАН АРХЕОГРАФИК ЭКСПЕДИЦИЯЛӘРДӘ ТАБЫЛГАН КОРЪӘН НӨСХӘЛӘРЕ

*А.М. Гайнетдинов*

В статье сообщается о новых находках рукописей Корана, найденных в ходе последних археографических экспедиций самим автором. Дается краткий анализ этих рукописей, описываются их особенности. Также сообщается о важности научных экспедиций и необходимости их постонной организации в места компактного проживания татар.

**Ключевые слова:** Коран, старинные рукописи, научные экспедиции, находки, археография.

Татарстанның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә бихисап күп борынгы кульязмалар һәм сирәк китаплар саклана. Алар, нигездә, төрле елларда оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында халыктан җыелган. Материаллар арасында бик күп кульязма Коръәннәр дә бар.

Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәрләренә мирасханәне материаллар белән даими баетып тору өчен һәрвакыт фәнни экспедицияләрдә йөрергә туры килә. Җәй җитүгә, илебезнең татарлар яшәгән төрле почмакларына, әби-бабалардан калган борынгы язма истәлекләр эзләп, сәфәргә чыгабыз. Эзләгән – тапкан, ташка кадак каккан, дигәндәй, археографик материал, төгәлрәк әйткәндә инкыйлабка кадәр язылган борынгы кульязмалар һәм сирәк китаплар кая гына барсак та, әле һаман табылып тора гәрчә алардан файдаланган буыннар алышынып бетеп килсә дә. Үзәк өчен экспедицияләр аеруча бик мөһим урын алып тора, чөнки, нигездә, халык арасында йөреп кенә милли, төрки язма истәлекләребезне барлый алабыз.

Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә эшләүче галимнәрне, хезмәткәрләрне бигрәк тә археографик эзләнүләр җәлеп итә. Институтта иң күп археографик экспедицияләрдә йөргән кеше, әлбәттә, атаклы галим Марсель Әхмәтҗанов. Мирасханәдә саклана торган кульязма Коръәннәрнең өчтән ике өлеше аның тарафыннан табылган.

Шунысын да әйтергә кирәк, экспедицияләрдән табып алып кайтылган борынгы китаплар сәламәтлеккә куркыныч яный торган тузан белән капланган, кәгазь гөмбәчекләре белән зарарланган, тычкан-күселәр

тарафыннан кимерелгән була. Бу эштән һич курыкмыйча, һәр китапны щеткалар белән чистартып, тузанын кагып, тышлап, кеше тотып укырлык хәлгә китерергә кирәк. Шуңа күрә экспедицияләргә йөрмәгән, материалларны эзләп йөргәндә, эшкәрткәндә күргән авырлыкларны, мәшәкатьләрне үз җилкәсендә татып карамаган кеше археографик материалларның кадерен дә белә алмыйдыр мөгаен.

Дәүләт архивларының берсендә эшләүче бер хезмәткәрнең борынгы документларны киштәләрдән алып идәнгә ташлаганын ишетеп, бик гаҗәпләнгәнебез бар. Борынгылардан калган хәзинәләрне шулай кадерсезләүчеләр дә очрый шул әле бүген. Шул хәтле кадерсезләү түгел, кайвакыт, хәтта, экспедициядән алып кайткан материалларны эшкәрткәннән соң калган «чүп-чарны», ягъни кәгазь калдыкларын, бик кечкенә ертык кисәкләрен, гөмбәчекләр белән яки күгәреп нык зарарланган битләрне дә ташларга кул бармый.

Соңгы елларда Институт җитәкчелеге тарафыннан фәнни экспедицияләргә аеруча нык игътибар бирелә башлады. Экспедиция вакытындагы бөтен эшләү, тору, туклану мәсьәләләрен дирекция үзе хәл итә, эшне нәтиҗәле итеп оештыра. Шул сәбәпле, археографик табышлар артканнан-арта бара, хезмәткәрләребез аларның тасвирламаларын төзеп кенә өлгерсеннәр.

2010 елда Институт тарафыннан Татарстанның Апас районына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Анда фольклор, археография, тел, сәнгатькә караган материалларны җыючылар да бар иде. Археографик материалны җыю исә мин фәкыйрегезгә йөкләнде. Кызганычка каршы, тулы Коръәннәргә юлыкмадым, фәкать фрагментлары гына табылды. Шулай да, берничә Коръән басмасына тап булдым. Аларның кайчан басылулары билгесез, чөнки тышлыклары, күбесенең йә башы юк, йә ахыры юк иде. Шулай ук калайга язылган Коръән табылды, ул инде XIX гасырның 80–90 нчы елларында эшләнгән булса кирәк.

Коръән Институт архивында күп саклана. Аннан соң, кешеләр үзләре ул китапларны өйләрендә кадерләп сакласа, әби-бабалардан калган, татар халкы мирасына караган истәлекләргә карата яшьләрдә хөрмәт, сакчыл караш уяна. Киләчәк буын аларны үз өйләрендә ниндидер изге нәрсә кебек кадерләп кенә сакланганнарын күреп үсә. Ә бу – рухи кыйммәтләрне үстерүгә юнәлдерелгән тәрбия чарасы булып хезмәт итәргә мөмкин. Шул сәбәпле, борынгы басма Коръән китапларын, әгәр дә алар тулы булмаса, без аларны хуҗаларында калдырабыз. Бу изге китап һәр мөселман йортында сакланырга тиеш.

2011 елда Татарстанның Кукмара районына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Биредә исә Коръән нөсхәләре дә табылды. Алар арасында кулдан язылганнары да, басмалары да шактый.

Чишмәбаш авылында табылган кульязма Коръән кыйммәтле табышлардан булды. Палеографик билгеләре буенча ул XVIII гасырга карый.

Уразай авылында, шулай ук, ике кульязма Коръәнгә юлыктык.

Аларның берсен 1911 елның 26 мартында мулла Җәлал бине мулла Мөхәммәди әл-Борбашый күчереп язган. Исеменнән күренгәнчә, ул үзе Балтач районының Борбаш авылыныкы булса кирәк. Бу инде тагын бер Коръән күчерүченең исеме ачыкланды дигән сүз. Китап башында түбәндәге сүзләр язылган: «Мәктәп балаларына төшкән битләрен кушып яздурдым, Аллаһы Тәгалә язган кешиләргә әҗерләрен бирсүн, ахирәтдә шәфәгатен насыйб кылсун, саваб өмид кылуб яздук». Коръәнне яздырган, эшләткән зат – Борбаш авылының Фәтхетдин Солтанморад улы. Китап 22,5х18 см форматында эшләнгән. Ул татар тәгъликы дигән ысулда куе көрән төстәге каралар белән язылган. Коръәннең тышлыгы каты кәгазьдән ясалып, киндер тукыма белән төрелгән. Китап ике төрле кәгазь белән эшләнгән, икенче кәгазендә су билгеләре юк. Димәк, аны ике кеше күчергән булып чыга. Беренче күчерелгән Коръәннең битләре югалгангадыр, җитмәгән өлешен аның иясе башка кешегә күчертергә биргәндер күрәсең. Шулай да безнең көнгә хәтле килеп җиткәнче ахыргы битләре югалган.

Икенче Коръәннең язылу еллары, күчерүчесе күрсәтелмәгән. Аның форматы – 17,5х14 см. Ул гарәпчә, нәстәгъликъ дигән ысулда куе көрән төстәге каралар белән язылган. Коръәннең тышлыгы каты кәгазьдән ясалып, киндер тукыма белән төрелгән, тукыманың инде ярты өлеше диярлек череп теткәләнә башлаган, аның буявы кәгазьгә дә күчкән. Кулъязма дымлы урында ятканлыктан һәм кәгазе дә начаррак сыйфатлы булу аркасында башындагы һәм ахырындагы битләре шактый гына ертылып, теткәләнеп беткән.

Кулъязма китаплардан тыш, әле фотога алу юлы белән ясалган Коръән дә табылды. Алар инде, билгеле, борынгы түгел. Ләкин бу күренеш татар халкының төрле юллар белән үзләренең китапларын саклап калырга тырышулары хакында сөйли.

2012 елда Удмуртия Республикасының Балезино һәм Юкамен районнарына комплекслы фәнни экспедиция оештырылган иде. Биредә Коръәннәр чагыштырмача күбрәк табылды.

Юкаменск районы, Иманай авылында табылган Коръән 17,5х11 см форматында, тексты нәстәгъликъ ысулында көрән төстәге каралар белән язылган. Сүрәләрнең һәркайсының диярлек башында кызыл төстәге кара белән аятьләрнең гомуми саны күрсәтелгән. Кайбер сүрәләрнең кайда иңгәнлеге дә (Мәккәдәме, Мәдинәдәме) теркәлгән. Кызганычка каршы, тышлыгы сакланмаган. Әлеге китапта Коръәннең «Кәһаф» («Тау тишеге») сурәсенең 45 нче аятеннән алып «Әхкаф» («Комлык») сүрәсенең 4 нче аятенә кадәр өлеше бирелгән. Су билгеләре юк, палеографик билгеләре буенча аның эшләнеше XIX гасыр ахырына туры килә. Күчерүчесе күрсәтелмәгән.

17,5х11см форматындагы икенче Коръән дә, шулай ук, югарыда телгә алынган авылда табылды. Күп кенә битләре кызыл рамкага алынган. Китап нәстәгъликъ ысулында көрән төстәге каралар белән

язылган, аятьләрне, аерыр өчен, кулланылган билгеләр кызыл төстәге кара белән бирелгән. Ике төрле кәгазь белән эшләнгән, тишелгән җирләре һәм кырыйлары пөхтә итеп башка кәгазь белән ябыштырылган, тышы киндер тукымадан ясалган. Анда, Коръәннең, башыннан алып, «Бәни Исраил» («Ягкуб балалары») сүрәсенең 99 нчы аятенә кадәр өлеше китерелгән. Су билгеләре юк, палеографик билгеләре аның эшләнүе XIX гасыр ахырына туры килүе хакында сөйли. Күчерүчесе күрсәтелмәгән.

Коръән китабының җиде биттән торган фрагменты да табылды. Ул 13,5х8,5 см форматында, тексты – 9,5х6,5 см. Ул шулай ук көрән төстәге каралар белән, бөтен сүрәләр башында диярлек кызыл төстәге кара белән аятьләрнең гомуми саны, кайбер сүрәләр башында кайда иңгәнлеге (Мәккәдәме, Мәдинәдәме) язылган. Тышлыгы юкка чыккан. Анда «Йәсин» сүрәсе һәм «Каф» сүрәсеннән алып Коръәннең ахырына хәтле булган сүрәләр китерелгән. Су билгеләре юк, палеографик билгеләре буенча ул XIX гасыр ахырына туры килә. Күчерүчесе күрсәтелмәгән.

Удмуртиядә бер Коръән китабының ахыргы ике битен генә таптык. Анда китап иясе Закир (Мөхәммәдзакир), үз-үзенә нәсыйхәт биреп, түбәндәге тәрбияви сүзләр язып куйган:

«Әй, Закир, бигрәк әдәбсез син, элек инсаф ал, соңра гыйлемлек ал! Әдәбсез галим наданлардан ямандур. Әүвәл әдәб-инсафлы булурга үгрән, соңра гыйлемлек ал! Әдәбсез галим наданлардан ямандур».

Удмуртиянең татар авылларында Коръән китабына зур игътибар биргәннәр. Аны XX гасыр урталарыннан соң да бик күп күчереп язганнар. Шул рәвешле күбәйткәннәр, бу изге китапны һәр кеше үзендә булдырырга теләгән, хәтта совет хөкүмәте динне тыйган заманда да моны эшләргә курыкмаганнар. Бу табылган кульязмалардан бик ачык сизелә. Коръән китапларының күп табылуы халыкның электән үк дини булганылыгын күрсәтә.

Шулай ук дәфтәргә күчерелгән «Йәсин» сүрәсе табылды. Ул үзе борынгы булмаса да, күчерелү рәвеше үзенчәлекле: гарәп сүзләре анда гарәпләрдә кабул ителгән формада түгел, бәлки ничек ишетелә, шул рәвешле язылганнар. Бу – күчерүченең гарәп телен белү дәрәҗәсе белән бәйле.

Шулар белән беррәттән, XX йөзнең 80 нче елларында күчерелгән кульязма Коръәнгә дә тап булырга туры килде. Димәк, бу якларда Коръән күчерү традициясе әле XX гасыр ахырына хәтле дәвам иткән.

Экспедицияләрдә йөргәндә еш кына кайбер авылда яшәүчеләрнең, борынгы кульязмаларны, кая куярга белмичә, зиратка алып барып күмүләрен ишетергә туры килә. Димәк никадәр хәзинә, халкыбыз мирасы җир куенына күчә. Әйтәсе килгән сүз шул: борынгы кульязмаларны, иске китапларны, зиратка күмгәнче, мәчетләргә, музейларга тапшыру дөресрәк булыр иде. Чөнки без һәрвакыт экспедицияләрдә йөргәндә борынгы кульязмалар, иске китаплар эзләп мәчетләргә, музейларга мөрәҗәгать

итәбез. Анда сакланган борынгы басма яки кулъязма хәлендәге китапларның һичьюгы, копияләрен булса да алып кайтабыз.

Басма Коръәннәр турында да берничә сүз әйтәсе килә. Удмуртиянең Засек авылында 1907 елда басылган ике томлы Коръән табылды. Шунысы бик кызык, әлеге китап өр-яңа кебек сакланган диярлек. Димәк, хуҗалары аны бик кадерләп кенә, салкында, эсседә тотмыйча, яхшы шартларда гына саклаганнар. Үзләре үлгәч, китап кадерсезләнеп ятып, гөнаһлы булырбыз, дип курыкып, бездән аны алып китүебезне бик үтенделәр. Хәзер исә бу китап мирасханәбездә саклана.

Үзәк җитәкчесе Р.Ф. Исламов барлык материалларның яхшы шартларда саклануын кайгыртып, күзәтеп, тәэмин итеп тора, шулай ук ул үзе дә мирасханәне баетуда шактый өлеш керткән галим. Аның тырышлыгы белән фонд тупланмалары тәртипкә китерелде, хәзерге заман таләпләренә туры килгән яңа стеллажлар белән тәэмин ителде, үзгәртеп кору эшләре башкарылды, техник җиһазлар белән тәэмин ителеш яхшырды, эшләү өчен барлык уңайлыклар тудырылды.

Безнең хезмәткәрләргә археографик материаллар тупларга ярдәм иткән бер кеше дә онытылмый – һәркайсының исем-фамилияләре теркәлеп куела, паспорты төзелә. Институтыбыз мирасханәсенә килеп җиткән археографик материаллар кадерләп саклана, чөнки, беренчедән, алар татар халкының кыйммәтле мирасын тәшкил итә, икенчедән, бу материаллар институт хезмәткәрләре тарафыннан бик күп авырлыклар, тырышлыклар белән, мәшәкатьләр белән җыелган.

***Гайнетдинов Айдар Марсиль улы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең фәнни хезмәткәре
e-mail: aydargm@yandex.ru

УДК 792:93

# ОКТЯБРЬГӘ КАДӘРГЕ ТАТАР ТЕАТРЫНДА КОМЕДИЯ ЖАНРЫ

*Д.Р. Фәрдиева*

В статье рассматривается процесс постановки комедий на татарской сцене дореволюционного периода. Проанализированы наиболее важные спектакли, их особая значимость для зрителя того периода.

**Ключевые слова:** театр, комедия, роль, пьеса, жанр, спектакль.

Татар әдәбиятында комедия – иң актив сәхнә жанры. Жанр буларак татар комедиясе татар мәгърифәтчелек фикеренең үсеше дәверендә формалаша. Шуңа күрә ул XIX гасырның татар сатирасы җирлегендә үсеш ала. Беренче татар комедияләре («Комедия Чистайда», «Хасәт бабай») үз чорының әһәмиятле мәсьәләләрен күтәреп чыгалар һәм алар хакында җәмәгатьчелек фикерен кузгаталар. Бу пьесалар заман рухы белән сугарылган булып, образлар ярдәмендә шул алдынгы идеяләрне гәүдәләндерәләр. Башка жанрлардан аермалы буларак, комедияләр халык телендә язылып, гади кешеләр арасында киң тарала.

1906 елның 22 декабрендә Казанда беренче тапкыр киң катлау тамашачылар өчен татарча ачык спектакль күрсәтелә. Бу кичтә «Кызганыч бала» драмасы белән бергә «Гыйшык бәласе» комедиясе дә уйнала. Спектакльдә «Шимбә» түгәрәге әгъзалары Әминә Терегулова, Суфия Коләхмәтова, Фатыйма Саинова, Зәйнәп һәм Рабига Габитовалар, Каюм Коләхмәтов, Габдрәүф Ниязбаев, Рәхим Тенишев, Солтан Рахманкулов һ.б. катнашалар.

Октябрьгә кадәрге татар театрында көнкүреш комедиясе, романтик драма һәм мелодрама актив яши. Бу чорда көнкүреш комедиясе генә түгел, ә бәлки комедиянең төрле жанрлары – водевиль, социаль-көнкүреш һәм сатирик пьесалар да куела.

Г. Камал – татар драматургиясендә комедия жанрының төп идея-эстетик принципларын билгеләп, аңа нигез салган язучы. Ул комедиягә зур бурычлар йөкләде, искелеккә, кадими көчләргә каршы көрәштә аны үткен корал дип санады.

1908 елның 18 августында Г. Камалның «Беренче театр» комедиясе сәхнәгә куела. Бу комедия милли театрга каршы һаман дәвам иткән һөҗүм шартларында языла. Мәгълүм булганча, бер төркем Казан муллалары дин исеменнән театрны тыю турында 1909 елда фәтва чыгарып, «Мәгълүмат» журналында бастыралар. Г. Камал бу көрәшләрдә

демократик көчләрнең барыбер җиңеп чыгачагына нык ышана һәм әлеге фәтвачы Хәмзәләрнең, ни генә кылансалар да, барыбер юлдан алынып ташланачакларын ачык күрә [Татар..., б. 596 ]. «Беренче театр» комедиясе тормыштан алынып язылa, һәм ул зур уңышка да ирешә. Г. Камал драматургия чаралары ярдәмендә конфликтның комедиячел табигатен тагын да үткен итеп күрсәтә. «Беренче театр» – Г. Камал иҗатының үсә баруын күрсәтү ягыннан да, «Сәйяр» труппасы репертуарына зур иҗтимагый проблемалы әсәр буларак килеп керүе белән дә бик мөһим. «Беренче театр»ның куелуы уңае белән, Ф. Әмирхан болай дип яза: «Г. Камал әфәнденең бу комедиясе нәкъ шул театр мәсьәләсенең кайнаган вакытында чыгуы белән бигрәк әһәмиятледер. Татарча театрларга мохалиф кешеләр үз кыланышларын шул ук татар театрына барып күрсеннәр» [Дамелла, 1908, б. 2].

«Беренче театр» комедиясе конкрет вакыйгаларга таянып, Г. Камалның үз тормышыннан алып язылган. Һәр персонажның үз прототибы бар. Хәмзә байның прототибы – Г. Камалның каенатасы. Хәмзә бай ролен Г. Кариев башкара. Әйтергә кирәк, Кариевның комедиячел типларны гәүдәләндерүдәге сәләте шушы роль ярдәмендә ачыла. «Өстән караганда көчле, ә асылда бетәргә хөкем ителгән фанатик Хәмзә ролен Габдула Кариев гаҗәп оста юмор белән башкара, ә караучы аның көчсез гайрәтендә бу сугышчан мракобесның тиздән бетәсен күрә, культураның һәм сәнгатьнең тантанасына ышана», – дип искә төшерә З. Солтанов [Султанов, 1940, с. 6].

Биби ролен Сәхипҗәмал Гыйззәтуллина-Волжская башкара. Ул аны авылдан килгән татар кызы итеп, ни акыллы, ни юләр, аңгыра һәм кире кеше итеп уйный. Рольне болай башкару – комедиядә бирелгән образга ятышып бетми. Бу – артистканың үз трактовкасы. Ләкин әсәрнең авторы Г. Камал бу рольнең башкарылуыннан бик канәгать булган [Кашшаф, 1958, б. 35].

Труппаның бу эшен РСФСРның атказанган артисты З. Солтанов: «Труппа фанатик татар буржуазиясенең бу чор өчен характерлы булган театр һәм культурага каршы көрәшен җәмәгатьчелек алдында фаш итүне максат итеп куйган иде. Беренче труппа артистлары йөзендә бу комедия оста башкаручыларны тапты, һәм «Беренче театр» комедиясе зур уңышлар белән барды», – дип бәяли [Султанов, 1940, с.63].

Г. Камалның «Бүләк өчен» (1909) комедиясе эзләнүләрнең тагын бер уңышы була. Революциягә кадәр татар әдәбиятында, шул исәптән драматургиясендә, көндәлек тормыштагы искелек һәм яңалык конфликтларын чагылдырган әсәрләр күп языла, һәм персонажларның көрәше еш кына акча өчен өйләнү, күп хатын алу, көчләп кияүгә бирү яки өйләндерү кебек вакыйгалар тирәсендә бара. Әмма Г. Камал бу мәсьәләләрне үзенчә чишә. Ул төп игътибарны комедиянең баш герое Хәмидәнең эчке дөньясын һәрьяклап фаш итүгә юнәлтә. Ул – иске гаиләдәге гореф-гадәтләрнең көзгесе булырлык итеп эшләнгән образ. «Менә шул кыска пьесада

Г. Камал бөтен татар тормышының әхлаксыз, гаилә башында торучыларның да «мисез» икәнлекләрен күрсәтеп өлгерә. Бу китаптагы татар хатыны – тәмам-тәмам илә безнең тормыштагы гаилә бәхетсезлегенең башлыгыдыр. Ул үзенең тәрбиясезлеге белән, баласының бәхет-сәгадәтенә тырышачак урында, юк кына нәрсә өчен аның бөтен сәгадәтен җуярга әзер тора. Ни өчен? Әйтергә дә оят: бер асыл күлмәк өчен!.. Гомумән алганда, Г. Камал әфәнденең бу әсәре дә хәзерге татар галәмендә беренче комедияләрдән саналырлык булып чыккан... Һәрбер татар гаиләсе өчен бер данәсен укырга вә үзләренең тоткан юлларының ни дәрәҗәдә көлке икәнлеген уйлап карарга тәүсыя итәм» [Габдулла..., 1976, б. 63].

Г. Камал төрле җәмгыятьләрне генә тасвирламый, үз чорының күпчелек социаль төркемнәрен дә сурәтли. Аның әсәрләрендә байларны да, шкафчыларны да, официантларны да, артистларны да, мөритләрне дә очратасың. Үзара көрәш алып барган кадимче белән җәдитчеләр дә җитәрлек. «Банкрот» комедиясе дә шул чор өчен бик характерлы әсәр. Кариев-Сиражетдин сәхнәгә акылын җуйган кеше кыяфәтендә килеп керә. «Кариев шулкадәр җүләрлеккә сабышып уйный иде, аның акылдан язган Сиражетдин икәнлегенә ышанмаска мөмкин түгел иде», – дип искә төшерә Гөлсем Болгарская [Татар..., 1975, б. 187].

«Бу пьесаны беренче мәртәбә куйган «Сәйяр» аңа үткен социаль яңгыраш бирдә. Бигрәк тә комедиянең төп ролен башкаручы Габдулла Кариевны әйтеп китәргә кирәк. Сиражетдин ролендә Кариев татар сәүдәгәрләренең җыелма образын күрсәттә. Аның уенында тамашачы Печән базары короленең характерлы якларын күрде. Г. Кариев риялы сәүдәгәрнең социаль йөзен ачып бирү дәрәҗәсенә житте», – ди Зәйни Солтанов үзенең истәлекләрендә [Султанов, с. 12].

Шулай итеп, жанр мөмкинлекләреннән, көлкеле хәл-әхвәлләрдән, сатирик персонажлардан, тел-сурәтләү чараларыннан оста файдаланып, Г. Камал татар драматургиясенең алтын фондында урын алган комедияләр иҗат итә.

1911 елдан алып 1917 елга кадәр «Сәйяр» труппасының даими репертуары үзәгендә, Г. Камал әсәрләреннән тыш, башка комедиографларның да пьесалары уңыш белән бара. Шундыйларның берсе – «Җәмгыять» һәм «Кыямәт» комедияләренең авторы – Гаяз Исхакый. «Кыямәт» спектакле куелгач, «Дин вә мәгыйшәт» журналында (1911, № 5) «Татар театры, яхүд имамнары тәхкыйрь» исемле мәкалә басылып чыга. Анда аноним автор бу спектакльләрдә дин әһелләренең фанатик, артта калган өлешенә юнәлдерелгән укны, бөтен руханиларга каршы юнәлдерелгән хурлау дип кабул итә [Арсланов, 1999, б. 174].

Сатирик юнәлеш көчле булган бу чорда татар театрында искелек тарафдарларының чын йөзен ачып салган комедияләрдән «Помада мәсьәләсе» (И. Богданов), «Хасәт баба» (Г. Фаикъ), «Низамлы мәдрәсә» (С. Рәмиев) кебек спектакльләр дә зур уңыш казана. Бу комедияләр тамашачыларда зур тәэсир калдыра, тормыштагы ак һәм кара та-

пларны аера белергә өйрәтә. Мондый комедияләрдә артистларның осталыгы да камилләшә бара. Сәйяр» труппасы составында булган артистлар Г. Болгарская, К. Тинчурин, Н. Сакаев, Г. Мангушев, Н. Таждарова, Камал I, Камал II һ.б. бу әсәрләр буенча спектакльләрдә осталарча эшләнгән тирән реалистик сәхнә образларын иҗат итәләр.

Татар комедияләре белән бергә, рус драматурглары әсәрләре дә сәхнәдә уңышлы куела. Мәсәлән, 1910 елның 4 февралендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан беренче тапкыр Н. Гогольнең «Өйләнү» пьесасы буенча спектакль күрсәтелә, ә 1916 елның 4 мартында – «Ревизор» әсәре. «Ревизорны» Г. Кариев үзенең бенефисына әзерли. Кариев монда тупас, икейөзле патша чиновникларының бөтен эшәкелекләрен туплаган Городничий образын уйный. Аның гримы, кыяфәте, шактый ук олы гәүдәсе дә килешеп тора. Тик тавышында, бераз усаллык кына җитенкерәми [Октябрьгә ..., 1988, 187 б.].

1917 елның 21 апрелендә «Сәйяр» труппасы тамашачыга «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектаклен күрсәтә. Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесасы – Октябрьгә кадәрге татар комедиясенең югары баскычын тәшкил иткән классик әсәр. Әмма бу комедия бик каршылыклы кабул ителә. Мәсәлән, Г. Кәрам, спектакльне караганнан соң, әсәрне «һичбер әдәби кыйммәткә ия булмаган бер фарс» – дип бәяли, ахырдан гына «шөбһәсез, галерка публикасына ошады булырга кирәк, алкышлар булгалады», – дип өстәп куя [Кәрам, 1917, б. 197]. Юныс хаҗи образын Г. Кариев тулы канлы, тормышчан сәхнә образы итеп башкара.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: 1906 елдан алып, Октябрьгә кадәр «Сәйяр» труппасы тарафыннан 60 тан артык комедия куела, һәм алар тормышның актуаль мәсьәләләрен күтәргән, чынбарлыктагы тискәре күренешләр турында уйландыра торган әһәмиятле иҗтимагый факторга әвереләләр, татар театры үсешенә зур йогынты ясыйлар.

ӘДӘБИЯТ

Арсланов Г. Гаяз Исхакый һәм татар театры // Казан утлары. 1999. № 9. 172–177 б.

Габдулла Кариев / төз. Х. Гобәйдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр. 1976. 230 б.

Дамелла. Беренче театр // Әлислах. 1908. 10 июнь.

Кашшаф Г. Беренче артистка. Казан: Таткнигоиздат, 1958. 49 б.

Кәрам Г. Театр вә музыка // Аң. 1917. № 5.

Октябрьгә кадәрге татар театры / төз. Һ. Мәхмүтов, И. Илялова, Б. Гыйззәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 399 б.

Султанов З. Дооктябрьский татарский театр // Кулъязма. Татарстан театр эшлеклеләре союзы архивы; 7 ф. 6 б.

Татар әдәбияты тарихы / редкол.: Н.Г. Юзиев, Я.Г. Абдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 600 б. Т. 3: ХХ гасыр башы.

Татар совет театры (очерклар) / ред. Б.Н. Гыйззәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 493 б.

***Фәрдиева Динара Радий кызы***, филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
театр һәм музыка бүлегенең фәнни хезмәткәре
e-mail: dinara.fardeeva@yandex.ru

УДК 72.04

# КАЗАНДА СПРЕЙ-АРТ СӘНГАТЕ ҮСЕШЕ

*А.Р. Исимбитьева*

В статье рассматривается развитие искусства спрей-арта в Казани. Автор уделяет внимание классификации произведений этого вида искусства, обозначает основные противоречия, свойственные спрей-арту, и выявляет возможности для роста в условиях города Казани.

**Ключевые слова:** спрей-арт, городская культура, райтер, бомбер, граффити.

Бүгенге шәһәрне граффитидан башка күз алдына да китереп булмый. Диварларга аэрозоль буяу белән төшерелгән рәсемнәрне һәр яшәү пунтында диярлек күрергә мөмкин. Граффити белән бизәлгән йорт диварлары, метро вагоннары, коймалар һәм башка шундый рәсем бизәлеше булырга тиеш түгел объектларга инде күнегеп киләбез. Бу мәкаләбездә граффити сәнгатенең иң тиз үсеш ала торган юнәлеше – спрей-арт турында сүз кузгатырга булдык.

Бүгенге көндә шактый киң кулланылыш тапкан граффити төшенчәсе турында аерым тукталып үтү кирәк. Тарих фәнендә бу термин таррак мәгънәдә, борынгы эпиграфик ядкярләр – тырнап ясалган рәсемнәр – турында сөйләгәндә кулланыла. Хәзерге көндә исә грффити урам диварларын бизәүнең бар төрен дә аңлата. Төшенчәгә шулай ук скреччинг – шома өслекне тырнап ясалган рәсем яки язма – һәм спрей-арт – аэрозоль буяу ярдәмендә төшерелгән рәсем – дә керә. Хәзерге көндә спрей-арт сәнгатенең инде үз терминологиясе, төрләре һәм стильләре дә оешкан.

Спрей-арт сәнгатенә беренче аяк баскан рәссамнар үзләрен той дип исемлиләр (ингл. toy – уенчык) һәм тәҗрибәлерәк рәссамнарны кабатлау юлы белән эш йөртәләр. Тойның үз стиле барлыкка килеп, үсеш ала икән, ул инде райтерга әйләнә.

Райтер – диварларда масштаблы, зур рәсемнәр калдыручы граффер. Шулай ук граффити-рәссам, стайлер исемнәре дә кулланыла. Әлеге рәссамнар өчен төрле яклап (мәсәлән уклар кертү, өчкырлы хәрефләр белән язу) эш стильләрен катлауландыру, кызыклы сюжет, югары сыйфатлы эшләнеш хас. Райтер диварга рәсем ясый, дип әйтү дөрес тә түгел, чөнки рәссам эчке хиссиятенә буйсынып эшли, үзен борчыган проблемаларга халык игътибарын җәлеп итәргә тырыша. Күпчелек граффити-рәссамнар хезмәтләрен нәкъ менә иҗат һәм адреналин катнашы буларак кабул итәләр.

Спрей-арт сәнгатенең иң тиз үсә торган юнәлешләреннән берсе – бомбинг, ягъни бер яки ике төс ярдәмендә аэрозоль буяулар белән төрле өслекләргә язмалар төшерү (метро вагоннары, поездлар, торак йорт диварлары, һәйкәлләр һ.б.). Бомбер эше тәвәккәллек сорый, ник дигәндә, аны хокук саклау органнары хезмәткәрләре тоткарларга мөмкин. Бу очракта рәссам өчен эшләнеш сыйфаты түгел, ә тизлек һәм рәсемнең мәйданы мөһим. «Бомба»лар исә *bubble letter* (ингл. күбекле язу) һәм *throw up* стилендә башкарыла.

Райтерлар арасында һәр граффити-рәссам берсүзсез буйсына торган кагыйдә бар. Иң мөһиме – мәдәни кыйммәткә ия биналарга һәм торак йортларга (кешеләргә үз карашыңны көчләп такма), кабер ташларына, мемориаль диварларга, автомашиналарга, бигрәк тә башка граффити-рәссамнар эше өстенә язмаска. Башка рәссам өстеннән язу – иң түбән һәм нәфрәт уята торган гамәл. Бу кагыйдә райтер өчен әхлак, үзенә бер чик билгесе дә. Ләкин бүгенге көн күрсәткәнчә, барлык граффити-рәссамнар да бу кагыйдәләргә буйсынырга теләми, бомберлар төрле өслекләр «бозуны» дәвам итәләр, шуның белән тулаем граффити сәнгатен дә шик астына куялар. Шулай да шундый оста райтерлар бар: алар «киндер» итеп ташландык йортлар, гаражлар диварын файдалана, аларның иҗат процессы киң мәйданны да biläп алырга мөмкин.

Казанда беренче граффити-рәссамнар 2000 нче еллар башында барлыкка килде. «Aeropop» төркемә берләшкән рәссамнар арасында, мәсәлән, Павел Тиняев һәм Юрий Найдышев бар. Соңрак мөстәкыйль райтерлар да барлыкка килде – Дмитрий Кудинов (LilD), Әмирхан Ризванов (Husky), Игорь Афанасьев (IGOU), Рөстәм Сәлимгәрәев (Qibic) һ.б. Аларның һәркайсының үз темасы, персонаж, шрифтлар бирүдә үз стиле оешкан.

Казанда иң киң таралган спрей-арт формасы булып язмалар тора. Спрей-арт язмаларын берничә группага бүлеп карарга мөмкин:

«Фанат» язмалары: «SPARTAK», «РУБИН» һ.б. футбол клублары логотиплары рәвешендә башкарылган язмаларны җанатарлар күбрәк шәһәр үзәгендә җир асты юлында калдыра.

Националистик язмалар: «Россия для русских», «Татар, уян, 1552», «1552. Мин хәтерлим», «За Русь» һ.б. Бу язмалар «бомба» стилендә шәһәр үзәгендә барлыкка килә торалар.

Сәяси язмалар: «За Путина», «Революция, мы идем» һ.б. күбрәк илдә барган сәяси үзгәрешләр белән бәйле, көндәлек тормышта алай киң таралмаган.

Мәхәббәт язмалары, мәсәлән «Солнышко, я тебя люблю!», профессионаллар тарафыннан эшләнми, шуңа да аларның сыйфаты шактый түбән. Шулай да алар шәһәрнең бар җирендә дә диярлек, үзәктә һәм шәһәр читендә, асфальтта урын алалар.

Хулиган язмалары: «zmz», «zames», «sawd» – күбрәк шәһәр үзәгендә була, кайчак читтәрәк тә очрый. Бу язмалар гадәттә торак йортлар, тарихи биналарга

төшерелә, ягъни шәхси һәм дәүләт милегенә зыян сала, шуның белән халык арасында тулаем спрей-арт сәнгатенә кискен каршылык уята да. Бу язмалар вандализм акты буларак бәяләнәләр, ник дигәндә, беренче чиратта шәһәрнең бу язмалар өчен бөтенләй дә туры килмәгән объектлары зыян күрә. Бүгенге көндә Казанда «Zames» группасы популяр. Төркем 17–25 яшьләр арасында 20 гә якын кешене берләштерә. Алар «территория билгеләп» теләсә нинди өслеккә язма төшерәләр. Төп максат – «zmz», «zames» «бомба»ларын «начар кешеләр»гә караган, ягъни идарә итүче сыйныф биналарына төшерү. Соңгы ике ел эчендә Казанда таган бер мәсьәлә барлыкка килде: «Zames» группасы вәкилләре шәһәрдә инде билгеле булган һәм рөхсәт белән эшләгән райтерлар эшләре өстеннән яза башладылар. Бу факт, әлбәттә, кискен каршылык китереп чыгарды. Райтерлар үзләре бомберлар «иҗатына» өстәнрәк карыйлар, граффити-рәссам тормышында вакытлыча була торган билгеле бер чор итеп бәялиләр.

Реклама язмалары. «Дом.ru», «Работа в офисе», «Работа на дому» һ.б. шундый язмалар трафарет ярдәмендә гадәттә асфальтка, төрле диварларга төшерелә. Трафарет тиз һәм чиста эшләү мөмкинлеге бирә. Язмалар реклама агентлыклары тарафыннан түләнә дә, шуның белән бу юнәлеш үсә, зурая.

Соңгы өч ел эчендә Казан спрейарт сәнгате үсеше буенча шактый зур адым ясады. Моңа, әлбәттә, шәһәребездә булып узган төрле фестивальләр дә нык ярдәм итте. Мәсәлән, 2010 елның август аенда башланып киткән һәм Казан шәһәре мэриясе булышлыгы белән үткәрелгән «Old Kazan. Ru» фестивале. Бу чараның төп темасы – Казан регионы тарихы һәм үсеше. Фестивальдә катнашкан граффити-рәссамнарга иске шәһәр күренешләрен, тарихи шәхесләрне ясарга тәкъдим ителде. Төп максат – үсеп килүче буын вәкилләрен, шәһәр халкын һәм кунакларны кала тарихы белән кызысындыру. Фестиваль нәтиҗәсе булып иске Казан образын бүгенге көн белән бәйләгән эшләр калды.

2011 елның 8–10 июль көннәрендә Казан Кремленең «Манеж» күргәзмәләр үзәгендә, күргәзмәләр сезонын тәмамлап, «MANAGE Art MAUER» арт-акциясе булып узды. Күргәзмә залына стендлар куелган иде. Бу стендларда шәһәрнең иң оста райтерлары осталык күрсәтте. Чараның иң кызыклы өлеше – һәр тамашачы спрей-арт эшенең барлыкка килү процессын, граффитирәссамны эш барышында күзәтә алды. Бу чара шулай ук Татарстанда беренче тапкыр урам сәнгатенең музей белән берләшүен күрсәтә. Оештыручылар фикеренчә, профессионал граффити-рәссамнар эше теләсә нинди галереяны да бизәрлек.

2011 елның 20 ноябрь көнендә Казанда уникаль спрей-арт фестивале – «Ислам глазами молодежи» беренче Казан ислам граффити фестивале булып узды. Чара Татарстан Республикасы Диния нәзарәте инициативасы һәм «Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифе фонды» булышлыгы белән оештырылды. Фестиваль региональ булганлыктан, анда

Пермь, Яр Чаллы, Түбән Кама райтерлары да катнашты. Бу – Россиядә беренче тапкыр дин һәм яшьләр субкультурасын берләштерү максатыннан оештырылган чара. Нәтиҗә буларак, гарәп каллиграфиясе, арабеска һәм Шәрык пейзажлары стилендә эшләнгән 16 зур эш барлыкка килде. Фестиваль күрсәткәнчә, дини кыйммәтләр заман һәм яшьләр таләбенә җавап бирә ала икән.

2012 елның июль аенда Казанда инде «Like it. Art» беренче халыкара граффити-фестиваль үткәрелде. Бу чара «MadeInKazan» проекты кысаларында шулай ук Казан мэриясе тарафыннан оештырылды. Фестиваль кысаларында лекцияләр, мастер-класслар, экспозиция, кулланылган буяу баллоннарыннан инсталляцияләр күрсәтелде. Халыкара чара булгач, фестивальдә Россиядән генә түгел, ә Италия, Болгария, Польша, Украина, Испания, Австрия, Германия һ.б. ил вәкилләре дә катнашты. Фестиваль катнашкан райтерлар, кулланылган материаллар, мәйдан исәбе буенча Европада иң эреләрдән булды. Нәтиҗә буларак, Казан урамнарын бизәп торган зур, сюжетлы эшләр барлыкка килде. Шәһәребезнең кайбер кешеләренә бик үк ошап бетмәсә дә, бу композицияләр шәһәребезгә үзенә бер бизәк, яңа төс өсти.

Бүгене көндә граффити – шәһәр тормышы һәм хәзерге заман мәдәниятенең аерылгысыз өлеше. Казанда спрей-арт, шәһәр башлыкларының яклавы нәтиҗәсендә, законлы төс ала. Мэрия граффити-рәссамнарга мәйдан, эшләү мөмкинлеге, хәтта билгеле бер зонаны бизәү заказы бирә. Әлеге еллар белән шәһәр хакимияте Казаннан бомберларны кысрыклап чыгару өчен дә тырыша. Әйтергә кирәк, бүген спрей-арт сәнгате үзенең каршылыклы, протест күрсәтүче чорыннан үсеш алган этабына аяк баса. Стиль һәм юнәлешләр чикләре юыла, граффити-рәссамнарның статусы да үзгәрә. Бүгенге Казан граффити-рәссамнары техника ягыннан гына түгел, ә тәэсир итү көче белән дә искиткеч эшләр күрсәтәләр. Хәтта шәһәребезне ачык һава астындагы галереягә әйләндерәләр, дияргә мөмкин.

***Исимбитьева Альбина Ринат кызы,***
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлегенең фәнни хезмәткәре
e-mail: isimbiteva@rambler.ru

# «ХӘЗИНӘ»ДӘ КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ СӘНГАТЕ: күргәзмәгә күзәтү

*Л.М. Шкляева*

Кырым татарларының ватаннарына күпләп әйләнеп кайтуы аларның сәнгать тарихында яңа сәхифәләр ачты. Иҗади эшчәнлекләрен мәҗбүри рәвештә Урта Азиядә яки Россиядә башлаган сәнгатькярләр, бабалары җиренә аяк басуга, үзләренең борынгы культураларына килеп кушылдылар һәм, рухланып, милләттәшләренең тарихы һәм традицияләре белән бәйле теманы яңадан күтәреп алдылар.

Ювелирлар (зәркәнчеләр), керамика әйберләре эшләү мастерлары, чигүчеләр, кулдан йон келәм (килим) тукучы осталарның варислары Кырым татарлары телен өйрәнүгә, бүгенге шартларда аларның борынгыдан килгән һөнәрләрен дәвам итү мөмкинлекләрен барлауга алындылар. «Кырым стиле» химаясендәге оешма һәм Украинада, башка илләрнең эре шәһәрләрендә 30 дан артык күргәзмә оештырган «Чатырдаг» иҗади берләшмәсе өзелеп калган традицияләрен кабат торгызып җибәрделәр. 2013 елда Казанда «Кырым татарлары сәнгате» күргәзмәсе оештырылды. Ул ТР дәүләт сынлы сәнгать музее директоры Р.М. Нургалиева инициативасы һәм Мәрҗани фонды ярдәме белән үткәрелде. Экспозиция «Хәзинә» сәнгать галереясында узды (аның кураторлары итеп Л.М. Шкляева белән Г.Р. Вәлиева-Сөләйманова билгеләнгән иде).

Күргәзмәнең бер бүлегендә бүгенге осталарның «иске» традицияләр үрнәгендә иҗат ителгән эшләнмәләре, аерым алганда С. Әюпованың йоннан тукылган келәмнәре куелган иде. XVII гасырга кадәр кулдан тукылган келәмнәрне сату өчен эшләмиләр. Ул гаилә ихтыяҗын тәэмин итү өчен генә, кул эше һөнәрчелеге буларак кына файдаланыла. Хатын-кызлар сарык йоныннан эрләнгән җепләрне табигый буяуларга маналар, алардан бизәкләр төшереп, келәм тукыйлар һәм өйләрен бизиләр. Хан сарайлары өчен келәмне Бахчасарай остаханәләрендә ирләр эшли. Келәмнәрне, товар буларак, җитештерүне яңа баскычка күтәрүдә шәһәрләрдә цехлар, кустарьчылык үзәкләре оеша башлау этәргеч ясый. Бу процесслар Кырым халкы өчен фаҗигале вакыйгалар алып килгән XX йөзьеллыкта тукталып кала. Әмма, хатын-кызның сабыр, оста куллары келәм тукучылыкның борынгы технологиясен үзләренең элгәрләре яшәгән тарихи ватаннарына әйләнеп кайткан бүгенге көннәргә хәтле саклап калган. Сабрия Әюпова да келәм тукуның борынгы сер-

ләрен саклый алган осталарның берсе. Ул үз иҗатында бизәкләрнең кабатлаулы формаларын чиратлаштыра һәм төсләрне дөрес сайлый белә. С. Әюпова эшләнмәләре борынгы нәфис мозаикалы картинаны хәтерләтә. Ул XXI гасырда формалашып һәм үсеп килүче базар таләпләренә йөз тоткан келәм туку һөнәрчелегенең чын остасына әверелде.

«Кырым татарлары сәнгате» күргәзмәсендә Р. Скибинның керамик эшләнмәләре дә куелды. Аның бүгенге милли бердәмлекне чагылдырган иҗаты гаҗәеп матур формаларга мөрәҗәгать итә белүе белән аерылып тора. Скибин балчык эшләнмәләрнең инде меңьярым ел дәвамында камилләшкән җирле традицияләренә таянып иҗат итә. Аны сугарулы (поливная) керамика кызыксындыра. Бу ысул Кырымда XIII гасырда, Кырым чүлмәкчеләренең эшләнмәләрен базар шартларында тарату оешкач ук, барлыкка килгән була, һәм XX гасырда ул тәмам таркала.

Балчык эшләнмәләрнең булачак остасы Р. Скибин Сәмәркандта туа һәм анда сәнгать училищесын тәмамлый. Ул балчыктан күп сыйдырышлы савытлар ясаганда үзбәкләр технологиясеннән файдаланырга омтыла, аларның бизәкләү ысулларын, ялтыравыклы бизәкләр төшерү алымнарын кулланып эш итә. Һөнәри күнекмәләрен эшкә җигеп, автор үз хезмәтләрендә Кырым татарларының образлар дөньясын чын осталарча гәүдәләндерә. Скибин тәлинкәләрендә бизәкләрнең катлаулы композициясе чагылыш тапкан, тәлинкә тирәләрендәге гадәттән тыш, кабатланмас рәсемнәр аларның чын оста кулы аша үтүен дәлилли.

Ювелир (зәркән) сәнгате – Кырым татарлары иҗатының традицион төре. Кырым зәркәнчеләре үз иҗатларында элек-электән көмеш җепләрдән файдаланганнар. Челтәрләп эшләнгән металл эшләнмәләргә ихтыяҗ зур булган, алар Кырым татар хатын-кызларының бәйрәмчә киемнәрендә мәҗбүри компонент булып саналганнар. Бахчасарайдагы остаханәләрнең берсендә эшләүче Айдер Асланов бу эшнең нечкәлекләренә кечкенәдән, әтисенә булышып йөргәндә үк, өйрәнә башлаган. Ул әтисен үзенең остазы дип саный. Аның сәнгати алымнарын үзләштергән Айдер үзе дә торабара көмеш җепләр белән бизәкләп эшләү сәнгатенең чын остасына әверелә. Озак елларга сузылган депортация чорында аңа бу эштән аерылып торырга туры килә, ә инде Кырымга яңадан әйләнеп кайткач, милли бизәкләр төшерелгән металл эшләнмәләр җитештерүен яңартып җибәрә. Кырым татарлары культурасын торгызу белән кызыксынган милләттәшләренең ярдәме белән 72 яшьлек Айдер Асланов үзенең остаханәсен ача һәм анда эшенең серләрен шәкертләренә өйрәтә, инде аларның күбесе остазларыннан калышмый диярлек. А. Аслановның кызы – Эльмира да шундыйларның берсе. Ул бүген зәркәнчеләр династиясенең лаеклы вәкиле.

Сәнгати эшләр күргәзмәсе сәнгатькярләрнең исемнәрен таныта, алар иҗатының кыйммәтен күтәрә.

# ЯҢА КИТАПЛАР

## Д.М. Абдуллина. Тукай иҗатында Коръән мотивлары

Дистә гасырлар дәвамында халкыбызның рухи дөньясына, бөтен яшәешенә сеңеп урнашкан ислам фәлсәфәсе, Коръән кануннары чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндергән әдәбиятыбызда чагылыш тапкан. Илдә хакимлек иткән идеологиянең динне кире каккан, аны халык тормышыннан аерып ташларга теләгән елларда мондый эчтәлектәге әсәрләр иҗат итүче авторларга шактый авырлыклар татырга да туры килде. Инкыйлабтан соңгы елларда иҗатының илаһият кануннары, Коръән белән якынлыгы Тукай шәхесен һәм мирасын бәяләүдә дә катлаулы, каршылыклы фикерләргә сәбәп булды, хәтта шагыйрь «пролетариат укучысы өчен яраксыз» дигән ярлык алырлык хәлгә дучар ителде. Кайчандыр, идеология таләпләреннән чыгып, без шагыйрьне атеист итеп күрергә дә теләдек. Татар халкының җанын, өметхыялларын, кайгы-шатлыкларын, моң-сагышын барлык төсмерләрендә, бөтен тирәнлегендә үзенең иҗатында гәүдәләндерә алган бөек шагыйребез иҗатын рухи кыйммәтләребезнең асылын тәшкил иткән Коръәннән аерып карау мөмкин дә түгел, әлбәттә. Тик бу якынлык ни дәрәҗәдә, аның асылы нәрсәдә? дигән сорауларга җавап эзләдек. Узган гасыр ахырында, коммунистик тыюкысулардан арынып, рухи асылыбызга кайту мөмкинлеге тугач, шагыйрьнең исламга мөнәсәбәте, әсәрләрендәге дини мотивлар турында шактый язмалар да басылды. Ә менә Д.М. Абдуллинаның Татарстан китап нәшриятында «Тукай иҗатында Коръән мотивлары» дип аталган китабын кулга алгач, Тукайны өйрәнү фәнендә күптән көтелгән, бәхәсле мәсьәләгә нигезле, тәфсилле җавап табылуы сөендерде.

Китап ике зур мәсьәләне берләштергән. Беренчесе – Габдулла Тукай иҗатындагы дини мотивларның өйрәнелү тарихы. Бу бүлектә Г. Тукайның иҗатындагы дингә һәм Коръәнгә мөнәсәбәтле фикерләренә кагылышлы әдәби-тәнкыйди карашларга анализ ясала. Автор, җәмгыятьтә дингә мөнәсәбәт үзгәрүгә бәйле рәвештә, Тукай иҗатындагы дини мотивларга булган карашның да аерым этаплар үтүен күрсәтә. Бу – инкыйлабка кадәрге чор, совет дәвере (ул тоталитар һәм посттоталитар дәверләрне үз эченә ала) һәм Тукай мирасын Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре яссылыгында бәяләүгә ирешелгән XX гасыр ахыры. Г. Тукай иҗатындагы ислам диненә мөнәсәбәтле, шул ук вакытта шактый ук каршылыклы фикернең бергә тупланып, янәшә куеп анализлануы үзе үк бу мәсьәләдә эзләнүләрнең максатын ачыклый. Бары совет чорында гына, заман таләбе белән, Тукай иҗатындагы бу мәсьәлә аерым эзәрлекләнү темасына әверелә. Шагыйрьнең «динче» буларак кире кагылуыннан башлап, «атеист шагыйрь» сыйфатында тәкъдим ителү юлы күрсәтелә. Биредә фәнни кулланылышка кертелгән мәкаләләр, Тукай иҗатына мөнәсәбәтле каралсалар да, гомумән әдәбиятның һәм дини фәлсәфәнең уртак максатларын, XX гасырда дәүләт, дин һәм шәхес мөнәсәбәтләрен ачуга да ярдәм итәләр.

Китапның икенче, өченче бүлекләре икенче зур мәсьәлә – Тукай иҗатының әт-Тәүхид фәлсәфәсе, Коръән, хәдисләр белән уртаклыгын ачыклауга

багышлана. Бу мәсьәләгә автор төрле яклап якын килә. Беренчедән, шагыйрь иҗатының ислам кануннары белән фәлсәфи-этик һәм эстетик уртаклыгын тикшерүгә зур урын бирелә. Әсәрләреннән китерелгән күпсанлы мисаллар ярдәмендә Тукайның Аллаһының барлыгын, берлеген тануы, Аның кодрәтенә, җиһанны бар итүче дә Ул икәнлегенә чын күңелдән инануы дәлилләнә. Аллаһының бөек кодрәт иясе булуы, мәрхәмәтенең чикләнмәгенлегенә ышануы шагыйрь иҗатында яңа бер алым – дога рәвешендә язылган әсәрләр тууга китерә, күңелендәге иң садә, иң тирән хисләрне, җан авазын башкаларга ирештерергә булыша, ди автор.

Шагыйрь иҗатының Коръән идеяләре белән уртаклыгының сәбәпләре дә аның халык, милләт язмышын дини мәсьәләләрдән аерып карамавына бәйләп карала. Хезмәттә Тукайның ислам кануннарының асылы булган гаделлек, кешелеклелек, матди һәм рухи тигезлек, зыялы, мәдәни яшәү рәвеше җәмгыятьнең нигезе булырга тиеш дип санавы, әмма сукырларча кол булуга, динне изү коралына әйләндерүгә кискен каршы чыгуы дәлилләнә.

Икенчедән, Тукай иҗатының Коръән белән бәйләнешен ачыклау традицияләлек һәм интертекстуальлек җирлегендә алып барыла. Традицияләлек, канунчылык яссылыгыннан якын килеп, Тукай иҗатындагы Коръән сюжетына нигезләнгән нәзыйрәләр анализлана. Шулай ук Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында да, нәзыйрә традицияләренә һәм бу хакта язылган фәнни хезмәтләргә дә киң урын бирелә.

Интертекстуаль бәйләнешләрдән Тукай иҗатында күп чагылыш тапкан цитаталар, реминисценцияләр, аллюзияләр тикшерүгә алынган. Аларның шигырьләрдә һәм проза әсәрләрендә иркен кулланылышы билгеләнеп, әсәр тукымасындагы төрле сәнгати, мәгънәви вазифалары дәлилләнгән.

Тукайның мөселман мәдәниятенең асылын тәшкил иткән Коръән тәгълиматы белән бәйләнешенә җентекле анализ ясаганнан соң, автор бу иҗатта ислам кануннары, гомумкешелек кыйммәтләре татар милләтенең иҗтимагый-сәяси идеаллары, әдәби-эстетик хасиятләре белән очраша, Шәрык һәм Гареб мәдәнияте казанышлары синтезы рәвешендә мәйданга чыга дигән фикергә килә. Һәм Тукай динче дә, дәһри дә түгел, ул – җәмгыять яшәеше өчен кирәкле, иң әһәмиятле инсаният кануннарын туплаган изге Коръәнгә хөрмәт белән каручы татар кешесе, чын милләтпәрвәр шәхес дигән нәтиҗә ясый. Монографиянең бай фактик, фәнни-теоретик нигезе сокландыра, шулай ук бу хезмәт куелган мәсьәләләрнең тарихи-мәдәни һәм әдәби-эстетик яссылыкта да өйрәнелүе белән дә кыйммәтле.

Китап, һичшиксез, Тукай иҗаты хакындагы безнең күзаллауларыбызны тагын да тирәнәйтә, тулыландыра һәм шагыйрь иҗатын өйрәнү юнәлешендә яңа бер адым булып тора. Гыйльми хезмәт булса да, монография галимнәр, фән белән шөгыльләнүчеләр өчен генә түгел, ә бәлки рухи мирасыбыз белән кызыксынучы һәр кеше өчен дә файдалы басма.

*Ф.И. Габидуллина,*
*филология фәннәре кандидаты*

## А.Х. Садыйкова. XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор

Бу монография күпгасырлык татар әдәбиятының халык иҗаты белән бәйләнешләрен өйрәнү, анализлау буларак язылган һәм авторның шактый еллар буе эшләгән «Ислам һәм халык иҗаты» темасын дәвам итә. Хезмәт киң планда, сигез гасырлык татар әдәбиятын, фольклорын иңләгән анализ булып күзаллана.

Беренче бүлек бөек суфи төрки шагыйрь Әхмәд Ясәви иҗатын яктырта. Биредә шагыйрьнең төрки халыклар арасында дин таратуы һәм бөтен шигъриятнең бераллалыкны белдерүгә, Аллаһыга гашыйклыкны алга сөрүгә багышлануы ассызыклана. Исламда инкяр ителгән сыйфатлар – гафиллек, нәфес, сабырсызлык – Ясәвидә кискен кире кагыла, ди автор. Аның фикеренчә (һәм бу очракта ул хаклы) Ясәви иҗатының Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган хикмәтләре төркиләрдәге дини эпосның нигезләрен тәшкил итә. Дини эпосның булу-булмавы моңарчы шик астында иде. А. Садыйкова анализы күрсәткәнчә, шагыйрьнең хикмәтләрендә ачык чагылган тормыш юлы пәйгамбәрнең гомер этапларын кабатлый.

Хикмәтләре татар әдәбиятында, шигъриятендә, халык иҗатында символлар чылбырын булдыра, дип яза А. Садыйкова.

Урта гасырның дүрт бөек татар шагыйре дә (Хәрәзми, С. Сараи, Котб, Сайяди, шулай ук Рабгузи һ.б.) әсәрләрендә ислам, суфи традицияләрен дәвам иттерәләр. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы һәм башка Урта гасыр шагыйрьләре бераллалыкны һәрдаим алга сөрәләр. Суфичыл әсәрләр шулай ук татар әдәбиятында ислам идеяләрен көчәйтү, әсәрләрне образлар белән баету вазифасын үтиләр.

Ясәвидә төп урын алган дини-суфичыл идеяләр, персонажлар, мотивлар татар язучыларының иҗатында барлык гасырларда да урын ала. XVIII гасыр әсәрләрендә бик көчле дини күтәрелеш чагылыш таба, дип саный автор. Ул һәр татар шагыйренең иҗатын аерым алып күзәтә; дини фольклорның, мифларның алар иҗатында гәүдәләнешен анализлый, уртак формулага әверелгән аерым гыйбарәләрне туплый.

Авторның бер мөһим нәтиҗәсе – суфичыл әдәбият гомум татар әдәбиятының аерылгысыз бер өлеше, дип санау. Мондый күренеш соңгы гасырларда әдәби традиция булып урын ала. Хәтта XX йөз башының бөек шагыйрьләре дә, яңалыкны яклап чыксалар да, барыбер шушы ук традицион сурәтләрне – Аллаһ гыйшкы, Һиҗрәт, мигъраҗ, кадер кич, Коръән, коръәни пәйгамбәрләр – кулла용налар; иблис, нәфес, гафиллекне гаепләү аларның иҗатын мул сугарган, һәм бу күренеш автор тарафыннан җентекле анализ нәтиҗәсендә исбатлана.

А. Садыйкова татар әдәбиятының суфичыл әдәбият белән бәйләнеше турында, төгәл нәтиҗә ясап, яңа фикер әйтә: «...бу мөнәсәбәтләр татар әдәбиятында әдәби суфичылык булып формалашкан».

Һичшиксез, бу хезмәт исламның, суфичыл традицияләрнең татар әдәбияты үсешендә зур роль тотканын раслый, аның дини фольклор белән бәйләнеше исә һәр ике фәнне дә баетканын күрсәтә.

*Н.Ш. Хисамов,*
*филология фәннәре докторы, профессор.*

## М.Р. Булатова. Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана»

Бу хезмәт Көньяк Башкортстанда формалашкан татар сөйләшләренең грамматик үзенчәлекләрен система буларак өйрәнүгә багышланган. Китапның авторы үзе дә шушы тәбәктә туып үскән, Стәрлетамак педагогия институтын тәмамлагач, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршында аспирантура узган, вакытыннан алда кандидатлык диссертациясен яклый. Үзен өметле яшь галимә итеп таныткан Миңнира Рәхим кызы Булатова Институтта фәнни хезмәткәр вазыйфасына эштә калдырыла. Ул татар сөйләшләрен өйрәнүдә актив катнаша, комплекслы экспедицияләрдә булып, мәкаләләр язып тора.

Билгеле булганча, татар диалектологиясенең узган юлы, казанышлары бай. Татар сөйләшләренең барысы да күпсанлы мәкаләләрдә, махсус җыентыкларда һәм монографияләрдә тасвирланып, «Татар халык сөйләшләре» (2 китапта) дигән хезмәттә бергә тупланып фәнгә кертелде. Шунысы әһәмиятле, безнең Татарстан диалектологлары, төрки республикалар арасында беренчеләрдән булып, лингвистик атлас төзүгә керешәләр. Татар тел белемендә лингвистик география методын гамәлгә ашыруга, ареалогик тикшеренүләр уздыруга Л.Җ. Җәләй (1940–1950 нче еллар), Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова (1950–1960 нчы еллар) нигез салучылар булдылар, 2 томлык «Татар халык сөйләшләре атласы»н төзеп бастырып чыгардылар. 1970 нче еллардан башлап, лингвистик география методы белән эшләүне аларның укучылары Л.Ш. Арсланов (Тау ягы сөйләшләре), Д.Б. Рамазанова (Урта Кама төбәге, Көньяк-көнбатыш Башкортстан), З.Р. Садыйкова (Оренбург өлкәсе), Ф.С. Баязитова (Түбән Кама төбәге; керәшен сөйләшләре), Ф.Й. Йосыпов (Урал арты һәм Көньяк Урал), Т.Х. Хәйретдинова (Төньяк-көнчыгыш Башкортстан) һ.б. дәвам иттеләр.

Лингвистик география методы белән өйрәнү татар халык сөйләшләренең формалашу үзенчәлекләрен тарихи планда ачыкларга һәм зуррак мәйдандагы аерым ареалларны барларга ярдәм иттеләр, сөйләшләрне өйрәнүне тирәнәйттеләр (Л.Т. Мәхмүтова, Д.Б. Рамазанова, Д.З. Мәхмүтшина һ.б.).

М.Р. Булатованың әлеге китабында лингвистик география ысулы белән Көньяк Башкортстандагы көнбатыш диалектның стәрлетамак, урта диалектның минзәлә (аның бәләбәй урынчылыгы), турбаслы, тепекәй, кормантау (бу сөйләш авторның ачышы булып тора), учалы сөйләшләренең морфологик үзенчәлекләре анализлана һәм фонетик, синтаксик күренешләр турында да мәгълүматләр китерелә.

Хезмәттә, берьяктан, әлеге сөйләшләр өчен гомумуртак булган һәм, икенче яктан, һәр сөйләш өчен үзенчәлекле саналган күренешләр җентекләп тикшерелә, башка сөйләшләр, башкорт һәм башка төрки телләр, борынгы төрки тел, язма истәлекләр белән системалы рәвештә чагыштырулар уздырыла.

Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк: китап бик яңалыклы. Беренчедән, башкорт авыллары арасында урнашкан һәм татар галимнәренә әлегә билгеле булмаган татар авылларының үзенчәлекләре тасвирлана, нәтиҗәдә автор кормантау сөйләшен аерып чыгара.

Икенчедән, махсус экспедиция барышында тепекәй сөйләшенең төньяк чикләрен ачыклый.

Өченчедән, «Көньяк Башкортстан» ареалындагы авылларның барлыкка килүендә мишәрләрнең этник катнашлыгын билгели. Бу күренеш әлеге сөйләшләрдә көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләрнең күбрәк саклануына китергән.

Дүртенчедән, әлеге ареалда этник башкорт компонентының да роле, мәсәлән, Төньяк-Көнбатыш Башкортстандагы сөйләшләр белән чагыштырганда, күчлерәк булуы ачыклана. Нәтиҗәдә, тикшерелә торган ареалда башкорт теле белән уртак яклар (күбесенчә лексика өлкәсендә) күчлерәк чагыла.

Китапта бер ареал эчендә формалашкан сөйләшләрнең борынгы уртак кыпчак нигезе, формалашу процессында урта диалект сөйләшләренең хәлиткеч роле, татар һәм башкорт телләренең үзара тәэсир итешү закончалыклары кебек катлаулы мәсьәләләр дә кузгатыла. Автор бай фактик материаллар белән эш итә.

Кыскасы, яңа эзләнүләрне чагылдырган, зур фәнни әһәмияткә ия булган, яңалыклы хезмәт дөнья күрде. Ул татар тел белемен, лингвогеографик тикшеренүләр өлкәсен баетуга әһәмиятле теоретик өлеш булып өстәлде.

*Д.Б. Рамазанова,*
*филология фәннәре докторы*

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc. форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

- авторның фамилиясе, инициаллары
- мәкалә исеме
- аннотация (рус телендә)
- төп сүзләр (рус телендә)
- сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, этисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата 2 фән докторы яки 1 фән докторы, 1 фән кандидаты тарафыннан язылган ике рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, 3 нче кат, 133 нче бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2014. № 1

Бизәлеш авторы
*Э. Башарова*

Басарга кул куелды: 6.06.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Өстәмә тираж 200. Заказ К-8

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында
нәшер ителде